МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№10-11 / ноябрь 2012



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ 20 ЕЛ

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕНЕҢ ЕГЕРМЕ ЕЛЛЫГЫ УҢАЕННАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ Р.Н.МИҢНЕХАНОВНЫҢ МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Сезне чын йөрәктән Татарстан Республикасы Конституциясе көне белән тәбрик итәм. Төгәл ике дистә ел элек республикабыз Югары Советы Татарстанның яңа Төп законын кабул итте. Моның нинди зур яңалык булуын, киләчәккә йөз тотуын вакыт бик ачык күрсәтте, дип әйтә алабыз.

Конституциябез үзенең тормышчанлыгын, хаклыгын раслады, социаль һәм икътисади мәсьәләләрне хәл итү нигезенә, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны, мәдәни һәм рухи-әхлакый үсешне тәэмин итү гарантына әверелде.

Республиканың Төп законын кабул итү Федераль үзәк белән мөнәсәбәтләрне үстерү өчен яңа шартлар тудырды. Бу багланышларның конституция-шартнамәчел моделе Россия Федерациясе җитәкчелеге хуплавы белән юридик яктан рәсмиләштерелде. 1994 һәм 2007 еллар шартнамәләре Россия федерализмы үсешендә мөһим роль уйнады.

Федерациянең тиз үсүче субъектларыннан берсе буларак, Татарстан бүген Россия дәүләтчелеген ныгытуны эзлекле яклый.

Татарстан Республикасы Конституциясен эшләгән чорда милләтара һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү аеруча зур әһәмияткә ия иде. Ул чакта барлык татарстанлыларның гражданнар буларак бердәмлеге, этник һәм дини яктан тигез хокуклылыгы турында анык тәгъбирләр табуга ирешелде. Сәяси һәм сайлау системаларының демократия нигезләренә корылуын Төп законда билгеләвебез дә җәмгыятьне берләштерүдә үз ролен уйнады. Боларның әһәмиятен бүген дә бәяләп бетергесез.

Татарстан Республикасы Конституциясе хәзерге социаль-икътисади үсешкә ныклы нигез салды. Икътисадның төп тармакларында ирешкән казанышларыбыз социаль дәүләт принципларын нәтиҗәле тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Төп законыбызда каралганча, республикабыз халкының мул һәм иркен тормышы хәзерге көндә иҗтимагый үсешнең иң төп өстенлекләреннән берсе булып тора.

Граждан җәмгыяте үсә барган саен, халыкның хокукый культурасы да арта. Татарстанлылар Конституцияне хөрмәт итәргә өйрәнәләр, аның нигезләмәләрен белергә, үз хокукларыннан тулы файдаланырга тырышалар.

Законнар чыгару эше эзлексез бара. Вакыт республиканың Төп законына да үзгәрешләр кертүне таләп итәчәк. Әмма Татарстан Конституциясенең төп нигезләмәләре, аның рухы үзгәрешсез калачагы шик тудырмый.

Кадерле татарстанлылар, сезне республикабызның иң әһәмиятле дәүләт бәйрәмнәреннән берсе уңаеннан ихлас күңелдән тәбриклим, сәламәтлек, бәхет, иминлек, киләчәккә якты өметләр һәм какшамас ышаныч телим.

Татарстан Республикасы Президенты
Р.Н.МИҢНЕХАНОВ

Журнал «Татмедиа» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.

Индекс 54132

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Рамил Ханнанов

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Иҗат төркеме:
Илдус Заһидуллин
Диләрә Нәүрүзова
Дания Фәйзуллина
Ленар Гобәйдуллин
Ренат Миңнегалиев
Алия Мөбарәкшина

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Телефон: (843) 222-09-83 (17-90)
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Заказ № М-1479.
Тираж — 3000 данә.
Формат 70 х 108 1/16
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды: 12.11.2012

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№10-11/ ноябрь

Эчтәлек

3 **Татарстан Республикасы Конституциясе. Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә. Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы** *(Өземтә)*

ТАРИХ

6 **Татарстан Республикасы Конституциясе — социаль татулык хартиясе: 20 ел реформа һәм сәяси тотрыклылык юлында.** *Фәрит Мөхәммәтшин*

16 **Татар юлы дәвам итә: Бөтендөнья татар конгрессына — 20 ел!** *Ринат Закиров*

30 **Татарны санау.** *Дамир Исхаков*

37 **Минем халкым.** *Халисә Мөдәррисова*

38 **Татарларда хәйриячелек тарихы сәхифәләре.** *Җәүдәт Миңнуллин*

46 **Татар федераль милли-мәдәни автономиясе: кичә, бүген, иртәгә.** *Алсу Хәбибуллина*

52 **«Без — бербөтен бүленмәс халык».** *Ленар Гобәйдуллин*

76 **«Миллилек — безнең төп өстенлегебез».** *Фаил Камаев белән Рамил Ханнанов әңгәмәсе*

80 **Саратов татар милли гимназиясе.** *Камил Әбләзев*

83 **Кырымым — Казаным.** *Диләвәр Османов*

84 **Тукай авылы мәхәлләсе иҗтимагый киңәшмәсенең эш тәҗрибәсеннән.** *Әгъзам Шакиров*

87 **«Нигмәтең шөкранасы дөньяда кылмак изгелек...»** *Римма Шәйдуллина*

92 **Гани бай.** *Галимҗан Ибраһимов*

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.

Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.

Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда авторлар, М.Козловский, А.Эшкинин, Н.Гарифның шәхси архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

Тышлыкның 1 нче битендә — *А.Эшкинин фотосы;*
3 нче биттә — Бөтендөнья татар конгрессы съездыннан күренеш

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Безнең журналга сез
54132
ИНДЕКСЫ
буенча һәр элемтә бүлегендә язила аласыз.

96 **Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясенең эшчәнлеге турында**. *Фәрит Уразаев*
102 **Бердәм мәгълүмат кырында.** *Гөлназ Шәйхи*
104 **Татар идеясе.** *Рафаэль Мөхәммәтдинов*
111 **Казан.** *Наилә Миңнеханова*
112 **Бөтендөнья татар яшьләре форумы: яңа буын аваз сала!** *Тәбриз Яруллин*
119 **Татарстан — милләттәшләребезнең тарихи Ватаны.** *Рөстәм Гайнетдинов*

124 **Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты эшчәнлегенең «елъязмасы» (1992-2012 еллар).** *Ленар Гобәйдуллин*

СӘНГАТЬ

141 **Сталин лауреаты** (Әдәби портрет). *Рауль Мир-Хәйдәров*

ӘДӘБИЯТ

154 **«Маяк».** *Гөлназ Хөснетдинова*
156 **Милли хәрәкәт вә Себер мөселманнары.** *Гаяз Исхакый*
159 **«Гаҗәпләнмә...»** *Шәүкәт Галиев*
160 **Тынгысыз галимә.** *(Резеда Ганиевага 80 яшь)*
162 **Шәрекъ Ренессансы.** *Резеда Ганиева*
168 **Батырша.** *Фәүзия Бәйрәмова*
174 **Хәйдәр** (Мин белгән Гайнетдин). *Фәрит Яхин*
187 **Читтә.** *Нурия Измайлова*
188 **Тукай энциклопедиясенә.** *Резеда Ганиева*

190 **Яңа китаплар.** *Динә Мостафина*
192 **Тарих сәхифәләреннән.** *Булат Хәйретдинов*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ

14 статья. Татарстан Республикасы Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга милли мәдәниятне, телне үстерүдә, аларның үзенчәлекләрен саклап калуда ярдәм күрсәтә.

Татарстан Республикасы Президенты
М.Ш.ШӘЙМИЕВ
Казан шәһәре,
6 ноябрь 1992 ел.

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ АРАСЫНДА ЭШЛӘР ҺӘМ ВӘКАЛӘТЛӘР БҮЛЕШҮ ТУРЫНДА ШАРТНАМӘ (2007 ЕЛ)

2 статья

[...]

4. Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе Хөкүмәте белән килештереп, ватандашларына көнкүреш үзенчәлекләрен саклап калуда, милли мәдәниятне һәм телне үстерүдә дәүләт ярдәме күрсәтә һәм булышлык итә.

[...]

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ Р.Н.МИҢНЕХАНОВНЫҢ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ЮЛЛАМАСЫ (2012 ЕЛ)

(Өземтә)

[...]

Чит төбәкләрдә яшәгән милләттәшләребез белән мөнәсәбәтләр киңәя һәм ныгый. Зур җаваплылык белән чираттагы Бөтендөнья татар конгрессы корылтаена әзерлек бара.

Агымдагы елның июнь аенда татар дөньясы «ТНВ-Планета» каналын карый башлады. Милли каналны тагын да камилләштерү һәм киңәйтү өстендә эшләүне дәвам итәргә кирәк.

Киләсе елның 1 гыйнварыннан, татар телен өйрәнергә теләгән һәрбер кеше өчен «Ана теле» онлайн-мәктәбе эшли башлаячак.

Каюм Насыйри әйткәнчә, һәрбер укымышлы кеше ике телне белә, беренчесен аңа әнисе өйрәтә.

Безгә төбәкара хезмәттәшлек өлкәсендә җентеклерәк эшләргә кирәк!

ТАРИХ

Булыр әле зур тарихта
Тагын бик күп алмашлар...

Шәүкәт Галиев

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ – СОЦИАЛЬ ТАТУЛЫК ХАРТИЯСЕ:

20 ЕЛ РЕФОРМА ҺӘМ СӘЯСИ ТОТРЫКЛЫЛЫК ЮЛЫНДА

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН,
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе,
сәясәт фәннәре докторы

КОНСТИТУЦИЯ КАБУЛ ИТҮ ҺӘР ДӘҮЛӘТ ЯЗМЫШЫ ӨЧЕН ЗУР ӘҺӘМИЯТКӘ ИЯ. КОНСТИТУЦИЯ — БЕР ҮК ВАКЫТТА ТӨП ЗАКОН ДА ҺӘМ БИЛГЕЛЕ БЕР ТАРИХИ ЭТАПТА ҖӘМГЫЯТЬ ТОРМЫШЫНЫҢ КӨЗГЕСЕ ДӘ. НӘКЪ МЕНӘ КОНСТИТУЦИЯДӘ ДӘҮЛӘТНЕҢ ҺӘМ ШӘХЕСНЕҢ СОЦИАЛЬ ИРЕГЕ ҺӘМ ХОКУКЫЙ ЯКЛАНУ ДӘРӘҖӘСЕ, ДИМӘК, ҖӘМГЫЯТЬ ИГЪЛАН ИТКӘН ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘГӘН СОЦИАЛЬ ИДЕАЛЛАРНЫҢ ҮСЕШ ДӘРӘҖӘСЕ ТУРЫНДА ФИКЕР ЙӨРТЕРГӘ МӨМКИНЛЕК БИРГӘН МӘСЬӘЛӘЛӘР ЧАГЫЛЫШ ТАБА.

6 ноябрьдә Татарстанның Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан кабул ителгән һәм яшәү нормасына әверелгән мөһим Законына — яңа Конституциягә 20 ел тула. Бүгенге көн — XXI гасырның икенче дистә башы күзлегеннән Конституциянең әһәмиятен бәяләп, шуны танырга кирәк: 1992 елда беренче тапкыр Россиянең һәм Татарстанның яңа тарихында яңа дәвер таләпләренә тулысынча җавап бирә торган һәм, аерым алганда, республиканың күпмилләтле халкының ышанычын чагылдырган сәяси-хокукый документ кабул ителде.

1990 елның июнендә — ул чактагы СССР кысаларында — РСФСР халык депутатлары съезды Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итте.

Россия Декларациясенең 4 нче маддәсендә: «РСФСР дәүләт суверенитеты иң югары максатлар өчен — һәр кешегә лаеклы яшәүгә аерылгысыз хокукны, туган телне иркле үстерү һәм куллануны, һәр халыкка милли-дәүләти һәм милли-мәдәни рәвешләрне сайлауда үзбилгеләнешне тәэмин итү өчен игълан ителә», — дип ассызыклана.

Россия Федерациясеннән соң ук, 1990 елның 30 августында, Татарстан Югары Советы Татарстан Республикасы дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итте, ул республиканы суверен дәүләт дип игълан итте; республика территориясендә аның законнарының өстенлеген беркетте; җирне, җир асты байлыкларын, табигый байлыкларны һәм башка ресурсларны бары тик республика халкы милке дип игълан итте; милләтенә бәйсез рәвештә республика гражданнарының хокуклары һәм ирекләренең өстенлеген ассызыклады; Татарстанның милли-дәүләти корылышында сәяси-хокукый реформалаштыру векторын билгеләде. Ә 1990 елның 31 августында республика Югары Советы 39 халык депутаты, сәясәт, хокук өлкәсендәге белгечләр составында Татарстанның яңа Конституциясе проектын әзерләү өчен Конституция комиссиясе төзү турында карар кабул итте, әлеге комиссиянең җитәкчесе итеп ул чорда республика парламенты Рәисе М.Ш.Шәймиев билгеләнде.

1992 елның 21 мартында республика статусы турында барча халык тавыш бирү яңа дәүләт — Татарстан Республикасы төзелү фактын юридик яктан раслады. Сайлаучыларның 60 проценттан артыгы референдумның төп фикерен — үз республикасының

дәүләт статусын арттыруның объектив зарурлыгын һәм сәяси максатчанлыгын таныды. Татарстан күпмилләтле халкының ихтыярын һәм мәнфәгатьләрен чагылдыручы демократик дәүләт, Россия Федерациясе белән Үзара вәкаләтләр алмашу һәм эшләр бүлешү турындагы Шартнамә нигезендә берләшкән, халыкара хокук субъекты дип игълан ителде.

Әлеге шартларда Татарстан Республикасы икътисадын һәм сәяси системасын реформалаштыруга өр-яңа алымнар, республиканың күпмилләтле халкын ныклы сәяси-хокукый конституциячел нигезгә туплау кирәк иде. Башка сүзләр белән әйткәндә, Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү Россиянең сәяси кырында сәяси һәм социаль-икътисади процесслар үсешенә турыдан-туры бәйле булды. Татарстанның яңа Конституциясе проекты 1991 елның 31 декабрендә халык фикер алышсын өчен бастырып чыгарылды, фикер алышу барышында барлыгы 5350 тәкъдим, төзәтмә кертелде. Хатлар һәм телеграммалар республикабыз шәһәрләреннән һәм районнарыннан гына түгел, башка төбәкләрдән дә килде. Халыкара хокук экспертизалары үткәрелде. Болар барысы да республикадагы сәяси процесс һәм Конституция әзерләү белән кызыксыну дәрәҗәсен күрсәтте. Башка конституцияләрдән аермалы буларак, 1992 елгы Конституциянең күпмилләтле Татарстан халкы тарафыннан яклау табуын дәлилләде.

1992 елның маенда Югары Совет сессиясендә Төп Закон проекты беренче укылышта каралды. Конституция комиссиясе халык депутатларыннан кергән биш йөздән артык төзәтмәне карады. Төрле сәяси карашлар, милләтләр һәм дин тотучыларны берләштерә торган килешенгән карарлар кабул ителде. Бу бердәмлекнең нигезендә тарихи дәүләтчелекне торгызуга, республиканың социаль һәм икътисади проблемаларын хәл итүдә мөстәкыйльлеген арттыруга ихлас омтылыш, Татарстанның бүгенгесе һәм киләчәге турында чын кайгырту булды.

Демократияне, республикада яшәүче һәр кешенең социаль һәм гражданлык хокуклары гарантияләрен халыкара хокук нормалары нигезендә ныгытуга, Татарстанның икътисади мөстәкыйльлеген арттыруга, гражданлык татулыгын һәм тынычлыгын, конфессияара толерантлыкны саклап калуга, республика халыклары арасында ышанычны ныгытуга мөһим адым ясалды. Конституция Татарстанның яңа сәяси системасының нигезенә генә түгел, аның бөтен гражданнары тормышының әхлакый, хокукый нормасына да әверелде. Аның төп маддәләре Татарстан дәүләт суверенитеты турындагы Декларациянең мөһим нигезләмәләре һәм референдумда бөтен халык тавыш бирүе нәтиҗәсендә чагылыш тапты.

Тагын шунысы мөһим: 1992 елда Татарстан Конституциясендә, яңа Россия Федерациясе тарихында беренчеләрдән булып, аның субъекты дәрәҗәсендә дәүләтнең демократик хокук өлкәсендә законнарның өстенлеге, аларның тайпылышсыз үтәлеше, закон чыгару, башкарма һәм суд хакимиятләренә бүленеше кебек система барлыкка китерә торган принциплар билгеләнде. Гомумтанылган хокук нормалары республика законнарыннан өстен дип игълан ителде. Шәхеснең Кеше хокукларының гомуми декларациясендә күрсәтелгән төп хокуклары һәм ирекләре закон белән рәсмиләштерелде. Кеше хокуклары иң югары социаль кыйммәт буларак игълан ителеп, гражданның һәм дәүләтнең үзара җаваплылыгы беркетелде.

М.Козловский фотосы

Татарстан Республикасы Конституциясе хакимиятнең үз органнарын, яңа демократик һәм базар икътисады институтларын төзергә мөмкинлек бирде. Аны кабул иткәннән соң хакимиятнең табигате һәм республиканың дәүләтчелеге эзлекле рәвештә үзгәрә башлады. Татарстан совет чорыннан соң дәүләт төзелешен, иҗтимагый-сәяси тормышны эзлекле рәвештә демократияләштерүне кискен социаль киеренкелекләрсез базар икътисады булдыру белән бергә уңышлы берләштерергә мөмкинлеге булган төбәкләрнең берсенә әверелде. Конституциянең төп казанышы шунда ки, ул әлеге процессларга карата, алып барыла торган үзгәрешләрне сепаратизмда һәм авторитаризмда гаепләүләрне бер читкә куеп, ныклы хокукый база булдырды.

Президентлык, даими һәм профессиональ парламент, җаваплы хөкүмәт, җирле үзидарә, Конституция суды, гражданлык кебек дәүләтигавами институтларны конституциячел-хокукый беркетү — боларның барысы да Татарстанга сәяси һәм социаль-икътисади мөнәсәбәтләрне сыйфат ягыннан яңа халәткә күтәрү бурычларын хәл итәргә мөмкинлек бирде. Дәүләт корылышының беренче этабында республика дәүләтчелегенең барлык кирәкле атрибутлары — герб, гимн һәм флаг кабул ителде.

Республиканың Төп Законында беркетелгән гражданлык институты гражданның җәмгыять һәм дәүләт белән тотрыклы хокукый багланышына нигез салды. Бу чакта әлеге багланыш үзара хокукларда, бурычларда, җаваплылыкта чагыла һәм шәхеснең абруен, төп хокукларын, ирекен тануга, ихтирам итүгә нигезләнә.

Гражданның хокукый статусы татарстанлыларга социаль уңайлыклардан һәм ресурслардан файдалануга юл ачты, үз-үзеңне күрсәтү һәм җәмгыять, дәүләт эшләренә идарә итүдә реаль катнашу өчен мөмкинлекләр тудырды. Билгеле, аеруча мөһим конституциячел нигезләмәләрне кайберәүләр декларатив нигезләмәләр дип тә атарга мөмкин, әмма моның сәбәпләре Конституция эчтәлегендә түгел, ә гражданнарның һәм идарәчел структураларның социаль җаваплылыгының, җәмгыятьнең хокукый һәм сәяси культурасының үсеш дәрәҗәсендә, шул исәптән иҗтимагый тормыш практикасында конституциячел нормалар системасын никадәр эзлекле рәвештә тормышка ашыруда.

Иң мөһим сәяси-хокукый норма татар һәм рус телләренә тигез хокуклы дәүләт телләре статусын бирүдән гыйбарәт. Татарстан гражданнарының, нинди милләттән булуына, теленә, дини инануларына бәйсез рәвештә, тигез хокуклылыгы, туган теленнән файдалануның гарантияләре турындагы конституциячел нигезләмәләре республика законнарында да үзүсеш тапты. 1992 елда ук телләр өлкәсен җайга салуның хокукый нигезен тәшкил иткән «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законы, ә бераздан милли мәгариф системасын киңәйтүне; Татарстан халыклары телләрендә әдәбият бастырып чыгаруга ярдәм итүне; шушы өлкәдәге тикшеренүләрне финанслауны; хакимият органнарында, мәдәният һәм мәгариф учреждениеләрендә, массакүләм мәгълүмат чараларында — милли телләр зарурлыгы таләп ителә торган барлык өлкәләрдә республикада төрле телләрдән файдалану өчен шартлар тудыруны күз алдында тота торган программа — Татарстан халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасы кабул ителде.

Конституцияне кабул итү Татарстанга радикаль социаль-икътисади реформаларны уздыруның уникаль юлын сайлап алырга ярдәм итте. Еш кына Федераль үзәк тарафыннан кабул итеп бетерелмәгән безнең алымнар ахыр чиктә шул ук Федераль үзәкнең закон чыгару эшчәнлегендә нигез итеп алынды һәм Федерация субъектлары арасында алдынгы тәҗрибә буларак таратылды.

Әмма, икенче яктан, Татарстан Конституциясе барлыкка килү факты, республиканың хокукый каркасын төзүдәге инновацион алымнар Федерация субъекты белән Үзәк арасында хокукый коллизия тудырды. Коллизиянең асылы республиканың Төп Законы Россия Конституциясеннән алданрак кабул ителүгә бәйле иде, чөнки ахыр чиктә бу ике закон үзара каршылыкка керде. Моннан тыш, Татарстан Федератив Шартнамәгә имза салудан баш тартты, ә аның вәкаләтле делегациясе Россия Федерациясе Конституциясе проектын әзерләү буенча конституциячел киңәшмәдән чыгып китәргә мәҗбүр булды, чөнки сыйфат ягыннан яңа типтагы федератив мөнәсәбәтләр коруда безнең принципиаль карашларыбыз исәпкә алынмады.

Үз чиратында, бөтен халык тавыш бирүе белән кабул ителгән Россия Федерациясе Конституциясе республикада хуплау тапмады. Шуңа күрә әлеге ситуациядән чыгуның төп алымы Федераль үзәк белән республика җитәкчелегенең Татарстан өчен генә түгел, Россия Федерациясе өчен дә тарихи документ булган Вәкаләтләрне чикләү һәм үзара эшләр алмашу турында шартнамә әзерләү һәм аңа имза салу юнәлешендә хәрәкәтләнүеннән гыйбарәт булды.

Россия дәүләтчелегенең федератив

үсеше практикасы Татарстанның мөстәкыйльлеген арттыруга юнәлтелгән омтылышларыбызның принципиаль дөреслеген ышанычлы рәвештә раслады, ә Россия һәм Татарстан конституцияләре нормалары нигезендә 1994 елның 15 февралендә «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы шартнамәсенә имза салу, Россия төбәкләре социаль һәм икътисади үсеш мәсьәләләрен хәл иткәндә, үзләренә зуррак йөк алсыннар өчен, хакимиятнең киләчәктә дә децентральләшү процессларын дәвам итүен аңлата иде.

Бүген исә шартнамәчел гамәлләрнең Россия Федерациясе Конституциясенә каршы килмәве генә түгел, бер үк вакытта Төп Законның аерым нормаларын ачарга ярдәм итүе, булган кимчелекләрне бетерүе һәм ахыр чиктә Россиянең бердәмлеген ныгытуга этәргеч ясавы көн кебек ачык. Татарстаннан соң 1990 еллар азагында Федерациянең 45 субъекты — республикалар, крайлар һәм өлкәләр шартнамәләр һәм Федераль үзәк белән килешүләр аша үз вәкаләтләрен җайга сала башлау очраклы хәл түгел, билгеле. 1990 еллар азагында субъектлар конституцияләре, Россия Конституциясе белән беррәттән, икеяклы шартнамәләр Россия федерализмының нигез ташына әверелде.

1994 елгы Шартнамә безнең иң яңа тарихыбыздагы тиңдәше булмаган вакыйгага әверелде. Аңа имза салу Федераль үзәк белән Татарстан Республикасы арасындагы мөнәсәбәтләрдәге киеренкелекне юкка чыгарды. Бу федератив дәүләт корылышы проблемаларын цивилизацияле юллар белән хәл итүнең ачык мисалы иде. Россия Хөкүмәте белән социаль-икътисади тормышның төрле тармакларындагы мөнәсәбәтләрне җайга салган 12 килешүне имзалап, Татарстан бөтен ил масштабында икътисад белән идарә итүне децентральләштерү алгоритмын һәм аны ничек күз алдына китерүен күрсәтте һәм тәкъдим итте. Ә сәяси күзлектән караганда, без яңа Россиянең федератив дәүләтчелеген ныгытуның фундаменталь факторы төрле дәрәҗәдәге хакимиятләрнең аралашуы һәм үзара хезмәттәшлеге өчен яңа стиль сайлаудан гыйбарәт булуны расладык.

Татарстан Республикасы Конституциясе федератив мөнәсәбәтләрнең Россия Федерациясе сәяси тормышының аерылгысыз элементына әверелгән яңа формуласын беркетте. Дәүләт идарәсенең административ-команда тибына төбәкләрнең мөстәкыйльлеген арттыру, хакимият вәкаләтләрен бүлешү, җирле үзидарә идеясе бөтенләй ят иде. Хәзер исә алардан башка хуҗалык һәм иҗтимагый эшчәнлекне тиешле дәрәҗәдә алып баруны күз алдына китерүе мөмкин түгел.

Татарстанның Төп Законы нормалары нигезендә Татарстан Федерация субъекты компетенциясе кысалары белән чикләнгән халыкара мөнәсәбәтләргә керү хокукын алды. Бүгенге көнгә Татарстан Хөкүмәте тарафыннан Россия Федерациясе төбәкләре, алдынгы бизнес-структуралар, Бергәлек илләрендәге, ерак чит илләрдәге, аларның субъектларындагы фәнни һәм тикшеренү үзәкләре белән 60тан артык килешүгә һәм беркетмәгә имза салынды. Республика Дәүләт Советы тарафыннан Федерация субъектлары белән 34 килешү, ике федераль хакимият органы һәм 7 чит ил партнёры белән килешү һәм беркетмә төзелде. Татарстан тарафыннан кайбер халыкара оешмалар белән үзара файдалы эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырылды, ерак һәм якын чит илләрдә, Россия

төбәкләрендә 20 тулы вәкаләтле, даими һәм сәүдә-икътисад вәкиллекләре ачылды.

Бөтендөнья бергәлеге Федерация субъектларының, федератив дәүләтнең тышкы сәясәте эшчәнлегенә зыян китермичә, киресенчә, аны баетырлык һәм аңа яңа төсмерләр кертерлек итеп килештерелгән халыкара икътисади, фәнни-техник һәм мәдәни бәйләнешләрының әһәмиятен таныды. Барлык цивилизацияле дөньяда Федерация дәүләтләре (әгъзалары) күптән инде халыкара хокук субъектларының яңа категориясенә бүленде һәм бу факт беркемне дә борчымый. Киресенчә, алар Европа төбәкләре ассамблеясына берләште, Татарстан 1990 елдан бирле аның әгъзасы булып тора.

2000 еллар башында, Татарстан Конституциясен кабул иткәннән соң ун ел узгач, аңа билгеле бер үзгәрешләрне кертү зарурлыгы объектив рәвештә барлыкка килде. Моның сәбәпләренең берсе — Төп Законны кабул иткәннән соң республикада хакимиятнең яңа институтлары: даими эшләүче парламент, Конституция суды, җәмәгать судьялары һәм башка шундый институтлар барлыкка килүгә бәйле төзәтмәләр кертүдән гыйбарәт. Икенче яктан, Конституция белән беркетелгән кайбер вәкаләтләрне республика шартнамә нигезендә Федераль үзәккә тапшырды. Конституциядә чынлыкта эшләми торган статьялар да бар иде. Болар бар да Татарстан Конституциясе нормаларының Россия Конституциясенә һәм Федераль законнарга каршы килүенә этәрде. Шуңа күрә моны хакыйкать үзе таләп итә иде.

Шул заманнарда Россиядә законнар системасының тулаем төзек булмавы нәтиҗәсендә төбәкләр законнарының Федераль законнарга туры килмәве проблемасы Федерациянең башка субъектларына да хас иде. 1990 елларда төбәкләр еш кына бу җәһәттән үзәктән алдарак бара башладылар. Федераль үзәк уртак карамактагы мәсьәләләр буенча законнар кабул итүдә төбәкләрдән соңга калып килде, мондый законнар эшләнгән вакытта Дәүләт Думасы тарафыннан субъектларның мәнфәгатьләрен һәм хокук куллану практикасын исәпкә алмау очраклары да булды.

2000 ел башыннан республиканың Дәүләт Советы безнең законнарны Федераль законнарга туры китерү буенча масштаблы эш башлады. 1990 елдан 300гә якын закон кабул ителде, аларның һәрберсен җентекләп анализларга кирәк иде. Президент М.Ш.Шәймиев җитәкчелегендәге Конституция комиссиясе дә үзенең эшчәнлеген башлап җибәрде, ул Татарстан Конституциясенең яңа редакциясе проектын әзерләүне үзенә максат итеп куйды.

Үз эшендә Конституция комиссиясе Төп Законның яңа редакциясе проектында республика тормышында булган олы үзгәрешләрне тиешле дәрәҗәдә чагылдыруга, Татарстан Конституциясе нормаларының Россия Федерациясе Конституциясе нормаларына, тулаем алганда, үсеп килүче федераль законнарга туры китерү зарурлыгына таянды.

2002 елның 28 февралендә «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы закон проекты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына кертелде. 2 марттан 20 мартка кадәр халык депутатларының шәһәр һәм район Советлары сессияләрендә, җирле үзидарә органнарында закон проекты буенча фикер алышулар уздырылды. Газеталарда, радио һәм телевидениедә махсус рубрикалар ачылды, аларда Конституция

комиссиясе әгъзаларының, барлык дәрәҗәләрдәге депутатларның, партияләр һәм иҗтимагый берләшмә вәкилләренең чыгышлары оештырылды. Фикер алышу барышында закон проектына 1242 тәкъдим һәм төзәтмә керде.

Тәкъдимнәрнең һәм искәрмәләрнең күбесе Татарстанның конституциячел корылышы нигезләрен, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, республикада дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә оештыруны җайга сала торган нормаларга кагылышлы иде. Конституция комиссиясе һәм парламент тарафыннан җентекләп өйрәнелгәннән соң, аларның күбесе закон проектының йомгаклау текстына кертелде. 2002 елның 19 апрелендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Конституциясенең яңа редакциясе кабул ителде.

Республиканың Төп Законы 1992 елгы Конституциянең хокук дәвамлылыгын саклап калды. 1 статьясы белән Татарстан Республикасы — Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсе нигезендә Россия Федерациясе белән берләшкән демократик хокукый дәүләт һәм Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең субъекты булып тора дигән норма беркетелде.

Әлеге икеяклы Шартнамәнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хокук системасының төп өлешенә әверелүен тану да бик мөһим. Конституциядә республиканың статусы беркетелде, ул, Россия Федерациясе карамагындагы эшләрдән һәм Татарстан белән уртак карамактагы эшләр буенча Россия вәкаләтләреннән тыш, калган барлык вәкаләтләргә, дәүләт (закон чыгару, вәкиллекле һәм суд) хакимиятенә тулысынча ия булуда чагыла.

Республика Конституциясендә халыкара хокук субъектлылыгы мәсьәләсе буенча да хокук дәвамлылыгы тәэмин ителгән. Үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан халыкара һәм тышкы икътисади багланышларда мөстәкыйль катнаша, ул, субъектлар һәм чит дәүләтләрнең административ-территориаль берәмлекләре белән генә түгел, ә чит дәүләтләрнең үзләре белән дә килешүләр төзергә хокуклы. Базар икътисадын киңәйтү һәм үстерү буенча тупланган тәҗрибә нигезендә Конституциянең яңа редакциясендә милекчелек институтларының эшчәнлеген тәэмин итү нормалары көчәйтелде, хуҗалык субъектларының намуссыз көндәшлегенә турыдан-туры чик кую мөмкинлеге билгеләнде, кече һәм урта бизнесны үстерүдә дәүләт ярдәме турындагы нигезләмә беркетелде. Тигез хокуклы татар һәм рус телләреннән гыйбарәт булган дәүләт телләре турындагы норманың да дәвамлылыгы чагылыш тапты. Татарстанның бу принципиаль позициясе — аның сәяси тотрыклылыгын тәэмин иткән иң мөһим шартларының берсе. Шуның белән бергә әлеге норманың җитди төзәтмә аша тулыландырылуын ассызыклап үтәргә кирәк, аның нигезендә «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт учреждениеләрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләре бертигез нигезләрдә кулланыла». Шулай ук яңа статья да барлыкка килде, аның нигезендә республика Та-

тарстаннан читтә яшәүче татарларның милли мәдәниятен, телен үстерүдә, көнкүреш үзенчәлекләрен саклап калуда ярдәм итә.

Кеше һәм граждан хокукларына, ирегенә һәм бурычларына шактый игътибар бирелә. Конституциянең яңа редакциясендә әлеге аспект Россия законнары, шулай ук халыкара хокук нормалары белән аңлатыла торган гомумтанылган нормалар призмасы аша чагылдырылды.

Ниһаять, Төп Законда хакимиятнең барлык тармакларының функцияләре күрсәтелде. Сүз республиканың даими эшләүче парламентының функцияләрен һәм хакимиятләр бүлешү принцибын беркетү турында бара. Федераль законнар нормаларыннан, парламентаризмны үстерүнең халыкара тәҗрибәсеннән чыгып, депутат корпусының хокукый статусына принципиаль үзгәрешләр кертелде. Республика депутат корпусының партия принцибы буенча төзелә башлаган санлы составында гына түгел, ә парламентның контроль функцияләрендә дә үзгәрешләр барлыкка килде. Дәүләт бюджет акчаларын тотуны тикшереп тору кысаларында яңа институт — Хисап палатасы төзелде.

Җирле үзидарә институтының эшчәнлек өлкәсе республика шәһәрләре һәм районнары дәрәҗәсенә кадәр киңәйтелде, халык хакимияте органнарының муниципаль милекне биләү һәм аннан файдалану өлешендә хокуклары һәм вәкаләтләре беркетелде. Башкача әйткәндә, Татарстан Конституциясенең барлык бүлекләренә диярлек төзәтмәләр кертелде. Аның яңа редакциясендә Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында яңа башланган тарихи чорның мөһим таләпләре чагылыш тапты.

Шуны да аерым билгеләп үтәргә кирәк: Төп Законның яңа редакциясен әзерләгәндә, без Россиянең бердәм хокукый киңлегенә керү Федерациянең барлык субъектларында да бер үк төрле законнар булырга тиешлекне аңлатмый дигән лейтмотивтан чыгып эш иттек. Региональ дәрәҗәдә хокукый җайга салуның зарурлыгы сакланып кала, чөнки Россия Конституциясендә субъектлар компетенциясенә генә керә торган һәм уртак карамактагы эшләр билгеләнгән. Әгәр барлык законнар да Мәскәүдә генә кабул ителә торган булса, Россия федератив түгел, ә унитар дәүләт булыр иде.

Узган ике дистә ел эчендә төбәкләрдә закон чыгару эше буенча шактый тәҗрибә тупланды һәм моны исәпкә алмый мөмкин түгел. Беркем өчен дә сер түгел: субъектларның аерым норматив актлары кешеләрнең тормыш эшчәнлеге буенча теге яки бу мәсьәләне федераль законнарга караганда нәтиҗәлерәк хәл итә, бу исә Үзәк тарафыннан да танала. Шуңа бәйле рәвештә, аеруча прогрессив региональ законнарны федераль дәрәҗәдә тарату мөмкинлеге турындагы мәсьәләне законнар белән җайга салу бик мөһим. Федераль закон чыгаручының аларны исәпкә алуы хокукый каршылыкларны булдырмауга гына түгел, ә тулаем Россиядә законнарның сыйфатын күтәрүгә, җәмгыятьтәге тотрыклылыкны тәэмин итүгә, аның үз-үзен үстерү механизмын барлыкка китерүгә ярдәм итәчәк.

2004 елның февралендә Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының беренче Шартнамәсенә ун ел булды. Әлеге Документның кайбер юридик нормаларының гамәлдән чыгарылуы

нәтиҗәсендә, Россия Федерациясенең сәяси-хокукый даирәсендә Үзәк белән Россия Федерациясе субъекты арасында каршылыклар тудыра торган вазгыять барлыкка килде. Әлеге вазгыятьне хәл итү өчен махсус комиссия төзелде, ул яңа Шартнамә проектын әзерләү буенча күпкырлы эш башлап җибәрде.

Дәүләт хакимиятенең федераль органнарында, шулай ук сәясәтчеләр һәм галимнәр арасында булган килештерүләрнең, сәяси әңгәмәләрнең озакка сузылган һәм катлаулы чорыннан соң 2006 елның декабрендә Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин Федераль Собраниегә «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында Шартнамә» проектын кертте. Илнең иң югары вазифаи затының шушы гамәле белән Россиянең федератив дәүләтчелеге Федераль закон рәвешендә кабул ителә торган тагын бер сәяси документ белән ныгытылды.

Яңа Шартнамә проекты буенча Федераль Собрание палаталарында катлкат фикер алышулар уздырылганнан соң, ул 2007 елның 26 июнендә Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин һәм Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев тарафыннан имзаланды. Ә 2007 елның 24 июлендә Россия Президенты «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турындагы Шартнамәне раслау хакында» 1999-ФЗ номерлы Федераль законга кул куйды.

Шартнамәнең төп билгеләнеше — игътибарны федерализм мәсьәләләренә юнәлтү генә түгел, ә төрле милләтләрнең хокуклары һәм мәнфәгатьләре аша демократия принципларын раслау да, этникара конфликтларны булдырмау да, төбәкләр икътисадын җирле халык мәдәнияте һәм традицияләре үзенчәлекләрен исәпкә алу нигезендә үстерү дә ул. Татарстан шундый төрдәге федератив мөнәсәбәтләрне урнаштырган бердәнбер төбәк булды. Җаваплылык һәм мөстәкыйльлек идеологиясе республиканың дәүләтчелеген үстерүдә заманча этап формуласына әверелде.

Республика Конституциясендә Татарстанның икътисади нигезен ныгытуда социаль базар хуҗалыгының роле дә аерым беркетелде, базар мөнәсәбәтләрендә закон нигезендә хуҗалык эшчәнлеге иреге һәм милек рәвешләренең төрлелеге тәэмин ителә. 1990 еллар уртасында без Россиядә беренчеләрдән булып, төп җитештерү чарасы буларак, җиргә хосусый милекчелек хокукын игълан иттек һәм юридик яктан рәсмиләштердек. Моннан тыш Дәүләт Советы тарафыннан Җир кодексы, тиешле законнар кабул ителү җир байлыкларын, шул исәптән нәтиҗәле файдаланылмый торганнарын да, базар әйләнешенә актив җәлеп итәргә мөмкинлек бирде.

Бүген, Конституция көнен билгеләп үткәндә, без барыбыз да Татарстан Республикасының Төп Законы узган елларда үзенең тормышка һәм хокукка сәләтлелеген күрсәтте, дип ышанычлы рәвештә әйтә алабыз. Россия Федерациясенең иксез-чиксез киңлекләрендә башланган югарыдагы һәм башка бик күп социаль-сәяси процессларның башында бүген республикабыз егерме еллыгын билгеләп үтә торган Татарстан Республикасы Конституциясе булды. Россиянең бүгенгесе һәм киләчәге, Татарстан Республикасының барлык күпмилләтле халкы өчен аның тарихи әһәмияте бәяләп бетергесез. ■

ТАТАР ЮЛЫ ДӘВАМ ИТӘ : БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНА – 20 ЕЛ!

РИНАТ ЗАКИРОВ,
Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе,
тарих фәннәре докторы



...1992 ЕЛНЫҢ ИЮНЬ АЕНДА КАЗАНДА БЕРЕНЧЕ БӨТЕНТАТАР ҖЫЕНЫ УЗДЫ. ШУШЫ ОЛЫ КОРЫЛТАЙДА БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫН БУЛДЫРУ ТУРЫНДА КАРАР КАБУЛ ИТЕЛДЕ ҺӘМ АНЫҢ ҖИТӘКЧЕ ОРГАНЫ – БАШКАРМА КОМИТЕТ САЙЛАНДЫ. УЛ ВАКЫЙГАДАН СОҢ ИНДЕ 20 ЕЛ ВАКЫТ УЗЫП ТА КИТТЕ ҺӘМ БЕЗНЕҢ ШУШЫ ДӘВЕРДӘ ҮТКӘН ЮЛЫБЫЗНЫ КҮЗАЛЛАП, БАШКАРЫЛГАН ЭШ-ГАМӘЛЛӘРГӘ, АЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕНӘ БӘЯ БИРЕРГӘ ХАКЫБЫЗ БАР ДИП УЙЛЫЙМ. 2007 ЕЛДА УЗГАН БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНЫҢ IV СЪЕЗДЫНДА ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ: «БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ – ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНДА ИҢ УҢЫШЛЫ ПРОЕКТЛАРНЫҢ БЕРСЕ», – ДИП ӘЙТКӘН ИДЕ. МОНЫҢ БЕЛӘН КИЛЕШМИЧӘ БУЛМЫЙ.

Әйе, татар халкы тарихы бай да, катлаулы да, фаҗигале дә. Заманында бабаларыбыз шанлы дәүләтләр тоткан, урта гасырларда Евразиядә яшәгән халыкларның үсешенә, язмышына йогынты ясаган, бай матди һәм рухи мәдәният булдырган. Ата-бабаларыбызның олы мирасы безнең бүгенге яшәешебезнең ышанычлы рухи нигезе булып тора, киләчәккә өмет белән карарга мөмкинлек бирә.

Татар тарихына күз салсак, аның фаҗигале сәхифәләрен дә күрәбез. XVI гасырда мөстәкыйльлекне югалткач, милли тарихның гаять катлаулы чоры башлана. Дәүләтчелек институтларсыз калган шартларда бай мәдәни мирасны саклау да, тәрбия-мәгариф системасын яшәтү дә, гореф-гадәтләрне яңа буыннарга тапшыру да нык катлаулана. Яшерен-батырын түгел, православие идеологиясенә корылган Россия дәүләтендә башка халыкларга һәм диннәргә мөнәсәбәт кырыс була, алар даими басым астында яшиләр. Монда халкыбызның бәгыренә үткән көчләп чукындыру сәясәте дә, социаль-икътисади мәсьәләләр дә, мәгариф-мәдәният өлкәсендәге чикләүләр дә — барысы да татар тормышына, язмышына тискәре йогынты ясый, әлбәттә.

Әмма, шуларга карамастан, татар халкы бирешми, яши, көрәшә, үзенең оптимистик рухы, якты өметләре белән күрше, тугандаш халыкларга да үрнәк булып тора. Дәүләтчелекне югалткач, авыл мәхәлләләре һәм игенче җәмгыятьләре татар халкы тормышын саклаучы, оештыручы төп үзәккә әверелә. Чынлап та, татар авылы бит ул кечкенә бер дәүләтне хәтерләтә. Аның мәчете, мәктәп-мәдрәсәсе, күңел ачу чаралары да, халык җыеннары — барысы да татарның милләт булып яшәешенә хезмәт иткән, милли мәдәният үсешен тәэмин итеп торган. XIX гасыр уртасында Казан университетында эшләгән атаклы алман галиме, этнограф һәм табиб Карл Фукс татарлар турында: «Алар күп кенә Европа халыкларыннан да гыйлемле, укымышлырак, укый-яза белмәгән татарны милләттәшләре хөрмәт итми», — дип яза. Бу — бик югары бәя!

XIX йөздән XX гасырга татар халкы инде әзерлекле, өлгергән милләт булып килеп керә. Моны гасыр башы көчле милли-мәдәни күтәрелеше анык дәлилли. Юкка гына ул чорны татар Ренессансы дип атамаганнар. Нәкъ шушы елларда яңа заманча милли әдәбият, профессиональ театр, музыка сәнгате, журналистика барлыкка килә, уртак әдәби тел формалаша. Әдәбият мәйданына Г.Тукай, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Дәрдмәнд, М.Гафури, Г.Ибраһимов һәм бик күп башка яшьләр язгы ташкын булып килеп керә. Иҗтимагый фикер, илаһият гыйлеме өлкәсендә Йосыф Акчура, Садри Максуди, Галимҗан Баруди, Ризаэтдин Фәхретдин, Муса Бигиев, Габдрәшит Ибраһимов һәм башка күп җәмәгать эшлеклеләре, акыл ияләре үз сүзләрен әйтә. Шул елларда Россия империясенең төрле почмакларында дистәләгән татар газета-журналлары чыга башлый, татар китаплары миллионлаган тиражлар белән басыла.

Нәкъ шушы чорда татарның рәсми иҗтимагый хәрәкәтләре формалаша. Яңа дулкында Беренче Россия инкыйлабы уңай тәэсир итә: мәгълүм ки, 1905 елның 15 августында, Түбән Новгород ярминкәсе вакытында, Ока елгасында «Густав Труве» пароходында бер төркем татар зыялылары һәм эшмәкәрләре йөзәргә чыга. Нәкъ менә шушы вакытта яшерен шартларда Россия мөселманнары тарихының бик мөһим вә кызыклы вакыйгасы — «Иттифак әл-Мөслимин» дип аталган Бөтенроссия мөселманнары фиркасен

булдыру турында карар кабул ителә. Фирканең II съезды 1906 елның гыйнварында яшерен рәвештә Петербургта җыела, ә III съезды 1906 елның августында Түбән Новгородта ярминкә вакытында рәсми рәвештә үткәрелә.

XX гасыр башындагы милли-мәдәни күтәрелеш иҗтимагый-сәяси хәрәкәт белән үрелеп барган. Мәгълүм булганча, 1905 елның 17 октябрь Патша манифестында ил халыкларына төрле өлкәләрдә ирек бирү турында әйтелә. Татар җәмәгатьчелеге манифестны бик рухланып, зур өметләр белән кабул итә. 1906 елның язында I Дәүләт Думасына сайлаулар уза, Россия парламентына мөселман депутатлары, шул исәптән 12 татар сайлана. 1917 елга хәтле Думаның дүрт чакырылышында мөселман депутатлары,

татарлар вәкиллек итә. Гасыр башы милли күтәрелеше халкыбыз язмышына бик көчле тәэсир итә — милләтнең заманча укымышлы, зыялы катламы барлыкка килә. Әмма Россиядә һәр революцион күтәрелештән соң реакция чоры башлана, 1905-1907 елгы инкыйлабтан соң да шулай була, Патша хөкүмәте (бигрәк тә А.Столыпин чорында), янә мөселман мәгариф системасын кысып, мөселманнарның эчке тормышына үҗәтләнеп тыкшына башлый.

Шулай итеп, 1917 ел җитә. Февраль инкыйлабын татарлар бик дәртләнеп, теләп кабул итәләр. 1917 елгы вакыйгалар татар халкының шактый әзерлекле милләт булуын күрсәтә.

Гомумән, ул чорда татар милли хәрәкәте ташкын кебек бәреп чыга. 1917 елның мартында мөселман гаскәриләренең Хәрби Шурасы оеша һәм бу оешма меңләгән хәрбине берләштерә. 1917 елның язында Бөтенроссия мөселман укучы яшьләре һәм Бөтенроссия мөслимәләр съездлары уза. Ниһаять, 1917 елның 1 маенда Мәскәүдә атаклы Әсәдуллаев йортында I Бөтенроссия мөселман съезды ачыла, корылтай ике атна эшли. Әлеге съездда Россия мөселманнарының Милли Шурасы сайлана, анда кергән 30 кешенең унысы татар була. Милли Шурага татарның күренекле вәкилләре Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Фатих Кәрими, Ильяс Алкин һ.б. сайлана.

II Бөтенроссия мөселман съезды 1917 елның июль аенда Казанда җыела. Бу юлы Казанга Кавказ һәм Төркестан вәкилләре килми һәм шул сәбәпле әлеге җыен Эчке Россия һәм Себер төбәге мөселманнары корылтаена әверелә. Нәкъ шул вакыйгага туры китереп, Казанда I Бөтенроссия мөселманнарының хәрби съезды һәм Бөтенроссия мөселман дин әһелләре съездлары җыела. Әйтергә кирәк, бу съездлар, һичшиксез, татар халкы тарихында әһәмиятле урын алып торалар. Алар милләтебезнең шул чордагы оешканлыгын, тәвәккәллеген күрсәтәләр. 1917 елның 22 июль көнендә Казанда өч съездның уртак утырышында Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни мохтарияте игълан ителә. Бу зур вакыйга татар милли дәүләтчелеген торгызу юнәлешендә тәүге һәм бик мөһим адым була. Утырышны мөфти хәзрәтләре Галимҗан Баруди Коръән укып ачып җибәрә, аннары Садри Максуди Эчке Россия һәм Себер мөселманнары мохтарияте турында Декларация игълан итә. Шулай ук бу көн милли бәйрәм көне дип игълан ителә!

1917 ел Совет заманында Октябрь революциясе елы дип дан казанган, әмма татар тарихы өчен ул бөтенләй башка вакыйгалар белән әһәмиятле. Ул елны милли күтәрелеш шундый биеклекләргә хәтле барып җитә, хәтта 1917 елның ноябрендә Милләт мәҗлесенә (милли парламентка) сайлаулар уза. Милләт мәҗлесенең тәүге эшчәнлеге 1917 елның 22 ноябрендә Уфада башлана. Шушы көннән, татар иҗтимагый хәрәкәте милли дәүләтчелек кору юнәлеше ала.

Һәр эшчәнлекнең үз мантыйгы була. Башта татар милли хәрәкәте Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни мохтариятен булдыру дип кенә эшне башлаган булса, аның парламентын сайлау, төрле нәзарәтләрдән (министрлыклардан) торган Милли Идарә кору, халык тормышына кагылышлы төрле законнар кабул итү — болар барысы да чынбарлыкта милли дәүләтчелеккә таба адымнар булып күзаллана. Татар хәрәкәте 1918 елның гыйнварыннан милли дәүләтчелек коруны максат итеп куя. Милли Мәҗлес

большевиклар фетнәсен һәм аларның хакимиятен танымый. Шул сәбәпле татар хәрәкәтенә, аның парламентына һәм хөкүмәтенә бик авыр шартларда эшләргә туры килә. Бүгенге замандашлар ул вакыттагы батыр милләт каһарманнарын белергә тиеш. Милләт мәҗлесендә Милли идарә рәисе итеп Садри Максуди, финанс министры итеп Шәйхулла Алкин, мәгариф министры итеп Нәҗип Корбангалиев сайлана, дин эшләре нәзарәтен мөфти хәзрәтләре Галимҗан Баруди җитәкли.

Милли Мәҗлес Уфада эшләсә дә, Идел-Урал штатын игълан итү татарның борынгы башкаласы Казанда 1918 елның 1 мартына билгеләнә. Шушы максат белән Милләт мәҗлесе махсус комиссия төзи. 1918 елның 8 (21) гыйнварында Казанда II Бөтенроссия мөселман хәрби съезды ачыла, Идел-Урал штатларын нәкъ шушы съездда игълан итү планлаштырыла. Әмма большевиклар бу юнәлештәге адымнарга көчле каршылык күрсәтә, II Бөтендөнья мөселман хәрби съездында большевиклар төркемен оештыралар (Муллануp Вахитов, Камил Якубов, Мирсәет Солтангалиев һ.б.). Шулай итеп, Казанда татар милли хәрәкәте һәм большевиклар арасында ачыктан-ачык каршылык башлана, эш хәтта хәрби бәрелешләргә дә барып җитә. Шуңа да карамастан Хәрби Шура Казанның татар өлешенә күчә һәм 1 март төнендә Идел-Урал Республикасын игълан итә. Әмма ул көннәрдә большевикларга Мәскәүдән һәм Петроградтан хәрби ярдәм килеп җитә, сан ягыннан шактый өстен булган гаскәр һөҗүм башлый. Идел-Урал Республикасы тормышка ашмый кала. Бу чорда илдә гражданнар сугышы җәелә башлый һәм әлеге шартларда ирекле татар милли хәрәкәте басыла.

1920 елның маенда В.И.Ленин кул куйган декрет нигезендә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырыла. Әлбәттә, моны татарның ирекле формада башкарылган үзбилгеләнү гамәле дип танып булмый. Әмма яхшымы-яманмы, бу XVI гасырдан соң формаль рәвештә торгызылган тәүге татар

дәүләтчелегенең яңа формасы һәм милләтнең киләчәк язмышы өчен файдалы гамәл була. Шушы автоном республика кысаларында татарның XX гасыр мәдәнияте, әдәбияты, сәнгате үсә. Дөрес, ул үсешкә совет идеологиясе бик нык тәэсир итте, әмма шул ук вакытта милли сәнгатьнең яңа жанрларыннан академик музыка, опера, балет, кино һ.б. барлыкка килде. Милли мәдәният, аның югары жанрлары, милли дәүләтчелекнең институциональ нигезе, Россия шартларында аларны яшәтер-үстерер милли республикалар булырга тиеш.

Әлбәттә, Совет дәүләте тоталитар режим шартларында милли хәрәкәт була алмады, әмма чит илләрдә татар мөһаҗирләре тырышлыгы белән милли хәрәкәт яшәде, милләтнең ирекле фикерен дә яшәтте-үстерде. Безнең чит илләрдә иҗат иткән бик күп танылган зыялыларыбыз XX гасырда татарның ирекле фикерен саклап үстергән. Йосыф Акчура, Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Әхмәт Тимер, Гали Акыш, Рәшит Арат Рәхмәти, Тамурбәк Дәүләтшин, Гариф Солтан, Әгъдәс Курат Нигъмәти һ.б. исемнәре татар иҗтимагый фикере тарихында алтын хәрефләр белән язылган. Алар заманча милли идеологияне булдырдылар һәм яшәттеләр. 1934 елда Япониянең Кобе шәһәрендә, ә 1935 елда Маньчжуриянең Мукден шәһәрендә зур татар корылтайлары уза. Ул җыеннарда Төркия, Финляндия, АКШ илләреннән килгән милләттәшләр катнаша.

XX гасыр ахыры Татар милли хәрәкәтенең яңа күтәрелешенә Советлар илендә башланган үзгәртеп кору сәбәпче булды. 1988 елның җәендә бер төркем татар зыялылары Казан университетында милли мәсьәләләр турында җыелыш уздыралар, 11 кешедән торган оештыру комитеты сайлыйлар һәм аңа Татар милли оешмасын төзү вазифасын йөклиләр. Ул оешма Татар иҗтимагый үзәге (ТИҮ) буларак халык арасында көчле яклау тапты. 1988-1989 елларның кышында Казанда, Чаллыда һәм Татарстанның башка шәһәрләрендә зур митинглар узды, анда милли мәсьәләләр күтәрелде. 1989 елның февралендә Казанда Г.Камал исемендәге театр бинасында Советлар Союзының төрле почмакларыннан килгән 800 делегат катнашында Татар иҗтимагый үзәгенең I корылтае узды. Шулай итеп, илнең төрле төбәкләрендә Татар иҗтимагый үзәкләре оеша башлый, татар халкының сәяси активлыгы көчәя.

XX гасыр башында милли хәрәкәт татар дәүләтчелеген торгызу мәсьәләсен күтәрә, ул идея башка формада — Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы рәвешендә тормышка аша. Әмма автономияле Татарстан Республикасының мөмкинлекләре бик нык чикләнгән була. Билгеле булганча, Советлар Союзы төрле статустагы милли республикалардан тора иде. Мондый төзелеш халыклар арасында тигезсезлек тудырды, аларны төрле сортларга бүлде. Әйтик, ул вакыттагы союздаш республикаларның мәдәният, мәгариф, фән өлкәләрендә мөмкинлекләре автономияле республикаларныкыннан күпкә зур булды. Аларда милли әдәбият, тарих фәне, мәгълүмат чаралары, китап бастыру эшләре артык чикләнми иде. ТАССР-да хәтта яшьләрнең әдәби журналын чыгару шушы статуска бәйле рәвештә тыелган була. Татарстанның чикләнгән статусы Фәннәр академиясен дә, энциклопедик басмаларны да, милли гуманитар фәннәр өлкәсендә эшли торган үзәкләрне дә, киностудия һ.б. фән, мәгариф, мәдәният институтларын да булдыруны чикли. Мондый тигезсезлек киң татар җәмәгатьчелегендә көчле ризасыз-

М.Козловский фотосы

лык тудыра. Шуңа күрә 80 нче еллар ахырында оешкан милли хәрәкәт төп максат итеп Татарстанга союздаш республика статусын алуны билгели һәм, әйтергә кирәк, бу лозунг татар халкының барлык катламнарында киң яклау таба. Кыска вакыт эчендә Татар иҗтимагый үзәге (ТИҮ), Татарстанга союздаш республика статусын таләп итеп, бер миллионнан артык имза җыйды. 1989 елның көзендә шушы таләпне яклап имзаланган кәгазьләр, беркетмәләр Мәскәүгә СССР халык депутатлары съездына илтеп тапшырылды. Татарстан халкының үз республикасына союздаш статус таләп итүе хакында сүзләр СССР халык депутатлары съездында яңгырады.

Советлар берлегендә күзәтелгән кискен үзгәрешләр, татар милли хәрәкәтенең көчле күтәрелеше, милли республикаларның бер-бер артлы суверенлык игълан итүләре илдә яңа вазгыять тудырды. Татарстан халкы һәм республика җитәкчелеге статус мәсьәләсен кемнәндер сорап түгел, ә үз ихтыярың белән хәл итеп булуын аңлый. Шуны истә тотып, 1990 елның 30 августында Татарстан Югары Советы депутатлары «Татарстан суверенитеты турында Декларация» кабул итәләр. Ул Декларациядә Татарстан мөстәкыйль дәүләт, Россия Федерациясе белән тигез хокуклы мөнәсәбәтләр коручы халыкара хокук субъекты дип игълан ителә. 1990 елның 30 август көне — һичшиксез, татар халкы тарихының иң мөһим даталарының берсе, шул көннән татар дәүләтчелегенең яңа тарихы башлана.

Кайвакыт: «Суверенитет безгә нәрсә бирде?» — дигән сүзләр ишетергә туры килә. Татарстан суверенитеты өчен алып барган көрәшебез милләттәшләребезне нык үзгәртте. Татар кешесенә горурлык хисе кайтты, ул гасырлар буе изелеп килгән кавемгә хас мескенлектән арынды, җилкәләрен турайтты, үзен дөнья халыклары белән тигез итеп тоя башлады. Мондый зур үзгәрешләр кешене канатландыра, аңа рухи көч бирә. Төрле төбәкләрдә гомер итүче милләттәшләрем белән аралашкан-

да, фикерләшкәндә уңай үзгәрешләр күзгә нык ташлана, күренә иде.

Бөтендөнья татар конгрессы да буш җирлектә оешмады, аның нигезен киң милли иҗтимагый хәрәкәт тәшкил итте. Татарстан суверенитеты турында Декларация киң татар дөньясы белән хезмәттәшлек итү, ерак җирләрдә яшәүче татарлар белән мәдәни бәйләнышларга юл ачты. Шуның нәтиҗәсе булып Бөтендөнья татар конгрессы оешты. Бөтендөнья татар конгрессының I съезды 1992 елның 19 июнендә Казанда ачылды. Ул съездда Россиянең төрле төбәкләреннән һәм дөньяның төрле илләреннән килгән меңнән артык делегат катнашты, һәм ул бик күтәренке рухта узды. Олуг җыенда катнашучылар Казанны халкыбызның рухи мәркәзе, татар дөньясының башкаласы дип таныды. Ә бу берләшү өчен бик мөһим фактор. Бөтентатар иҗтимагый үзәге рәисе Марат Мөлеков корылтай трибунасыннан: «Бөтендөнья татарлары, берләшегез!» — дигән шигарь яңгыратты. Әлбәттә, Бөтендөнья татар конгрессының беренче корылтае бик күтәренке рухта узды. Ул съездда кабул ителгән документлар бик зур тарихи әһәмияткә ия, алар татар халкы дәүләтчелеген торгызу, татарның телен, мәдәниятен, мәгарифен, гореф-гадәтен саклау мәсьәләләрен күтәрә, татар халкын бердәмлеккә чакыра. I съездда Конгрессның җитәкче органнары сайлана: 25 кешедән торган Бөтендөнья татар конгресс Башкарма комитеты, ә Башкарма комитет рәисе итеп танылган тарихчы, КДУ профессоры, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Индус Таһиров тәгаенләнә.

Бөтендөнья татар конгрессының II съезды 1997 елның августында узды. Әйтергә кирәк, илдәге вазгыять инде шактый үзгәргән иде. Әгәр I съезд илдәге киң демократик үзгәрешләр шартларында узса, II съездга Россиядәге сәяси көчләр балансы башка иде. Мәгълүм булганча, 1993 елның ахырына хәтле Россиядә башкарма хакимият белән законнар чыгару хакимияте арасында баланс булса, билгеле вакыйгалардан соң (парламентны утка тотып тарату, яңа конституцияне гамәлгә кертү һ.б.) ул баланс юкка чыкты. 1997 елда Россиядә башкарма хакимият өстенлеге бик нык сизелә иде. Шуңа да карамастан, Татарстан һәм татар халкы ирешелгән дәүләтчелек позицияләреннән чигенмәс өчен бик зур тырышлык куйды. Әйтик, БТКның II съездында татар язу системасын латин графикасына күчерү турында карар кабул ителде. Гомумән, татар телен дәүләт теле статусында гамәлгә кую турында бик җитди сөйләшү булды. Татар тарихын объектив яктырту турында да саллы чыгышлар яңгырады. Бу юлы төбәкләрдәге татар оешмаларының уңышлы эшләп китүләре сизелде. Чит илләрдән килгән милләттәшләрнең чыгышларында Татарстанга кайту теләге яңгырады. Шунысын да әйтергә кирәк: СССР таркалганнан соң, чит илгә әверелгән элеккеге совет республикаларында 2 миллионга якын татар калды һәм аларның язмышы халкыбыз өчен җитди проблема булып тора. Ә Россия законнары бу мәсьәләдә бик кырыс: тарихи Ватаннарына кайткан милләттәшләребез еллар буе урнаша алмый интегә.

БТКның II съездында илдәге демократик рух әле сизелә иде. Бөтендөнья татар конгрессының II съездына уңышлар теләп, Россия Президенты Борис Ельцин һәм хөкүмәт рәисе Виктор Черномырдин котлау телеграммалары җибәргән иде. II съезд эшчәнлегендә Россия хөкүмәте рәисе урынбасары Рамазан Абдуллатыйпов та катнашты.

Нишлисең, татар язмышы Россиядәге сәяси вазгыятькә бик тыгыз бәй-

ләнгән. Илдә демократия урнашканда, татар тормышы да гөрләп чәчәк ата, халык иркенрәк сулый башлый, хәрәкәткә килә. Бөтендөнья татар конгрессының да илдәге демократик үзгәрешләр җимеше икәнен танырга кирәк. Әгәр ул 20 ел дәвамында эшләп килә икән, димәк, илдә дә демократия яши, саклана дигән сүз.

Бөтендөнья татар конгрессының III съезды 2002 елның 29 августында «башка төрле демократия» шартларында узды, ул шартлар Россиядә «суверен демократия» дип аталды. Яшерен-батырын түгел, БТК эшчәнлегенең асылы читтә яшәүче татарларның, аларның оешмаларының Татарстан Республикасы белән хезмәттәшлек коруыннан, халыкның бердәмлеген ныгытудан гыйбарәт. Бу чорда шулай ук милли мәгарифне кысу сәясәте дә башлана. «Федераль стандартлар» кертү сылтавы белән илнең мәгариф системасыннан «милли мәктәп» төшенчәсе гомумән алып атыла. Федераль мәгариф җитәкчеләре ачыктан-ачык: «Россиядә бернинди татар, башкорт, чуваш мәктәбе була алмый, биредә фәкать Россия мәктәбе генә була ала», — дип сөйли башлый. Шулай ук 2002 елда Дәүләт Думасы рус булмаган халыкларга фәкать кириллхәрефләре белән генә язу рөхсәт ителү турында закон кабул итте.

Әлбәттә, бу юлы корылтайның рухы татар халкы тарафыннан Татарстан Республикасын яклауга юнәлтелгән була. Чыгыш ясаучы делегатларның һәрберсе татар халкы дәүләтчелеген, федерализм принципларын яклап сөйли. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев тә Татарстанның аерым статусы, федераль хакимиятләр белән төзелгән Шартнамә һәм аның нигезендә нәрсәләр эшләп булуы турында чыгыш ясый, халкыбызны бердәмлеккә өнди.

БТКның III съезды бик үзенчәлекле вакыйга белән тәмамлана — 30 август — Татарстан Республикасы көнендә — Казан Кремлендә съезд делегатлары Россия Президенты В.В.Путин белән очраша. Бу очрашуда съезд делегатлары милләт язмышына бәйле бик мөһим проблемалар күтәрәләр. Шушы очрашу нәтиҗәләреннән чыгып, Владимир Путин Россия хөкүмәтенә дүрт пункттан торган Әманәт (поручение) юллый. Әйтергә кирәк, Президент әманәтләренең берсе — Мәскәүдәге Әсәдуллаев йортын татар милли-мәдәни үзәгенә тапшыру мәсьәләсен уңай хәл итте.

III съездда Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетына яңа рәис — Ринат Закиров сайлана. III съезддан соң Татар конгрессы, илдәге катлаулы вазгыятьне истә тотып, яңа стратегия алып баруга күчә: милли хәрәкәтне конкрет эшчәнлек, конкрет проектларны тормышка ашыру белән тулыландыруны максат итеп куя. Бу проектларның беренчесе татар яшьләре хәрәкәтен гамәлгә кую булды. I Бөтендөнья татар яшьләре форумы 2004 елның җәендә Казанда җыела, анда Татарстаннан, Россия Федерациясе төбәкләреннән һәм чит илләрдән 600 делегат катнаша. Әлбәттә, бу татар яшьләренең беренче җыены танышу, аралашу, үзара элемтәләр урнаштыру максатын күздә тота һәм делегатлар шушы максатка ирешеп таралышалар. Шунысын да әйтеп китү мөһим: I Татар яшьләре форумына очраклы кешеләр дә килгән иде, аларның кайберләре хәтта яшьләрне милләтчелектә гаепләп тә маташтылар, әмма бу яхшы сабак та булды, чөнки алдагы форумнарга инде әзерлекле, милли рухлы яшьләр чакырылды. 2012 елда татар яшьләре форумнарының инде бишенчесе узды һәм иң куанычлысы — һәр яңа форумга берсеннән-берсе әзерлекле, уңган яшьләр килә башлады. Алар

арасында үзләрен фән өлкәсендә дә, спортта да, әдәбият-сәнгатьтә дә, эшмәкәрлектә дә күрсәткән татар яшьләре күп. Ә милләтнең киләчәге, һичшиксез, яшьләр кулында.

БТКның яңа эш стратегиясе татар халкының барлык катламнары белән эш алып баруны күздә тотты. Шул максаттан чыгып, 2006 елның язында Казанда IV Бөтенроссия татар теле укытучылары һәм милли мәгариф хезмәткәрләре җыелды. Ә милли мәгариф өлкәсендә эшләр шактый катлауланган иде. Федераль мәгариф органнары, Россия Федерациясе Конституциясен инкарь итеп, илдәге халыкларның милли мәктәп системасын бетерүгә керештеләр. Әлбәттә, милли мәгарифкә каршы алып барыла торган хөкүмәт сәясәте Россия халыкларында зур ризасызлык тудырды. Мондый вазгыять шартларында татар җәмәгатьчелеге һәм Татарстан җитәкчелеге, башка республикаларны җәлеп итеп, милли мәгарифне яклау чараларын уздырып карады. Әйтик, 2007 елның язында Татарстан Дәүләт Советы, Россия Федерациясе республикалары вәкилләрен җыеп, Казанда милли мәктәп мәсьәләсенә багышланган зур конференция уздырды. Анда Мәскәүдәге федераль министрлыктан килгән җаваплы чиновниклар да катнашты, һәм шунда бер бик мөһим нәрсә ачыкланды. «Милли мәктәп — ул Россияне таркатучы этносепаратизм чыганагы», — дип әйтте Мәскәүдән килгән түрә ханым. Шулай итеп, милли мәктәпләрне таркату галәмәте бик тирәннән килә торган сәясәтнең бер өлеше булуы ачыкланды.

Гомумән, Бөтендөнья татар конгрессының эшчәнлеге төрле проблемаларны чишүдән гыйбарәт. Алар арасында шактый катлаулылары да бар, шуларның берсе — Башкортстан татарлары мәсьәләсе һәм татар-башкорт мөнәсәбәтләре. СССРда үзгәртеп кору башлангач, алар турында ачыктан-ачык сөйләшү мөмкинлеге туды. Әлбәттә, татар-башкорт мөнәсәбәтләре проблемасының тарихи тамырлары бик тирән. Идел-Урал төбәген яулап алгач, патша хакимияте җирле халыкларны бер-берсенә каршы кую сәясәтен тормышка ашыра. Башкорт сословиесе булдырыла һәм аңа төрле икътисади өстенлекләр бирелә. Әлбәттә, шул өстенлекләргә кызыгып, башкорт сословиесенә башка халык вәкилләре, шул исәптән татарлар да языла башлый.

Мәгълүм булганча, 1920 елда В.Ленин декреты белән Татарстан Республикасы булдырыла һәм аның составына Казан, Уфа, Вятка, Самара губерналарының аерым өязләре кертелә. Уфа губернасының Минзәлә өязе Татарстанга кушыла, ә аның татарлар күпләп яшәгән өязләрендә кайсы республикага керү турында референдум узарга тиеш була. Әмма большевиклар, үз вәгъдәләрен бозып, бернинди сораштыру уздырмыйча, 1 миллионнан артык татарны кече Башкортстанга кушып, хәзерге чикләрендәге Башкортстан Республикасын төзиләр. Менә шулай, халык теләген исәпкә алмыйча гамәл кылу, милләтара мөнәсәбәтләрнең киеренкелегенә китерә. Нәтиҗәдә, Башкортстанда республикага исем биргән, титул халык булган башкортлар азчылыкта кала, 21% кына тәшкил итә. Әлеге санны «арттыру» максатыннан, 1979 елгы халык санын алуда Башкортстан җитәкчелеге татарларны башкорт итеп яздыруга күп көч куя, шушы максатта административ басымны киң куллана. Ул елны, формаль рәвештә булса да, 300 мең татарны башкорт милләтенә «өстиләр». Ә 1989 елда халык санын алу бернинди административ басымсыз, ирекле рәвештә уза, һәм бу юлы 300 мең кеше татарлар санына кушыла. 2002 елгы халык

санын алу Башкортстанда яңадан басым астында уза, янә 300 мең татар башкорт милләтенә «күчә».

Яшерен-батырын түгел, татар-башкорт мөнәсәбәтләре, 2002 елда аеруча бозыла һәм, танырга кирәк, монда татар милли хәрәкәте радикаллары да үз өлешен кертә. Бөтендөнья татар конгрессы III съездына кунак булып Башкортстан Президенты килә, съездда чыгыш ясый. Ә икенче көнне Россия Президенты В.В.Путин белән очрашу вакытында, Башкортстан татарлары вәкиле андагы вазгыятьне кискен тәнкыйтьләп чыгыш ясый. Шушы вакыйгадан соң Башкортстанда татар-башкорт аралары бик нык бозыла, татар хәрәкәтендә дә, башкорт хәрәкәтендә дә радикаллар өстенлек ала һәм шуңа бәйле рәвештә ике халык арасындагы мөнәсәбәтләр бозылганнан-бозыла бара.

2007 елда Бөтендөнья татар конгрессның IV съездына әзерлек алып барганда, Башкарма комитет җитәкчелеге Башкортстандагы каршылыклы хәлләрне үзгәртү турында уйлана башлый. Чынлап та, биш ел барган үзара аңлаша алмау халыкка да, гади кешеләргә дә һичнинди файда китерми, киресенчә, зыян гына сала. Шушы вазгыятьне үзгәртү максатыннан, Башкортстанга БТК вәкилләре йөри башлый, халык белән очраша, Башкортстан һәм Башкорт корылтае вәкилләре белән сөйләшүләр алып бара. Башкортстандагы татар милли хәрәкәтенә яңа кешеләр җәлеп ителә. Шулай итеп, БТКның IV съездына Башкортстаннан радикалларны да, төпле фикерле шәхесләрне дә үз эченә алган делегация килә. Нәтиҗәдә, БТКның IV съезды татар һәм башкорт халыкларына мөрәҗәгать кабул итә, ике халыкны һәм аларның республикаларын дустанә мөнәсәбәтләр торгызырга чакыра.

Шөкер, бүген Татарстан белән Башкортстан арасында дуслык, кардәшлек мөнәсәбәтләре яңадан торгызылды. Ике республика президентлары даими очрашып торалар, Уфада Татарстан Республикасы даими вәкиллеге ачылды, «Татарстан — Яңа гасыр» телеканалының Башкортстандагы хәбәрчеләр пункты эшли башлады, әлеге каналның тапшыруларын бүген бөтен Башкортстанда карап була. Ике республиканың да иҗат төркемнәре күпсанлы гастрольләр оештыра. Кыскасы, ике тугандаш халыкның мәдәни бәйләнешләре тагын да ныгыды.

Әлбәттә, ике халыкның уртак проблемалары да җитәрлек. Шул ук милли мәгариф мәсьәләләре бүген Россия Федерациясенең барлык халыкларын да борчый. Шуларны истә тотып, Бөтендөнья татар конгрессы Бөтендөнья башкорт корылтае һәм Идел-Урал төбәгендә яшәүче халыкларның иҗтимагый оешмалары белән бергә берничә киңәшмә уздырды. Идел-Урал халыклары вәкилләре, милли мәктәпне яклап, уртак белдерү белән дә чыктылар. Менә шулай, милли мәсьәләләр, аларны хәл итү проблемасы, телисеңме-теләмисеңме, дәүләтнең милли сәясәтенә килеп терәлә.

Инде мең елдан артык Ислам дине халкыбызның иң ышанычлы терәге, рухи ныгытмасы булып тора. Туган телебез белән Ислам дине — татар кешесенең төп билгесе. Совет чорында дин зур югалтуларга дучар булды. Казанда эшләп торган бер Мәрҗани мәчете, ә Татарстанда нибары 13 мәчет калган иде. Шөкер, инде ике дистә елдан артык вакыт халкыбыз рухи яңарыш кичерә, иманга кайта. Бүген республикабызда 1 мең 500 мәчет эшли, башкалабызда аларның саны 60тан артып китте. Татарстанда һәм башка төбәкләрдә дистәләгән мәдрәсәләр ачылды, менә инде 15 ел Казанда Россия Ислам университеты

уңышлы гына эшләп килә. Шулай итеп, безнең инде гыйлем ягыннан шактый әзерлекле мөселман руханиларыбыз үсеп чыкты. Болар барысы да халкыбызның киләчәгенә өмет белән карарга мөмкинлек бирә.

Халыкның рухи тормышы — бик катлаулы өлкә, аның меңләгән нечкәлекләре бар. Халыкны ышандырам, әйдәп-ияртеп барам, үгет-нәсыйхәт бирәм дисәң, үзең бик иманлы, ихлас, инсаф булырга тиешсең. Хәзрәтләребез шушы хакта күбрәк уйлансыннар иде. Яшерен-батырын түгел, дин өлкәсендәге таркаулык үзен нык сиздерә. Бер заманны кайбер хәзрәтләребез үзара аралашуны туктатканнар иде. Уйлап карагыз, бүген Россия төбәкләрендә 70кә якын мөфти хәзрәтләре исәпләнә. Кечкенә генә Мордовия Республикасында дүрт Диния нәзарәте бар, һәрберсе юрганны үз өстенә тарта. Кыскасы, дин өлкәсендәге таркаулык татар халкының гомуми бердәмлегенә бик нык комачаулый, зыян сала.

Менә шуларны истә тотып, Бөтендөнья татар конгрессы 2005 елның җәендә «Татар җәмгыятендә Ислам яңарышы» дигән фәнни-гамәли конференция уздырды. Бу чара дин әһелләребезнең аралашуга, фикер алышуга бик сусаган булуын раслады. Россиянең төрле төбәкләреннән килгән татар имамнары ике көн дәвамында якыннан аралашты, җуелган дуслык җепләрен яңадан булдырды. Бөтендөнья татар конгрессы, беркемгә дә басым ясамыйча, дин әһелләренә аралашырга, фикер алышырга мәйдан бирде. Шушы конференциядә БТК Башкарма комитеты каршында Дин эшләре буенча комиссия корырга карар кабул ителде. Бүген бу комиссияне танылган галим, Россия Ислам университеты ректоры, ТФАнең мөхбир-әгъзасы Рафыйкъ Мөхәммәтшин җитәкли.

Күрәбез ки, дини яңарыш мәсьәләсе милләтне саклау проблемалары белән үрелеп бара. Шуңа да тагын бер борчулы күренеш турында әйтмичә булмый. Кайбер татарлар яшәгән төбәкләрдә мәчетләрдән татар теле кысрыклап чыгарыла. Моның белән һич килешеп булмый, мәчетләргә йөрүче мөселманнарның шактый өлеше төрки халык вәкилләре, алар татарчаны яхшы аңлый. Икенчедән, мондый гамәл яшьләребезгә дә начар тәэсир итә, аларны миллилектән, татарлыктан читләштерә. Үз халкыңны, аның телен хөрмәт итмәү — бик яман сыйфат, дөресен әйткәндә, тәрбиясезлек. Шуңа күрә Бөтендөнья татар конгрессы барлык мөселман уку йортларында татар телен җиренә җиткереп укытуны кирәк дип саный һәм бу юнәлештә максатчан эш алып бара.

Гомумән, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының дини оешмалар белән хезмәттәшлеге елдан-ел ныгый, үсә бара. Моның нәтиҗәсе буларак, бик күп матур чаралар гамәлгә куелды. 1988 елдан башлап мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин җитәкчелегендәге Үзәк диния нәзарәте Изге Болгар җыеннарын уздырып килә иде. 2007 елда бу чараны уздыру эшенә Бөтендөнья татар конгрессы да кушылды. Шул вакыттан бирле әлеге чара бөтен Россия күләмендәге зур җыенга әверелде. Соңгы елларда бу бәйрәмдә илнең төрле төбәкләреннән килгән 40-50 мең кеше катнаша. Мәгълүм булганча, Татарстан парламенты Идел Болгарстанында рәсми рәвештә Ислам динен кабул итү көнен (21 май) бәйрәм дип игълан итте. Бу бәйрәмне халкыбыз, республика җәмәгатьчелеге зур канәгатьлек белән бәйрәм итә.

Барыбыз да күреп торабыз, Татарстан җитәкчелеге дини мәсьәләләргә игътибарны бик нык арттырды.

2010 елда Бөтендөнья татар конгрессы хөкүмәт ярдәме белән I Бөтенроссия татар дин әһелләре форумын җыйды, ул бик уңышлы узды. Хәзрәтләребез «мондый дини мәҗлесләрне ел саен уздырыга кирәк», дигән теләк белдерделәр. Татарстан җитәкчелеге дә мондый ниятне хуплады. Быел 900дән артык имамнарыбыз инде өченче тапкыр Казанда җыелды. Бу форум да уңышлы үтте, хәзрәтләребез фикер алышты, каршылыклы мәсьәләләрне уртага салып сөйләште. Мондый очрашулар таркаулыкны киметә, рухи бердәмлеккә хезмәт итә.

2008 елда Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты каршында Бөтенроссия татар авыллары ассоциациясе оешты. Уйлап карагыз, бүген Россиядә зур көче һәм милләтнең таянычы булган 4 меңнән артык татар авылы бар. Татар авылларында халкыбызның теле дә, дине дә, гореф-гадәтләре дә саклана. Алар арасында диндар, иманлы, эш сөючән халкы белән бөтен милләтебезгә үрнәк булырлыклары да байтак. Шундый бөтен илдә дан тоткан татар авыллары исемлегендә Пенза өлкәсенең Урта Әләзән, Самара өлкәсенең Гали, Түбән Новгород өлкәсенең Рбишча, Сафаҗәй, Мордовиянең Әзюркә, Чувашстанның Шыгырдан, Урмай, Тукай авылларын, Киров өлкәсенең Иске Йөрек, Оренбург өлкәсенең Алабай тал авылларын атар идем. Шушы авыллар тәҗрибәсе киләчәктә татар авылын эшмәкәрлек яшәтәчәген раслый. Аларның һәрберсе Рәсәй базарында үз урынын тапкан. Әйтик, Урта Әләзән халкы көнбагыш үстерә. Гали авылында халык, теплицалар корып, яшелчә, кыяр-помидор үстерә, аны шәһәрләргә озата. Шыгырдан, Тукай авыллары терлек асрый, ит сата. Бу авылларда хәләл ризык җитештерүче ширкәтләр эшли, аларның продукциясен шәһәрләрдә бик теләп алалар.

Россия төбәкләрендәге уңышлы татар авыллары тәҗрибәсе Татарстан җитәкчелегендә дә кызыксыну уятты. 2010 елда Самара өлкәсенең Гали авылында узган I Бөтенроссия авыл Сабан туенда Татарстан Президенты Р.Н.Миңнеханов та катнашты. Гали авылы тәҗрибәсен бөтен татар дөньясына, шул исәптән Татарстанга да таратырга кирәклеге турында басым ясап әйтте. Бу вакыйгадан соң ике ел вакыт узды, Татарстанда бүген 900дән артык гаилә фермасы эшли. Димәк, авылларыбыз киләчәгенә без өмет белән карый алабыз. Әгәр авылда тормыш шушы юнәлештә киткән икән, димәк, җир мәсьәләләрен дә яңача хәл итәргә кирәк булачак. Җирсез кеше авылның төпле нигезе була алмый.

Гомумән, бүген татар тормышында нык җанлану күзәтелә. Россиянең 70тән артык төбәгендә, дөньяның 24 илендә уза торган Сабан туе бәйрәмнәре, татарча көрәш турнирлары, махсус оештырылган ат чабышлары, Бөтенроссия татар фольклоры фестивальләре, «Татар кызы», «Татар егете» бәйгеләре — мондый чаралар милли мәдәният өлкәсендә, төбәкләрдәге татарлар тормышында яңа күренешләр буларак бәяләнергә хаклы. Иң мөһиме, милләтебезнең иманы чиста, рухы нык, киләчәккә өмет белән карый. Мин горурланып әйтә алам, дөнья татарлары үзләренең чираттагы җыенына — Бөтендөнья татар конгрессының V съездына зур күтәренкелек белән әзерләнә. Шигем юк, бу зур чара халкыбыз тарихына яңа бер якты сәхифә булып кереп калачак. Без ерактан киләбез, барасы юлыбыз да әле бик ерак. ■

ТАТАРНЫ САНАУ

ДАМИР ИСХАКОВ,
тарих фәннәре докторы

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БИК КҮПТӘННӘН КИЛГӘН «САНСЫЗ» ДИГӘН ТӨШЕНЧӘ БАР, АНЫҢ БЕРЕНЧЕЛ МӘГЪНӘСЕ — «ИСӘПКӘ АЛЫНМАГАН», ШУҢА КҮРӘ — «ТӘРТИПСЕЗ», Ә ИКЕНЧЕСЕ — «САНАП БЕТЕРГЕСЕЗ КҮП».

Бу мәгънәләр икесе дә халыкны исәпкә алу белән бәйле, чөнки «саналмаган» кеше Алтын Урда дәверендә үк «эшкә яраксыз, рәтсез» булган, ә «санап бетергесез күп» булу, билгеле, санаучылар тарафыннан колачлап булмый торган нәрсәне билгеләгән, ул әйбернең, күренешнең «санау» юлы белән бер тәртипкә кертелә алмаганлыгын күрсәткән. Мәсәлән, Нугай Урдасының иң көчле дәверендә, аның халкы 1 млн кешедән артык булган чорда, «сансыз нугай» дигән гыйбарә булганлыгы билгеле. Күренә ки, халкыбыз күп гасырлар дәвамында саналып килгән һәм Россия тарихында да татарны исәпкә алу яңа нәрсә түгел.

Шулай да, Советлар Союзы таркалганнан соң, Россия Федерациясендә халыкны исәпләү әле ике генә тапкыр булды. Беренчесе, билгеле булганча, 2002 елны, икенчесе — 2010 елны. Бу ике хисапның беренчесе турында инде аналитик язмалар басылды, ә 2010 елгы исәп буенча әле тәшвишләп язылган мәкаләләр күренмәде. Шуны исәпкә алып, мин бу эшкә алындым да. Әле бүген соңгы исәп турындагы тулы мәгълүматлар дөнья күрмәде, шунлыктан, тәкъдим ителгән анализ бераз гомуми рәвештәрәк ясалыр. Ул барыбер әһәмиятле, чөнки татар демографиясенең кайсы якка барганлыгын алардан инде чамалап була.

Иң башлап шуны күрсәтергә кирәк: 2010 елгы җанисәп алдыннан шул акциягә багышланган Россиядә чыккан мәкаләләр 2002 ел белән чагыштырганда ике тапкыр азрак булып, Татарстан прессасында да бу турыдагы язмалар һәм дискуссияләр күпкә кимрәк күренгән (карагыз: Ходжаева Е. Перепись как проблема: анализ общероссийской и татарстанской русскоязычной прессы 2002 и 2010 годов // Ab imperio, 2010, №4). Социологлар моның сәбәпләрен 2010 елга җәмгыятьнең «тынычлануы» белән аңлаталар, ә Татарстандагы җанисәп тирәсендәге язмаларның аз һәм кыюсыз булуларын республика җитәкчеләренең милли якны «уйнатудан» туктаулары һәм Мәскәүнең кул астына күбрәк керүләре белән бәйлиләр. Чынлыкта эш анда гына түгел. Беренчедән, 2002 елгы халыкны исәпкә алу нәтиҗәләреннән күренгәнчә, татарны этник төркемнәргә бүлергә тырышу барып чыкмады, шуңа күрә, соңгы җанисәп алдыннан җәмәгатьчелек бу турыда әллә ни борчылмады, сәясәтчеләр дә федераль органнарга бу мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итмәделәр. Икенчедән, 2002 елгы татар мәсьәләсе тирәсендәге зур шау-шуны берничә актив татар галиме оештырган иде. Татарны саклап

калу өчен көрәш күбрәк Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җилкәсенә төште һәм ул оешма милләт үзаңын ныгыту өчен мөмкин булганның барысын да диярлек эшләде. Дөрес, конгрессның кулы җитмәгән урыннар да калды, шуңа күрә кайбер төбәкләрдә нәтиҗәләр бик үк уңышлы булмады.

Инде килеп, 2010 елгы исәп турында төгәлрәк сөйләшүгә күчкәндә, ил күләмендә аны оештыруның кайбер тискәре якларын күрсәтү кирәк булыр. Беренчедән, тар даирәдә, билгеле булганча, бу җанисәп вакытында эре шәһәрләрдә күп кеше исәп алучыларны өйләренә кертмәгән. Андыйларның саны 3,6 млн, ягъни ил халкының 2,5%ы, ә кайбер санаулар буенча 5,6 млн кеше (Русия халкының 3,7%ы). Бәлки бу халыкның бер өлеше җанисәп анкетасын телефон аркылы тутырганнардыр. Югарыдагы кешеләр турында мәгълүмат полиция (милиция) чыганаклары аркылы җыелган, ләкин ул чыганакта хәзер милләт күрсәтелми, туган тел турында да белеп булмый. (Ул турыда телефон аркылы сорашып җавап алырга ярамый.) Билгеле, мондый күренеш җанисәпкә бик үк ышанырга ярамаганлыгын күрсәтә. Нәкъ шуңа күрә дә федераль органнарда хәзер сүз җанисәп вакытында аңа катнашуны мәҗбүри итү турында бара. Шушы ук нәтиҗә татарга да кагыла, чөнки аның да күпчелеге шәһәрдә яши. Икенчедән, хакимият вәкилләре «илдә бала күп туа», башлады дип сөйләнсә дә, 2002-2010 еллар арасында илдә халык саны 2,3 млн кешегә (бөтен халыкның 1,6%ы) кимегән. Сан ягыннан арткан халыклар да бар, ләкин татарлар алар арасында түгел, безнең халык бу яктан русларга якынрак. Русларның саны ике җанисәп арасында 4,3%ка кимегән, бу 4 млн 870 мең кешегә дигән сүз. Әлеге саннар бала тууга караганда, үлүчеләрнең күбрәк булуы турында сөйли. Күренә ки, тискәре демографик күренешләр илдә һаман да яши.

Татарларның саны турында әйтеп үтик. Билгеле булганча, 2002 елны РФ чикләрендә 5,5 млн татар исәпкә алынган иде. 2010 елгы исәп илдә татарның санын 5,3 млн дип күрсәтте, димәк, халкыбыз 200 меңгә, төгәлрәге, 240 мең кешегә кимегән. Билгеле, Кавказ халыклары белән чагыштырганда (чеченнар — 70 меңгә, аварлар — 100 меңгә, кумыклар — 80 меңгә, даргиннар 80 меңгә арткан) һәм хәтта якутлар һәм бурятлар белән чагыштырганда (беренчеләре — 40 меңгә, икенчеләре 10 меңгә арткан) безнең демографик күрсәткечләр тискәре. Моның берничә сәбәбе бар. Иң әһәмиятлесе — әйтеп үткәнемчә, татарда бала туу җитәрлек түгел, үлүчеләр күбрәк. Башка сәбәпләрне күрсәтү дә кирәк. Әйтик, үткән җанисәп алуда, ягъни 2002 елда, минем исәпләвемчә, Башкортстанда 200 мең чамасы татар башкорт итеп язылган иде. 2010 елны Татарстан ягыннан «тартып алынган» милләттәшләребезне кире кайтару өчен эш җитәрлек булмады. Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты тырышып карады, ләкин, аның кулында мөмкинлекләр аз булу сәбәпле, аңлату-пропаганда эшләре сүлпән барды. Ә Башкортстан ягы халыкны пропагандалауны (чынлыкта алдауны) нык оештырды. Әле хәзер дә андый эшчәнлекнең тукталганы юк. Нәтиҗә шундый: минемчә, башкорт «йоткан» милләттәшләребезнең 40%на якыны гына татар булып язылды, шуңа күрә 140-150 мең татар әле хәзер дә «башкорт» булып исәпләнә дип уйларга урын бар. Димәк, безнең кимүебезнең тагын бер сәбәбе — татарны «башкортлаштыруда». Хәлбуки, башкортлар да 2002-2010 еллар арасында 90 меңгә кимегән, бу кимү, татар «йотылмаса», күпкә артыграк булыр иде.

Тагын бер сәбәп — инде күрсәтелгәнчә, шәһәр халкының бер өлеше стандарт исәп процедурасын үтмәгәнлектә. Ягъни, шәһәрдә яшәүче-

ләр физик яктан бар (3,6 млн кешедән 4,9 млн кешегә кадәр), ләкин аларның милләте һәм туган теле билгеле түгел. Шушы зур төркемдә татарлар да аз түгелдер дип уйлый алабыз.

Соңгы сәбәп — татарларның ассимиляцияләнүе. Ул бигрәк тә катнаш никахлы гаиләләрдә көчле. Катнаш никахлар татарларда, дөресен әйтик, шактый киң таралган: әгәр дә бер милләт вәкилләре корган гаиләләр саны 2002 елда татарларда 1 млн 112 мең булса, 2010 елны аларның саны кимегән — 1 млн 59 меңгә калган, димәк, катнаш никахлар күбәя бара. Әлбәттә, катнаш никахлы гаиләләрдә милли аң көчле булса, балаларны татар үзаңлы итеп тәрбияләргә мөмкин. Ләкин, күпчелек күзәтүләр буенча (социологик тикшерүләр дә шуны раслый), катнаш никахлы гаиләләрдә тәрбияләнгән татарлар нигездә «эретүчеләр» түгел, ә «эрүчеләр». Шундый демографик закон бар: ике халык вәкиле никахлашса, ахыр чиктә сан ягыннан күбрәк булган халык ота. Бездә исә күпчелек катнаш никахлар руслар белән корылган… Бәлки, дин йогынтысы көчәйсә, бу өлкәдә хәлләр бераз уңай якка үзгәрер.

Шулай итеп, 2010 елгы җанисәп Россиядә татар милләтенең саны кими барганлыгын күрсәтте. Бу күренеш берничә фактор йогынтысында формалаша. Безнең уебызча, аның нигезендә балаларның аз тууы гына түгел, ә ассимиляция йогынтысының көчле булуы мөһим роль уйный. Бу тенденция үзгәрмәсә, берничә ел элек бер төркем татар демографлары ясаган фараз — 2025 елга татарларның саны 0,5 млн кешегә кимиячәк дигән фикер иртәрәк тә тормышка ашарга мөмкин.

Хәзер татарны «бүлгәләү» мәсьәләсенә тукталыйк. 2010 елгы җанисәп нәтиҗәләре күрсәткәнчә, хакимиятнең бу юнәлештә алып барган сәясәте барып чыкмады. Нәтиҗә түбәндәге саннар белән раслана:

2010 елда аерым этник төркем буларак язылган татарлар:

керәшеннәр	34822 кеше
нугайбәкләр	8148 кеше
себер татарлары	6779 кеше
мишәрләр	786 кеше
болгарлар	719 кеше

Күренә ки, татар милләтеннән «бүленеп чыгарга» теләүчеләрнең саны 51,3 мең кеше чамасы гына, ягъни Россиядә яшәгән милләттәшләребезнең 1%тан кимрәге. Димәк, татарлар бүленергә һәм таркалырга теләми, аларда милли аң нык. Керәшен татарларының, 2002 ел белән чагыштырганда, саны артуны болай аңлатыр идем. Чынбарлыкта, рәсми җанисәп мәгълүматларына караганда, керәшеннәрнең күбрәк өлеше татарлар теркәлгән. Бүген керәшеннәрнең һәм нугайбәкләрнең (соңгылары да православие динен тотучы татарлар) саны артуы табигый күренеш. Чөнки татарның мөселман үзаңы үскән саен, православие динен тотучы милләттәшләребез үзләрен башка этно-мәдәни төркем дип билгелиләр. Кызганыч, 2010 елгы җанисәп вакытында керәшеннәр мәсьәләсе буенча аңлату эшләре алып барылмады диярлек.

Шунысы игътибарга лаек: 2002 ел белән чагыштырганда, себер татарлары булып язылучыларның саны кимеде. Моны, беренче чиратта, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының һәм аерым галимнәрнең максатчан эшләүләре нәтиҗәсе белән бәйләп карарга мөмкин. Бар җиргә дә кулы җитмәсә дә, Бөтендөнья татар конгрессы һәм аның Этнологик мониторинг үзәге Себердә яхшы гына эшләде, җанисәп барышында андагы процессларга йогынты ясый алды. Себер татарлары арасында безнең бер милләт булуыбызны аңлау артты. Ә бер милләт эчендә төрле этник төркемнәр булырга мөмкин, мисалга инглизләрне һәм испаннарны китереп була. Милли аң берникадәр дәрәҗәдә галимнәр

катнашы белән дә «ясала». Минем Себердә этнология буенча кандидатлык диссертациясен уңышлы яклаган ике шәкертем эшли, тагы ике аспирантым диссертацияләрен язып ята. Фәнни хезмәттәшлек иткән галимнәр, зыялылар, милләт мәнфәгатен үзәккә куеп, фикер йөртәләр. Бу Себер татарларында да шулай. Билгеле, мондый эшчәнлек себер татарларының милли аңын һәм аларның этник мохитләрен юкка чыгармый, фәкать үзләренең бербөтен татар милләтенең этник төркеме икәнлеген аңлауларын гына көчәйтә.

Болгарчыларның исә җанисәп вакытында кеше башын бутарга тырышулары барып чыкмады (уйлап карагыз, «болгар» булып язылганнарның туган телләре «болгар теле» булып чыга түгелме?). Димәк, бу төркем тарафдарларының йогынтысы бик кечкенә: халкыбыз миллилекнең төп терәге булган татар үзаңы яклы.

Татарның ассимиляциягә бирелүе турында әйтеп үттек. Милләтебез өчен иң куркынычы — татарның тел ягыннан ассимиляцияләнүе. 2010 елгы җанисәптән күренгәнчә, РФда яшәүче 5,3 млннан татарның 1 млн артыграгы, ягъни биштән бере туган телен белми, русча сөйләшә, дөресен әйткәндә, «татар телен беләм», дип яздырганнар арасында туган телен әйбәт белүчеләр күпкә ким. Әлбәттә, моны җанисәп аркылы белеп булмый, ләкин социологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, шәһәр татар гаиләләрендә туган телдә аралашу аларның яртысына гына хас күренеш. Билгеле булганча, тел бетсә, аның артыннан гомуми этник ассимиляция да килергә мөмкин. Дөрес, бу процесс тиз генә бармый. Мәсәлән, Литва татарлары туган телләрен инде XVI гасырларда ук оныткан булган, ләкин алар бүген дә исән-сау. Аларның туган телләре башка телләр, ләкин мөселман өммәтендә булу аларны саклап калган. Мондый очракта телне кире кайтару да мөмкин. Хәзер татарлар арасында да аның шулай икәнлеген аңлау көчәя, тел өйрәнү буенча яңа методикалар да кулланышка керә, шуңа күрә, бәлки, алга таба бездә татарча сөйләшүчеләрнең саны артыр. Дөрес, мондый эш җиңелләрдән түгел. Әйтик, Башкортстанда яңа вазгыять күзәтелә — татар телендә эшләгән, яисә татар теле укытылган мәктәпләрдә башкорт теле кертелде. Андый мәктәпләрдә укыган, өендә һәм урамда татарча сөйләшкән балалар, хәзер ярымтатар, ярымбашкорт телендә сөйләшә башладылар.

Ләкин нәрсә генә булмасын, татарлар Россиядә үзләренең сан ягыннан икенче урыннарын саклап калдылар. Татарлар 2002 елдагы кебек үк ил халкының 3,87%ын тәшкил итәләр. Ләкин, демографик яктан тискәре процесслар да бара. Мәсәлән, 2002 елда татарлар арасында 16 яшькә кадәрге балалар 17,7 % тәшкил итсә, 2010 елны бу күрсәткеч 15,9 %ка кадәр төшкән. Шул ук вакытта өлкән яшьтәгеләр төркеме (60 яшьтән узган ир-атлар, 55 яшьтән узган хатын-кызлар) 2002 елда 19,3% тәшкил иткән булсалар, хәзер алар 21,6 %ка җиткән. Димәк, милләтебез картая, аның структурасында яшьләр саны кими. Әгәр дә хәл уңай якка үзгәрмәсә, без демографик инкыйразга керәчәкбез. Хәлбуки, мондый тискәре күренешләрне үзгәртү мөмкин һәм ул, беренче чиратта, безнең үзебездән тора: балалар күп туса, сәламәтлекне ныгытсак, татарның саны артачак. Билгеле, биредә дәүләтнең ярдәме дә кирәк. Бәлки, алдагы елларда илдә демографик сәясәт тагы да уңай булыр. Аның татар милләтенә дә уңай йогынтысы булыр дип ышанырга кирәк.

2002 һәм 2010 елларда Россия Федерациясендә татар халкын исәпкә алу мәгълүматлары буенча саннар*

Төбәкләр, республикалар һ.б. милли-территориаль берәмлекләр	2002 ел	2010 ел
I. Төньяк-Көнбатыш төбәк		
1. Архангельск өлкәсе	3076	2335
2. Ненец автоном өлкәсе	211	...
3. Вологодск өлкәсе	1859	...
4. Вологда өлкәсе	4734	4534
5. Санкт-Петербург шәһәре	35616	30857
6. Ленинград өлкәсе	9447	8993
7. Мурманск өлкәсе	7654	5624
8. Новгород өлкәсе	2083	...
9. Псков өлкәсе	1502	...
10. Карелия Республикасы	2629	10779
II. Үзәк һәм Үзәк каратуфраклы төбәк		
1. Брянск өлкәсе	1179	...
2. Белгород өлкәсе	3397	...
3. Воронеж өлкәсе	3501	...
4. Владимир өлкәсе	8678	7332
5. Тверь өлкәсе	6719	5859
6. Кострома өлкәсе	2732	...
7. Калуга өлкәсе	4306	4206
8. Курск өлкәсе	1581	...
9. Иваново өлкәсе	8208	6696
10. Липецк өлкәсе	1751	...
11. Мәскәү шәһәре	166189	149043
12. Мәскәү өлкәсе	52892	56202
13. Орлов өлкәсе	1424	...
14. Рязань өлкәсе	5575	4941
15. Смоленск өлкәсе	2429	...
16. Тамбов өлкәсе	2732	...
17. Тула өлкәсе	8974	7878
18. Ярославль өлкәсе	6175	4982
III. Төньяк-Кавказ төбәге		
1. Краснодар крае	25615	24840
2. Ростов өлкәсе	17892	13948
3. Ставрополь крае	12909	11795
4. Адыгея Республикасы	2904	2571
5. Карачай-Черкесия Республикасы	2022	...
6. Дагыстан Республикасы	4669	...
7. Кабардин-Балкар Республикасы	2852	2375
8. Төньяк Осетия-Алания Республикасы	2113	...
9. Калмыкия Республикасы	1086	...
10. Чечня Республикасы	2137	1466
11. Ингушетия Республикасы	151	...

... — Мәгълүматлар юк.
*Кырым татарлары башка татарлар белән бергә бирелә.

IV. Идел-Урал төбәге		
1. Түбән Новгород өлкәсе	50616	44103
2. Ульяновск өлкәсе	168773	149873
3. Пенза өлкәсе	86806	86431
4. Мордовия Республикасы	46261	43392
5. Саратов өлкәсе	57583	52884
6. Волгоград өлкәсе	28848	24557
7. Әстерхан өлкәсе	77142	60523
8. Киров өлкәсе	43637	36457
9. Удмуртия Республикасы	109868	98831
10. Коми Республикасы	15690	10799
11. Мари Эл Республикасы	43464	38357
12. Чувашия Республикасы	36399	34214
13. Татарстан Республикасы**	2018893	2043017
14. Башкортстан Республикасы	995253	1009295
15. Самара өлкәсе	127984	126124
16. Пермь крае	136634	115544
17. Свердловск өлкәсе	168224	143803
18. Оренбург өлкәсе***	165989	151727
19. Чиләбе өлкәсе****	214220	187872
20. Курган өлкәсе	21986	17017
V. Себер төбәге а) Көнбатыш Себер		
1. Төмән өлкәсе	116055	131096
2. Ханты-Манси автономияле округы (Югра)	107954	108894
3. Ямал-Ненец автономияле округы	27795	28509
4. Омск өлкәсе	48116	41870
5. Томск өлкәсе	20151	17029
6. Новосибирск өлкәсе	27886	24158
7. Кемерово өлкәсе	51065	40229
8. Алтай крае	8904	6794
9. Алтай Республикасы	462	...
б) Көнчыгыш Себер		
1. Красноярск крае	44461	34828
2. Иркутск өлкәсе	31089	22882
3. Бурятия Республикасы	8196	6813
4. Тыва Республикасы	...	...
5. Саха-Якутия Республикасы	10817	8122
6. Чита өлкәсе (Байкал арты крае)	8159	5857
7. Хакасия Республикасы	4024	3095
в) Ерак Көнчыгыш		
1. Приморье крае	14572	10640
2. Хабаровск крае	10982	7836
3. Еврей автономияле өлкәсе	1196	879
4. Амур өлкәсе	4889	3406
5. Камчатка крае	3620	2374
6. Магадан өлкәсе	2002	1415
7. Чукотка автономияле округы	535	...
8. Сахалин өлкәсе	6832	4880

**Татарлар составында 29962 керәшен һәм 484 «болгар».

***Татарлар составында 235 «болгар».

****Татарлар составында 7679 нугайбәк.

МИНЕМ ХАЛКЫМ

ХАЛИСӘ МӨДӘРРИСОВА

Ераклардан, тарих төпкеленнән
Болгар — татар булып калыкты.
Хәтере — хак, намусы ак булыр
Сөембикәсе булган халыкның.

Төртенергә төртеп бастырса да,
Коръән уты җанын яктыртты.
Көнен буды, динен буалмады
Мәрҗание булган халыкның.

Кадерле бер асыл җәүһәр итеп,
Татар телен җиргә танытты.
Телен кисеп, аңын каплап булмый
Тукайлары булган халыкның.

Катламнардан яшел шытым булып,
Төрмә ташын тишеп калыкты.
Тоткын итеп, тезләндереп булмый
Мусалары булган халыкны.

Сүзен әйтер, миссиясен үтәр
Сокландырып олпат тарихны.
Чорлар йотмас, вакыт үтерәлмәс
Киләчәге булган халыкны.

ТАТАРЛАРДА ХӘЙРИЯЧЕЛЕК ТАРИХЫ СӘХИФӘЛӘРЕ

ҖӘҮДӘТ МИҢНУЛЛИН,
тарих фәннәре кандидаты,
Казан (Идел буе) федераль университетының
Тарих институты доценты

XIX гасырның икенче яртысында Россия киң масштаблы реформалары белән таныла. Шуның нәтиҗәсе буларак, ил индустриаль җәмгыять нигезләрен формалаштыруда шактый зур уңышларга ирешә. Бу реформаларның бер чагылышы булып күпсандагы ирекле иҗтимагый оешмалар, барыннан да бигрәк хәйрия җәмгыятьләре барлыкка килү тора. XIX гасырның азагына Россиядә 14854 хәйрия оешмасы (җәмгыяте һәм йорты) хисаплана [1].

Бу дәвердә акрынлап татар иҗтимагый хәрәкәте җайга салына. Аның элементларының берсен ирекле оешмалар тәшкил иткән. Мондый оешмаларның аякка басуы патша хөкүмәтенең колониаль сәясәте һәм консерватив, иске карашлы кешеләрнең каршы торулары сәбәпле, шактый авыр, акрын барган. Ирекле оешмаларның барлыкка килүе — төрле проблемаларны күмәк көч белән чишәргә омтылган иҗтимагый көчләрнең өлгергәнлеген дә күрсәтә.

1. Благотворительные учреждения Российской империи. — Т.1. — СПб., 1900. — С.1-5.

Нәкъ менә XIX гасырның соңгы чирегендә яшь татар буржуазиясе, зыялылары һәм руханилары арасыннан җитештерүне, сәүдәне, мәгарифне көчле оештыручылар, галимнәр, рухи лидерлар гына түгел, ә барлык җәмгыять алдында торган бурычларны аңлаган эшлеклеләр дә үсеп чыга, алар үз эшләренә чын күңелдән бирелеп һәм милләт алдында үзләренең шәхси бурычларын аңлап, иҗтимагый эшчәнлек мәйданына чыгалар.

Касыйм татарлары тарафыннан 1867 елда Санкт-Петербург каласында беренче рәсми теркәлгән хәйрия җәмгыяте [2] Россия империясе төрки-мөселманнары иҗтимагый тормышында сизелерлек эз калдырмаган.

Хәйрия җәмгыятьләре барлыкка килү, шул исәптән татарныкы да, 1897 елдан соң активлаша. Бу чорда эчке Эшләр министрлыгы карары белән күпмедер дәрәҗәдә бу оешмаларның уставларын теркәү эше гадиләшә, шулай ук җәмгыятьләрнең үрнәк уставлары раслана һәм басылып чыга.

Бу процесста зур рольне уйнаган И.Гаспринский милли тәрәккыятне исламның рухи һәм әхлакый кыйммәтләре белән бәйләп татар дөньясын европалаштыруда күргән [3]. Ул төрле иҗтимагый оешмалар, беренче чиратта хәйрия җәмгыятьләре төзүгә һәм аларның эшчәнлегенә җентекле игътибар бирә. Бу проблемалар ул оештырган «Тәрҗеман» газетасы сәхифәләренең даими темалары булалар. Күп сандагы үтенечләр сәбәпле, ул 1897 елда җәмгыятьләрнең үрнәк уставларын бастыра һәм шундый оешмалар төзүнең тәртибен тасвирлый [4]. Бу чорда «Тәрҗеман»нан кала милли массакүләм мәгълүмат чаралары булмауны истә тотсак, мондый эшләр тирән әһәмияткә ия. Әлбәттә, И.Гаспринский бу мәкалә белән генә чикләнми. Әлеге оешмаларның эшчәнлеген халык арасында җәелдерү һәм пропагандалау максатыннан. ул даими рәвештә җәмгыятьләрдәге яңалыклар, барыннан да бигрәк аларның еллык хисаплары турында мәкаләләр бастыра. Акрынлап бу гамәлләр күркәм традициягә әйләнә һәм Идел буе татар матбугаты тарафыннан күтәреп алына.

XX йөз башына инде хәйрия җәмгыятьләре татарлар күпләп яшәгән шактый шәһәрләрдә эшлиләр. Болар — Казан, Санкт-Петербург, Троицк, Касыйм, Петропавловск, Әстерхан һ.б. Октябрь инкыйлабына кадәрге татар хәйрия җәмгыятьләренең гомуми хисабы турында төгәл мәгълүмат әлегә юк. 1913 елда империядә нибары 87 барлык мөселман хәйрия һәм мәдәни-агарту җәмгыятьләре (аларның күпчелеге татар җәмгыятьләре) хисапланган. Безнең якынча хисаплавыбыз буенча, 1917 елга татар хәйрия җәмгыятьләренең гомуми саны 350гә кадәр җитә. Алар хәтта Архангельск, Вологда, Ростов на-Дону кебек традицион чиста рус шәһәрләрендә, шулай ук чит илләрдә эшләгәннәр (Төркия, Кытайда, һ.б.).

Хәйриячелек — Россиядә яңа туып килүче гражданлык җәмгыяте шартларында татарларның күпмедер дәрәҗәдә оеш-

2. Устав Бекбулатовского общества Взаимной благотворительности касимовских татар. — СПб., 1882.

3. Гаспринский И. (1851-1914) — танылган җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, педагог.

4. Важное законоположение // Тарджеман. — 1897. — 22 июля.

кан формада иҗтимагый тормышларын җанландыра ала торган бердәнбер рәсми рөхсәт ителгән эшчәнлек кыры. Шул сәбәпле, татарларның беренче оешкан иҗтимагый институтлары нәкъ менә хәйрия җәмгыятьләре була. Бу аңлашыла да, чөнки хакимият хәйриячелекне сәясәттән берникадәр ераграк торган иҗтимагый эшчәнлек дип санаган һәм шуннан чыгып андый оешмаларны ачарга рөхсәт биргән. Бу — беренчедән. Икенчедән, хакимият дәүләтнеке булмаган иҗтимагый оешмалар ачарга рөхсәт биреп, халыкны социаль яклау өлкәсендәге дәүләт функцияләренең бер өлешен җәмгыятьләрнең үз өсләренә аудара.

Хәйрия җәмгыятьләре Россиядә бик акрын оешучы һәм еш кына декларатив характерда булган социаль хезмәттәшлекнең төп системасын тәшкил иткән. Хәйрия оешмалары кысаларында социаль яктан актив һәм җәмгыять мәнфәгатьләре турында кайгыртучы яңа эшкуарлар формалашуга этәргеч бирелә.

Ирекле иҗтимагый оешмалар төрлечә — җәмгыять, комитет, химаячелек, түгәрәк, тәгавен [ярдәм итешү, хезмәттәшлек] һ.б. исемнәр белән аталганнар. Иң киң таралганнары алдына «мөселман» сүзе куелган «җәмгыять» булган. XX йөз башында да татарларның этник үзаңы күп очракта дини үзаңы белән билгеләнгән. Җәмгыять оешмаларының исемнәрендә «мөселман», яки «ислам» сүзләре аларны дини оешма буларак төркемләр өчен нигез була алмый. Күп очракта бу исем «татар» төшенчәсенә синоним булып тора. Мәсьәлән, Санкт-Петербург мөселман хәйрия җәмгыяте 1914 елда мөселман бәйрәме Сабантуйны оештыра, аңлашыла ки, Сабантуй дини бәйрәм түгел, ә халык бәйрәме. Бу оешмаларның исемнәрендә «мөселман» сүзе булу аларга гамәли эшчәнлекләрендә татар мәктәпләре һәм китапханәләре ачарга, татар спектакльләре һәм әдәби-музыкаль кичәләр үткәрергә, татар милли бәйрәме Сабантуйны оештырырга комачауламаган.

Кайбер очракларда, әгәр дә теге-яки бу оешма үзенең милли составы белән катнаш булса, атамада «татар» сүзе кулланыла. Мәсәлән, Гурьев шәһәрендә «Татар-кыргыз [казах] җәмгыяте» (1907), Җаркәнд шәһәрендә «Татар-кыргыз [казах] комитеты» (1917) һ.б.

Мөселман-татарларда оешкан хәйриячелекнең тарихи язмыш, дингә һәм сәяси-юридик статуска бәйле берникадәр үзенчәлеге бар. Мөселман хәйрия җәмгыятьләре, башка конфессия оешмалары белән чагыштырганда, берникадәр соңрак барлыкка киләләр һәм 1905-1907 елгы беренче рус революциясе елларында киң таралыш алалар.

Россиядәге мөселман халыкларында аерым социаль катлауларга бүленгән хәйриячелек рус милләтендәге кебек киң колач җәйми. Шул сәбәпле мөселман җәмгыятен оештыручылар һәм әгъзалары арасында төрле катлау вәкилләрен — дворяннарны, сәүдәгәрләрне, мещаннарны, зыялыларны, руханиларны һәм

крестьяннарны күрергә мөмкин. Әлбәттә, хәйриячелек эшендә зур рольне сәүдә-эшкуарлык даирәсе вәкилләре уйнаган.

Мөселман хәйрия оешмалары барлыкка килүендә һәм үсешендә шартлы рәвештә түбәндәге этапларны аерып чыгарырга мөмкин:

1) 1867-1897 еллар;
2) 1897-1905 еллар;
3) 1905-1914 еллар;
4) 1914 ел — 1917 елның феврале;
5) 1917 елның феврале — 1917 елның азагы.

XIX гасырның икенче яртысы — XX йөз башында татарларда хәйриячелек системасы түбәндәге төркемнәрдән тора:

— хәйриячелек йортлары;
— хәйриячелек оешмалары;
— шәхси, индивидуаль ярдәм һәм булышу.

Хәйрия җәмгыятьләренең эш юнәлешләре һәм составлары буенча шартлы рәвештә берничә төргә аерырга мөмкин:

— гомуми;
— хатын-кызлар;
— махсус.

Табигый ки, җәмгыятьләрнең уңышлы эшчәнлеге аларның финанс мөмкинлекләреннән бик нык бәйле булган. Акчаның даими рәвештә кереп һәм артып торуы иҗтимагый оешмаларның эшен, аеруча аның җитәкче органнарын бәяләгәндә төп факторларның берсе булып торган. Шуңа күрә теләсә кайсы җәмгыятьнең идарәсе бу мәсьәләгә иң беренче нәүбәттә игътибар иткән.

Хәйрия җәмгыятьләренә акча әгъзалык кертеменнән (взносыннан), иганә, төрле җыемнар, проценттан һәм күчемсез милектән кергән керемнәрдән җыелган. Православие мәхәлләсе җәмгыятьләреннән аермалы буларак, татар җәмгыятьләре акча җыюның дөньяви чараларыннан да файдаланган: хәйрия спектакльләре, кинематографик сеанслар, концертлар, әдәбимузыкаль кичәләр, милли бәйрәм Сабантуйны һәм башка күңел ачу чараларын оештырганнар.

Боларга бәйле рәвештә татар дини реформаторларының исламның төп баганаларыннан берсе булган зәкятне хәйрия оешмаларына кертеп, татар җәмгыяте ихтыяҗлары өчен файдалану буенча эшчәнлекләре аеруча кызыксыну уята. Мәсәлән, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Г.Буби, бу очракта мәхәлләнең иң мөһим ихтыяҗлары исәпкә алыначак, дип бик дөрес фаразлап, зәкятне хәйрия җәмгыятьләренә җыярга тәкъдим итә. Ул зәкятне мондый оешмаларга һәм мәчет-мәдрәсәләр төзелешенә бирергә яраганлыгын исбатлый. Бу фикер, Җамал Вәлиди билгеләвенчә, зәкятне ярлы кешегә, дин әһеленә бирергә кирәк дигән традицион карашлар белән чагыштырганда, чын мәгънәсендә, тамырдан үзгәреш була [5].

Г.Буби бу мәсьәләдә ялгызы гына булмый. 1905 елда ук та-

5. Валидов Дж. Очерк истории образованности и литературы волжских татар (до революции 1917 г.) — М.-Пг., 1923. — с.68.

6. Апанай [Г.] Мәктүбләр // Казан мөхбире. — 1905. — 10 ноябрь.

7. Ибраһимов Р. Зәкят вә җәмгыяте хәйрияләр // Миръат. — 1908, Казан. — Б.14-15.

8. Отчёт Правления Общества пособия бедным мусульманам г.Казани, с состоящими при ней богодельней, приютом и начальной женской школой (мектебе), за 1907 год. — Казань, 1908. — С.8.

9. Отчёт Правления Общества пособия бедным мусульманам г.Казани, с состоящими при ней богодельней, приютом и начальной женской школой (мектебе), за 1908 год. — Казань, 1909. — С.10.

10. Отчёт Оренбургского мусульманского общества за 1912 год. — Оренбург, 1913. — С.11-13, 29.

нылган Казан имамы һәм җәмәгать эшлеклесе Г.Апанай мөэмин мөселманнарга зәкятне хәйрия җәмгыятьләренә бирергә өнди. Аның язуынча, «безнең байларның зәкяте кода-кодагый, туган-тумачаларга, яки хәер сорауны үзләренең һөнәрләре иткән акылсыз бәндәләргә генә китә» [6]. Шулай итеп, ул акчаны тәртипсез исраф итүгә каршы чыга, аны бер урынга туплауны һәм мөһим социаль мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүне, мисал өчен, ятимханәләр, мәдрәсәләр, һөнәр мәктәпләре төзүгә тотуны яклый.

Зәкятне хәйрия җәмгыятьләренә бирү тарафдарларының берсе Р.Ибраһимов булган. «Миръат» альманахында ул шулай ук зәкятне (әлбәттә, шәригать ноктасыннан) хәйриячелек оешмаларына тапшыруның дөреслеген исбатлый. Монда Р.Ибраһимов хәйрия җәмгыятьләрен бәйт әл-мал (VII гасырдан ук барлыкка килгән казна, җәмәгать финанслары, ягъни тулысынча бөтен мөселман мәхәлләсе карамагындагы акча) белән чагыштыра [7]. Зәкятне җәмәгать ихтыяҗларына куллану мәсьәләсендә Р.Ибраһимов һәм «Дин вә мәгыйшәт» («Дин һәм тормыш») журналы кадимчеләре арасында кискен бәхәсләр булган.

Югарыда әйтелгәннәрнең нәтиҗәсе буларак, иҗтимагый фикер акрынлап тамырдан үзгәреш кичерә һәм зәкятне хәйрия җәмгыятьләренә бирү гадәткә керә. Әйтик, 1907 елның 1 гыйнварына Казан мөселман хәйрия җәмгыяте кассасына 225 сум 7 тиен зәкят акчасы керсә [8], 1908 елның 1 гыйнварына бу сумма 1282 сум 59 тиенгә җитә [9].

Хәйрия җәмгыятьләре төрле юнәлештә зур эшләр башкарганнар. Аларның кайберләрен карап китик.

Барыннан да бигрәк хәйрия җәмгыятьләре халык мәгарифе үсешенә зур өлеш кертәләр. Һәрбер җәмгыять үзенең химаясендә бер, ә кайбер очракта берничә мәктәп тоткан. Мәсәлән, 1912 елда Оренбург мөселман хәйрия җәмгыяте карамагында 3 мәктәп була, моннан тыш ул шәһәрнең барлык башка татар мәктәпләрендәге мохтаҗ укучыларга һәм губернадагы алты авыл мәктәбенең ярлы укучыларына акчалата ярдәм күрсәткән [10]. 517 укучыны һөнәрчелеккә өйрәтә торган 7 мәктәп Уфа мөселман хатын-кызлар карамагында булган [11]. Санкт-Петербург мөселман хәйрия җәмгыяте 1913 елда шәһәрнең төрле югары һәм махсус уку йортлары (университет, техник институт, хәрби-медицина академиясе, психо-неврология институты, Югары авыл хуҗалыгы курслары, реальное училище, сәүдә мәктәбе, Югары хатын-кызлар курслары һ.б.) укучыларына акчалата ярдәм иткән [12].

Татар хәйрия җәмгыятьләре яшьләргә һөнәри-техник белем бирүне башлап җибәрәләр. Төрле шәһәрләрдә хәйрия җәмгыятьләре һөнәрчелек мәктәпләре, остаханәләр һәм кыска гына вакыт эчендә төрле һөнәрләргә өйрәтүче курслар ачкан. Әйтик, 1911 елда Пермь мөселманнарының мәдәни-икътисади

11. Отчёт Уфимского дамского мусульманского общества за 1914 год. — Уфа, 1916. — С.4.

12. Отчёт мусульманского благотворительного общества в С.Петербурге. За шестнадцатый год его деятельности (с 1 января 1913 г. по 1 января 1914 г.) — С.Петербург, 1914. — С.10.

13. Отчёт Пермьского мусульманского культурно-экономического и благотворительного общества за 1911 год. — Пермь, 1912. — С.4.

14. Шәрәф Б. Оренбург губернасында мөселманнар (иҗтимагый цәм икътисади мәсьәлә) // Аң. — 1913. — №2. — Б.29-31.; Устав безплатной народной библиотеки-читальни Илецкого мусульманского общества. — Оренбург, 1913.

15. Отчёт Оренбургского мусульманского общества за 1912 год. — Оренбург, 1913. — С.4, 34-37.

16. Җәмгыятьтә берәү. Җәмгыять йортында уку мәҗлесе // Дин вә мәгыйшәт. — 1910. — № 5. — Б.81-82.

һәм хәйрия җәмгыятенең һөнәрчелек-столярлык мәктәбе үзенең экспонатларын Пермь земствосы белән берлектә Омск күргәзмәсенә җибәреп, көмеш медальгә лаек булган [13].

Китапханәләр ачу, аларның уңышлы эшчәнлеге, шулай ук татар хәйрия һәм мәдәни-агарту оешмалары тырышлыгы нәтиҗәсе. Бу китапханәләрнең фондлары белән татар халкының төрле катлаулары вәкилләре файдаланган.

Җәмәгать китапханәләре оештыру эшендә Оренбург губернасының төрле хәйрия җәмгыятьләре максатчан эшләгән. Әйтик, Троицк мөселман хәйрия җәмгыяте, Орск мөселман җәмгыяте, Каргалы (Сәет бистәсе) мөселман җәмгыяте, Тоз-Түбә мөселман җәмгыяте, шулай ук кайбер авыл мөселман җәмгыятьләре җәмәгать китапханәләре ачкан [14]. Губернадагы татар китапханәләре арасыннан аеруча эреләре — Оренбург мөселман җәмгыяте китапханә-уку йорты һәм Чиләбе мөселман бушлай халык китапханәсе булган.

Оренбург мөселман җәмгыятенең түләүсез китапханәсе З.Хәйруллин җитәкчелегендәге махсус алты кешедән торган комиссия белән идарә ителгән. Китапханә фондлары даими тулыланып торган: 1911 елда анда 2837 китап булса, 1912 елда аларның саны 3225кә җиткән. Шул ук елда китапханәгә 10440 кеше килгән, өйгә 4046 данә китап, журнал һәм газета бирелгән, иганәчеләр тарафыннан 132 данә китап һәм 272 данә журнал тапшырылган (шулар арасында «Природа и люди», «Торговое дело» кебек рус журналлары да бар), ел дәвамында 113 кушымта белән 425 журнал сатып алынган һәм татар телендә 10, рус телендә 7 исемдәге газета алдырылган [15]. Укучыларга гадәти хезмәт күрсәтүдән тыш, Оренбург мөселман җәмгыяте китапханәсе халык өчен бушлай укулар да оештырган. Әйтик, 1910 елның 24 гыйнварында шундый кичәләрнең берсендә атаклы галим М.Бигиев чыгыш ясый, «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллиме Х.Айдаров тарих гыйлеменең әһәмияте, ә И.Бикчәнтәев Казан каласының тарихы турында сөйли [16]. Мондый укулар даими рәвештә оештырылган. Бу кичә-укуларда төрле фикер алышулар, дискуссияләр булган, Оренбург шәһәре татарларының төрле катлау вәкилләре мәнфәгатьләре «бәрелешкән».

Хәйрия җәмгыятьләре тарафыннан оештырылган җәмәгать китапханәләреннән үз заманы өчен иң эресе Оренбург губернасы Троицк каласында урнашкан. Троицк китапханәсе шәһәр халкы арасында зур популярлык казанган, анда 1911 елда гына да 19432 укучы теркәлүе күп нәрсә турында сөйли [17].

1914 елда мөселман хәйрия җәмгыяте тырышлыгы белән Мәскәү татар китапханәсе ачыла [18]. Китапханәнең эшен җайга салып идарә итәр өчен алты кешедән торган махсус совет төзелә. Касыйм татар китапханәсе дә мөселман хәйрия җәмгыяте тарафыннан оештырыла, әмма аның махсус әгъзалары һәм үз

17. Тагиров И.Р. Революционная борьба и национально-освободительное движение в Поволжье и на Урале (февраль-июль 1917 года). — Казань, 1977. —С.59.

18. Ширин Мәскәүдә мөселман көтебханәсе // Кояш. — 1914. — 3 апрель.

19. Кирмәндә көтебханә // Йолдыз. — 1906. — № 37.

20. Самара мөселман җәмгыяте // Икьтисад. — 1909. — №41. — Б.1027.

21. Дахили хәбәрләр //әл-Ислах. — 1908. — №28. — Б.10; №35. — Б.10; Тәрәкъкыюне ислам җәмгыятенең гомуми җыены мөнәсәбәте илә // Сибирия. — 1913. — №138; Назир кирәк // Тормыш — 1916. — №549. — 20 ноябрь.

22. Мәхмудвагыйзь [Нәүрүзов] Җәмгыятьләремез // Сибирия. — 1912. — 3 март; Амур буенда // Сибирия. — 1912. — 29 июль; Капал // әл-Ислах. — 1908. — №20. — Б.12-13.; Керкә шәһәрендә көтебханәи исламия //

советы булмый [19]. Ф.Мортазин җитәкчелегендәге Самара мөселман хәйрия җәмгыяте шулай ук җирле халыкны агартуга һәм төрле уку курслары оештыруга җентекле игътибар бирә. Мәсәлән, ул 1908 елның 15 гыйнварыннан 18 апреленә кадәр татар сәүдәгәрләре өчен түләүле кичке курслар оештыра. Шул ук елда балалар өчен рус телен өйрәнү буенча махсус класс оештырыла, ел азагына китапханә ачу мәсьәләсе хәл ителә, шулай ук халык өчен ислам тарихы һәм татар-мөселманнарның икътисади хәлләре турында лекцияләр укыла [20]. Башка шәһәрләрдә дә җәмәгать китапханәләрен ачу тәкъдиме нигездә хәйрия һәм мәдәни-агарту җәмгыятьләре тарафыннан чыккан [21].

Азәрбайҗан, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Себер һәм Ерак Көнчыгышта татар диаспораларының тернәкләнүе һәм ныгуы белән, кагыйдә буларак, беренче чиратта, шәһәрләрдә татар китапханәләре барлыкка килә башлый. Баку, Алма-Аты, Ташкент Коканд, Нәманган, Әндиҗан, Петропавловск, Аягуз, Пржевальск, Казалы, Капал, Керки, Омск, Томск, Иркутск, Благовещенск — болар хәйрия җәмгыятьләре, төрле мәдәни-агарту оешмалары, һәм шулай ук аерым шәхесләрнең инициативасы белән китапханәләр ачылган шәһәрләрнең шактый тулы булмаган исемлеге [22]. «Гомумән, шуны әйтергә кирәк, Җидесу вилаятендә хәйрия һәм мәгариф җәмгыятьләре, китапханәләр, уку йортлары, шулай ук яңа методлы мәктәпләр оештыру инициативасының күпчелеге җирле татарларга карый. Мондый җәмгыятьләр, китапханә һәм уку йортлары башка шәһәрләрдә дә, мәсәлән Ташкентта, Кокандта, Нәманганда да булганнар. Алар, нигездә, 1905-1907 елгы революциядән соң ачылганнар. Мәсәлән, 1909 елда Ташкентта күп кенә җәдитчеләрне берләштергән «Тәгавен» [«Ярдәм»] хәйрия җәмгыяте ачыла. 1910 елда Тукмак шәһәрендә (Җидесу вилаяте) китапханә белән мәгариф һәм хәйрия җәмгыяте ачу турында патша хакимиятеннән рөхсәт алу эше кузгалтыла», — дип яза Урта Азиянең яңа тарихы белгече А.В.Пясковский [23].

XIX гасыр ахырында җәдитчелек хәрәкәте үсеше кысаларында, Казан Татар укытучылар мәктәбендә, Казан, Оренбург, Самара, Троицк, Уфа, Җаек һ.б шәһәр мәдрәсәләрендә татар яшьләре оешмалары барлыкка килә [24].

1905-1907 елгы революциядән соң мәктәп-мәдрәсәләргә, шулай ук укучы яшьләргә ярдәм итү буенча махсус җәмгыятьләр төзелә [25]. Аеруча бу юнәлештә Оренбург шәкертләренә ярдәм җәмгыяте максатчан эшләгән [26].

Патша хакимиятенең хәйрия җәмгыятьләренә, һәм гомумән иҗтимагый оешмаларга мөнәсәбәте мәсьәләсен шартлы рәвештә ике этапка бүлергә мөмкин. Беренче этап 1867 елдан, ягъни татарларда хәйрия җәмгыятьләре барлыкка килгән дәвердән башлана. Икенче этап Идел буе төбәгендә татар мөселман йогынтысына каршы торуга чаралар әзерләү буенча аерым

Кояш. — 1912. — 20 декабрь; Сергиопольдә мөселман кыйраәтханәсе // Вакыт. — 1913. — №1362; Петропавелда көтебханә // Кояш. — 1913. — 9 гыйнвар; Хисаметдинов Б. Алмата // Вакыт. — 1915. — 14 гыйнвар; Идарәгә мәктүб // Тормыш — 1916. — 21 гыйнвар; Хантимирия Г. Тәшәккер һәм хисап // Вакыт. — 1915. — 20 май; Габидов Х. Сибириядә. Иркутскийдан // Тормыш — 1915. — 14 гыйнвар; Бакуда Идел буе мөселманнары арасында // Йолдыз. — 1917. — 27 март; Пясковский А.В. Революция 1905-1907 годов в Туркестане. — М., 1958. — С.548-549.

23. Пясковский А.В. Указ. соч., С.549.

24. Бубыйдан мәктүб. Таләбәи кирам дикъкатенә // Әлфәт. — 1907. — 26 май; Курбанов Т.Я. Татарские учителя и учащаяся молодёжь Поволжья и Приуралья в период буржуазно-демократической революции 1905-1907 гг. // Из истории педагогики в Татарии. — Сб.I. — Казань, 1967,

киңәшмә уздырылганнан (гыйнвар, 1910 ел) соң башлана һәм 1917 елның февраленә кадәр дәвам итә. Бу этап татар хәйрия оешмаларына мөнәсәбәттә тыю чаралары көчәю белән генә түгел, ә аның бөтен ил күләмендә системалы төсмер алуы һәм дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә күтәрелүе белән характерлана.

Архив материалларыннан күренгәнчә, татар хәйрия җәмгыятьләрен ябуның төп сәбәбе аларның үз акчаларына мәктәп һәм мәдрәсәләрне, ягъни мөселман мәктәпләрен (күбесенчә җәдиди мәктәпләрне) тәэмин итүләре һәм ярдәм күрсәтүләре булган, чөнки бу вакытта империя законнары буенча татарларга шәхси дини мәктәпләр генә тотарга яраган. Хәйрия җәмгыятьләренең татар мәктәпләренә ярдәм итүе патша хакимияте тарафыннан дини ихтыяҗларны кайгырту һәм башкару буларак каралган. Бу да хәйрия җәмгыятьләренә тыелган. Моңа шулай ук татар уку йортларының хокукый статуслары аныкланмаган булу да этәргән.

1914 елның март ае башына «империядәге мөселман оешмаларының гомуми хисабы 87 гә җитә, шул исәптән 5 дини җәмгыять, 47 хәйрия һәм 35 мәгариф оешмасы була» [27].

1917 елның февраль революциясеннән соң иҗтимагый һәм сәяси оешмаларның тарихында яңа этап башлана. Вакытлы хөкүмәтнең карары буенча 1917 елның 12 апреленнән Россия гражданнары җәмгыятьләр һәм берләшмәләрне ачыктан-ачык оештыру хокукын ала [28].

Хәйриячелек һәм мәдәни-агарту эшләреннән кала, бу җәмгыятьләр, гәрчә аларның устав бурычларына кермәсә дә, билгеле бер дәрәҗәдә татар халкының иҗтимагый-сәяси тормышында да катнашканнар.

Шулай итеп, татарларда оешкан иҗтимагый эшчәнлек иң әүвәле хәйриячелек өлкәсендә барлыкка килә. Демократик җәдичелек хәрәкәте Россиядә монархия шартларында үзенең максатларын тормышка ашыруда хәйриячелек өлкәсендә мөмкинлек тапкан, шуның белән бу хәрәкәтнең вәкилләре иҗтимагый аренага чыкканнар. Иҗтимагый эшчәнлекнең бу формасы хәйриячелектә дини һәм дөньяви омтылышларны бергә берләштерү мөмкинлеген биргән. Хәйрия җәмгыятьләре татар «сәяси» милләтен оештыруда бик мөһим роль башкарганнар.

1918 елда большевиклар диктатурасы оешу дәверендә барлык хәйрия җәмгыятьләре үзләренең эшчәнлекләрен туктаталар. ■

С.10-74; Әмирхан Р. Иманга тугрылык. — Казан, 1997. — Б.105-115.

25. Отчёт Правления Общества попечения об учащихся мусульманах в 1-м Омском мектебе. За 1909 год. — Омск, 1910; Устав Общества вспомоществования недостаточным учащимся в Ростовской на Дону магометанской школе «Мектебе» и содействия к улучшению материального положения школы. — Ростов на-Дону, 1913 и др.

26. Оренбургское общество помощи об учащихся мусульман. — Оренбург, 1913.

27. РГИА. ф.821, оп.133, д.474, л.59.

28. Постановление Временного правительства о собраниях и союзах // Вестник Временного правительства. — 1917. — 20 апреля (3 мая).

ТАТАР ФЕДЕРАЛЬ МИЛЛИ-МӘДӘНИ АВТОНОМИЯСЕ: КИЧӘ, БҮГЕН, ИРТӘГӘ

АЛСУ ХӘБИБУЛЛИНА,
Татар федераль милли-мәдәни автономиясенең матбугат хезмәткәре

ТАТАРЛАР — ЕВРАЗИЯ КИҢЛЕКЛӘРЕНДӘ НЫК ТАРАЛЫП ГОМЕР ИТҮЧЕ ХАЛЫК. XX ГАСЫР БАШЫНДА РОССИЯДӘ, ИЛДӘ КИСКЕН ИҖТИМАГЫЙ ҮЗГӘРЕШЛӘР БАШЛАНГАЧ, МӘСКӘҮ ШӘҺӘРЕНДӘ 900 ДЕЛЕГАТ КАТНАШЫНДА УЗГАН МӨСЕЛМАННАРНЫҢ БӨТЕНРОССИЯ СЪЕЗДЫ (1917 ЕЛНЫҢ 1-11 МАЕ) ТАТАР МИЛЛӘТЕНЕҢ КИЛӘЧӘК ҮСЕШЕН МИЛЛИ-МӘДӘНИ АВТОНОМИЯ БЕЛӘН БӘЙЛӘҮНЕ ӨСТЕН КҮРӘ.

1917 елның июль азагында Казан шәһәрендә җыелган Мөселманнарның II Бөтенроссия съезды «Эчке Россия мөселманнарының милли-мәдәни автономиясе турында» документ кабул итә. Милли-мәдәни автономияне тормышка ашыру Садри Максуди җитәкчелегендәге коммиссиягә йөкләнә. Милли мәҗлеснең комиссиясе 1918 елның 16 гыйнварында «Эчке Россия һәм Себер мөселманнары мәдәни автономиясенең төп нигезләре турында» документ эшли.

Аннан соңгы сәяси вакыйгалар илдә тагын да кискен үзгәрешләргә китерә, алар татар милләте язмышына турыдан-туры тәэсир итәләр. «Идел-Урал штатлары», Татар-башкорт республикасы проектлары турында без яхшы беләбез. Ахыр чиктә, большевиклар татар халыкының өчтән бере дә яшәмәгән ТАССР оештыралар. Совет еллары илнең башка өлкә-республикаларында яшәгән татарлар өчен зур сынау еллары була. Революциягә кадәр татар малы хисабына көн күргән татар мәктәпләре,

милли һәм дини оешмалар, Советлар илендә хосусый милек бетерелгәч, дәүләт күзенә карап яшәргә мәҗбүр була.

XX гасыр ахырында илебездә башланган зур үзгәрешләр шаукымы татар халкын да читләтеп узмады. Яңа икътисади, сәяси, иҗтимагый шартлар милли традицияләрне саклау, үстерү, ил буйлап сибелгән татарларны берләштерү эшен башка дәрәҗәдә үтәргә мәҗбүр итте. Матавыклы 90 нчы елларда туган милли проблемаларга ил җитәкчелеге дә күз йома алмый иде. Нәтиҗә буларак, 1996 елда «Милли-мәдәни автономия турында» Федераль закон кабул ителде. Әлеге канун илдәге милли азчылыкны тәшкил итүче халыкларны юкка чыгудан коткару, этник төркемнәргә туган телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклау юлында бергә тупланыр, яңа мөмкинлекләр бирү өчен кабул ителде. Илдә бер-бер артлы яңа милли оешмалар — милли-мәдәни автономияләр теркәлә башлады. Азәрбайҗаннарның милли-мәдәни автономиясе, яһүдләрнең милли-мәдәни автономиясе, лезгиннарның милли-мәдәни автономиясе…

1998 елның маенда Казанда Татар федераль милли-мәдәни автономиясен булдыру турында зур сөйләшү булды. Илнең төрле төбәкләрендәге татар оешмалары вәкилләре җыелган бу зур киңәшмә, федераль күләмдә татарларны тәкъдим итәрдәй тагын бер яңа оешмага нигез салыну көне буларак, тарихка кереп калды. Санкт-Петербург, Свердловск, Саратов һәм Ульяновск өлкәләре вәкилләре Федераль татар милли-мәдәни автономиясен оештыру турында карар кабул иттеләр. Яңа юнәлешкә сукмак салу кебек җаваплы бурычны ул вакытта татарларның әйдаманы, милләт өчен җан атып йөрүче галим, тарихчы Индус Таһировка тапшырылды. Төбәкләрдән җыелган оешма җитәкчеләре аны бертавыштан рәис

итеп сайлый. Бу вакытта Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетын җитәкләгән Индус ага өчен Федераль автономияне дә җитәкләү авыр йөк булмый: таныш проблемалар, таныш йөзләр, дигәндәй. Шулай итеп, татарларның милли-мәдәни автономиясе, Бөтендөнья татар конгрессы карамагындагы оешма буларак, эш башлап җибәрә.

2002 елда, Индус ага милли хәрәкәт җитәкчелегеннән киткәч, Татар федераль милли-мәдәни автономиясе дилбегәсе татарның икенче бер милләтпәрвәр улы — Римзил Вәлиевкә күчә.

Татар яшьләренең актив бер дулкын булып милли мәйданга чыгып килгән вакыты иде. Татар гимназияләрендә белем алган, рухи хөрлек шартларында үскән егет-кызларның мәктәп бетереп, университетларга укырга кереп йөргән еллары. Казанда татар яшьләренең үз мөстәкыйль тормышы аваз сала. Кемнәрдер янып-көеп иң сәләтле татар балалары өчен «Сәләт» аланнарын оештырып йөри, анда сәлкеш, әйдаман булып милләт ул-кызларын тәрбияли. Икенче берәүләр татар шәһәр мәдәниятен үстерү белән яна: татарча рэп яза, рок җырлый, этнофолк музыкасына татар текстлары иҗат итә... Казандагы татар дискәтүкләре, альтернатив музыка концертлары, татар квартирниклары... Башкала яшьләреннән күреп, төбәкләрдә яшәүче татар егетләре һәм кызлары да үзләрендә шундый ук кичәләр, концертлар уздыралар.

Шушы елларда татарлар турында Мәскәүдә ишеттерә башларга кирәк дигән фикер дә уяна. Мәскәүдә төрле милләтләрнең этник оешмалары үзара мөнәсәбәтләрне җайлый башлый. Уртак утырышлар, семинарлар, конференцияләр уздырыла, фестивальләр, форумнар үткәрелә. Барлык милләтләрнең дә федераль милли-мәдәни автономияләре Россия башкаласында урнашкан. Татарларныкы исә — Казанда. Казан — Мәскәү арасы ерак түгел-түгелен, әмма барып кайту гына тиешле нәтиҗәне бирер микән дигән сорау туа. Монда иң мөһиме — вакыйгаларның уртасында кайнарга бит.

Шуңа Казанда, Татар федераль милли-мәдәни автономиясенең III хисап-сайлау җыелышында (24 март 2007 ел) бу мәсьәлә көн үзәгенә куела. Җыелышка Россиянең 40лап төбәгеннән татар оешмалары лидерлары килә. Алар оешманы җитәкләргә Мәскәү белән элемтәләр булдырган, андагы мохит һәм хәлләрнең торышы белән таныш булган кеше сайларга кирәк, дигән карарга киләләр һәм Илдар Гыйльметдиновны Татар федераль милли-мәдәни автономиясенә җитәкче итеп сайлау һич кенә дә очраклы булмый. Ул Татарстанның Яшьләр эшләре буенча дәүләт комитетында, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгында эшләгән вакытта ук татар яшьләре белән төрле чаралар оештырып, аларга дәүләт ярдәмен алырга ярдәм итеп йөргән кеше. Чит төбәкләрдәге татар яшьләре белән Татарстан арасында элемтә булдыручы Министрлык кармагындагы «Идел» яшьләр үзәген оештыруда да аның роле зур була. Аның турыдан-туры катнашы белән Татар яшьләре көннәре беренче тапкыр 1990 елда Казанда уздырыла башлый.

Илебезнең кайсы гына төбәгенә барып чыксаң да, милләттәшләребезне очратмыйча калган юк. Шуңа күрә милләттәшләребезне җыю, туплау, аларның төрле башлангычларына ярдәм итү белән ике оешма (Татар федераль милли-мәдәни автономиясе һәм Бөтендөнья татар конгрессы) киң

масштабта кулга-кул тотынып эшли башлый.

Татар федераль милли-мәдәни автономиясе милләттәшләребезгә методик һәм башка төрле ярдәмнәр күрсәтү, төбәкләрдә яңа татар оешмалары булдыруга теләктәшлек итү, Россия күләмендә татар милләтенең мәнфәгатьләрен кайгырту кебек зур максатлар куеп эшли. Федераль милли-мәдәни оешмалар төбәк милли-мәдәни автономияләреннән оеша. Бүген Россиянең 30 төбәгендә татар милли-мәдәни автономиясе эшли. Алар барысы да Татар федераль милли-мәдәни автономиясе составына кергән. Һәр төбәктәге татар оешмасының җитәкчесе Татар федераль автономиясенең Шурасы составында тора. Төбәк җитәкчеләрен туплаган Шураның җитәкчелек органы булып рәис һәм рәистәшләр исәпләнә.

Бредә карарлар һәрвакыт уртага салып сөйләшеп кабул ителә. Ел саен җитәкчеләре һәм төбәкләрдәге оешмаларның активы катнашында конференцияләр үтә. 2008-2009 елларда конференцияләр төбәкләрдәге татар оешмаларының эшен көйләп җибәрү, аларга юнәлеш бирү максатыннан оештырыла, 2010 елда милли-мәдәни автономияләрнең гражданлык җәмгыятен оештырудагы роле турында сөйләшенә, 2011 елда татар оешмалары һәм дәүләт органнары арасындагы хезмәттәшлек мәсьәләләренә ачыклык кертелә, 2012 елда исә төбәкләрдә татар теле укыту мәсъәләсе тикшерелә.

Мәскәү казанында кайнаган Илдар әфәнде федераль дәрәҗәдә иҗтимагый оешмалар арасында үткәрелүче грант конкурсларында катнашуны җайга сала. Милли кием эскизлары, декоратив-гамәли сәнгать белән шөгыльләнүче яшь осталар өчен «Традицияләр һәм заманчалык» проекты 2008 елда җиңеп чыга. Федераль грантка бирелгән акчага Идел буенда яшәүче яшь модельерлар өчен «Этно-Дар» конкурсы, шул исемдәге мода һәм декоратив-гамәли сәнгать фестивале, төрле төбәкләрдән килгән осталар катнашында күргәзмә үткәрелә. Чын матурлык фестивале булып тарихка кереп калды ул.

Алдагы 2009 елга конкурска Р.Ваһапов исемендәге җыр фестивале проекты тәкъдим ителә. Әйе, барыбызга да таныш, бүген дөнья яулаучы фестивальнең чишмә башы Татар федераль автономиясенә барып тоташа!

Фестивальләр үткәрү бик кирәк, әмма иң борчыган мәсьәлә — балаларның әкренләп туган телләрен оныта баруы. Чит төбәкләрдә катнаш гаиләләр күп. Мондый гаиләләрдә татар теле юк дияргә була, балалар телне белми. Шуңа күрә Татар федераль автономиясе телне саклау буенча махсус программалар төзү турында уйлана. Яшь буында татар теленә карата кызыксыну уяту максатында, балалар өчен ун дисктан торган «Халкым мирасы» аудиоколлекциясе эшләнде. Ун дискка татар халкының иң яхшы фольклор үрнәкләре, җырлары, шигырьләре, әкиятләре, милли тарихның иң күркәм сәхифәләре тупланган. Башта 1000 данә эшләнгән аудиоколлекциягә сорау зур булу сәбәпле, ул күбәйтелеп, татар китапханәләренә, татар мәдәнияте үзәкләренә, якшәмбе мәктәпләренә таратыла.

Чит төбәкләрдәге татарлар өчен тел өйрәнү буенча дәреслек идеясен Татар федераль милли-мәдәни автономиясе проект итеп формалаштырып, Европа Советына тәкъдим итте. Дәреслек һәм аудиодисктан торган «Татар теле — күңелем теле» укыту комплекты Европа Советы һәм РФ Төбәкләр үсеше министрлыгы

ярдәме белән тормышка ашырылды. Дәреслек мәктәпләрдә, үзлегеннән тел өйрәнергә теләүчеләргә атап язылган. «Татар теле — күңелем теле» дәреслегенең тагын бер үзенчәлеге бар. Татар теле рус һәм инглиз телләре аша өйрәтелә.

Милләтне саклау эшенә яшьләрне актив рәвештә җәлеп итәргә омтылабыз. Мисал өчен, Татар яшьләре көннәре быел 22 нче тапкыр үткәрелде. Аны Татар федераль автономиясе ел саен Татарстан Яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министрлыгы, аның карамагындагы«Идел» яшьләр үзәге белән берләшеп үткәрә. Яшьләрне бергә җыеп, милли оешмалар төзергә, эшне ничек оештырып җибәрергә икәнен өйрәтәләр, бу эштә Федераль милли-мәдәни автономия, Татарстанның ничек ярдәм итә алганын аңлаталар.

Шулай ук балаларны да Казанга чакырып, төрле чаралар оештыру матур гадәткә әверелде. Чит төбәкләрдәге татар балалары өчен «Милләтебез хәзинәләре» дип аталган лингвистик лагерьларда туган телгә, милли мәдәниятка кызыксыну уятырга тырышалар.

Соңгы елларда «Мөселман яшьләре фестивале», «Татар балалар лидеры мәктәбе», «Татар яшьләр лидеры мәктәбе» кебек чаралар да үсеш алды. Татарстан Яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министрлыгы, аның карамагындагы «Идел» яшьләр үзәге белән берләшеп үткәрелә торган әлеге чараларны уздыруда Татар федераль милли-мәдәни автономиясе зур көч куя.

Бүген Татар федераль милли-мәдәни автономиясе иҗтимагый оешмасы — илнең 30 төбәгендәге җирле татар милли-мәдәни автономияләрен берләштергән Россия күләмендә хөрмәт ителә торган милли оешма. Аның оешмалары Байкал буйларыннан Нева ярларына кадәр сибелгән: Башкортстан, Бурятия, Коми, Мари Эл, Мордовия, Удмуртия, Алтай крае, Архангельск, Волгоград, Иваново, Калуга, Кострома, Красноярск, Тула, Чиләбе өлкәләре Мәскәү шәһәре һәм Мәскәү өлкәсе, Түбән Новгород, Новосибирск, Омск, Оренбург, Пенза өлкәләре, Пермь крае, Самара өлкәсе, Санкт-Петербург шәһәре, Саратов, Свердловск, Төмән, Ульяновск өлкәләре, Ханты-Манси автономияле округы. Милли мәсьәләләргә кагылышлы һәм федераль югарылыкта үткәрелүче бер генә чара да аның катнашуыннан башка узмый. Илдар әфәнде Дәүләт Думасы депутаты, Россия Президенты карамагындагы Милләтара мәсьәләләр советы әгъзасы булып тора. Хәзер Милләтара мәсьәләләр советында Россиянең дәүләт милли сәясәте концепциясен әзерләү буенча эш бара.

Тиздән кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Куян күчтәнәче» дигән коллекция әзер булачак. Әлеге коллекция аша балалар кечкенәдән үк татар рухын тоеп, туган телне яратып, белеп үсәр дигән өметтә калабыз.

Читтәге татар туганнар өчен исә интерактив проект эшләнә. Әлеге проект аша читтәге татар оешмалары үз төбәкләрендә оешманың эшен оештырырга, аны нәтиҗәле итәргә өйрәнер дип көтелә.

Әмма бу проектлар ярдәмендә генә төбәкләрдәге оешмаларның эшен көйләп бетереп булмый. Төбәкләрдәге проблемалар да җитәрлек. Аларның иң көн кадагындагысы — туган телнең югала баруы. Чит төбәкләрдә татар теленең хәле бүген сөенерлек түгел. Яшь буын телдән аерылып бара. Әле татарлар күпләп яшәгән авылларда (мисал өчен, Пенза өлкәсендә, Удмуртиядә, Ульяновскида) тел саклана. Аны сакларга дин дә, мохит тә ярдәм итә. Ә менә зур шәһәрләрдә хәл бик мөшкел. Татар теле укытучылары җитми, курслар башлап җибәрәм дисәң, дәреслеге юк, дәреслекләрен тапсаң, курсларны оештырыр урын юклыгы ачыклана. Бу очракта төбәкнең икътисади хәле зур роль уйный. Хәллерәк төбәкләрдән Иваново өлкәсендә, Мәскәү өлкәсендә, Мәскәү шәһәрендә, Санкт-Петербург каласында, Красноярскида эш яхшы куелган. Ул төбәкләрдәге татар оешмалары җитәкчелекнең ярдәмен һәрдаим тоеп яши. Ә менә Бурятия Республикасында, Коми Республикасында татар оешмалары хәлләнеп китә алмый. Халкының эшләр эше дә булмаганда милли мәсьәләләр гел арткы планга күчеп кала.

Шулай ук төбәк автономияләре акча җитмәүлектән интегә. Әлеге проблеманы татар оешмалары җитәкчеләре агымдагы елның 12 маендагы Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашу вакытында да тагын бер кат искәртеп үттеләр. Хәзер Президент карары нигезендә ТР Мәдәният министрлыгында төбәкләрдәге татар автономияләре өчен грант конкурсы әзерләнә.

Проблемалар Татар федераль

милли-мәдәни автономиясен дә читләтеп үтми. Бүген оешма тулысынча үзе тапкан акчага гына яши. Иҗтимагый оешма буларак, автономия бюджеттан финансланмый. Шуңа күрә ниндидер проектлар хисабына яшәргә туры килә. Бу очракта Татарстан Республикасы җитәкчелегенә рәхмәт әйтергә кирәк. Нинди генә фикер белән мөрәҗәгать итсәң дә, алар беркайчан да кистереп юк, дип әйтмиләр. Ничек тә булса ярдәм итү җаен табалар.

Татар федераль милли-мәдәни автономиясенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәккә планнары шулардан гыйбарәт. Чишеләсе мәсьәләләр хәл ителә, Россия буйлап сибелеп яшәүче татарларны берләштерү, аларга ярдәм итү максатыннан, яңадан-яңа проектлар уйлап чыгарыла, тормышка ашырыла. Шулай итеп, Татар федераль милли-мәдәни автономиясенең, Россия төбәкләрендә үз мирасын барлап, саклап, үстереп яшәүче татарларның яңа тарихы языла. ■

«БЕЗ – БЕРБӨТЕН БҮЛЕНМӘС ХАЛЫК»

СОҢГЫ ИКЕ ДИСТӘ ЕЛ ЭЧЕНДӘ ТӨБӘКЛӘРДӘ ЯШӘҮЧЕ ТАТАРЛАР ТОРМЫШЫНДА НИНДИ ЗУР ВАКЫЙГАЛАР, ҮСЕШ-ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ЮГАЛТУЛАР БУЛДЫ? ТАТАР МИЛЛӘТЕН, ТЕЛЕН, ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕН САКЛАП КАЛУ, ҮСТЕРҮ ҺӘМ КИЛӘЧӘК БУЫНГА ҖИТКЕРҮ ӨЧЕН, НӘРСӘЛӘР ЭШЛӘНӘ ҺӘМ ЭШЛӘРГӘ ПЛАНЛАШТЫРЫЛА? ТАТАРСТАННАН ЧИТТӘ МИЛЛИ ТОРМЫШНЫ ТОРГЫЗУДА НИНДИ КЫЕНЛЫКЛАР БАР? ӘЛЕГЕ СОРАУЛАР БЕЛӘН БЕЗ 1992-2002 ЕЛЛАРДА БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ ИНДУС ТАҺИРОВКА ҺӘМ ТӨБӘК ТАТАР МИЛЛИ-МӘДӘНИ АВТОНОМИЯЛӘРЕ ҺӘМ БАШКА ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМА ҖИТӘКЧЕЛӘРЕНӘ МӨРӘҖӘГАТЬ ИТТЕК.

ИНДУС ТАҺИРОВ
тарих фәннәре докторы,
Казан (Идел буе) федераль
университеты профессоры

Бөтендөнья татар конгрессының барлыкка килүенә 20 ел тулды. Шушы дәвер эчендә булып үткән гамәлләр төрлечә бәяләнә, чөнки сүз ифрат катлаулы һәм каршылыклы процесслар турында бара. Бу елларда СССР таркалды, КПСС юкка чыкты. Илне буып торган богаулар өзелде. 1990 елда республикабызның суверенлык Декларациясе кабул ителде. 1992 елның 21 мартында Декларациябезне халык фикере белән ныгыткан референдум үзе генә дә ни тора! Ул көннәрдә Татарстанга ясалган янаулар, телевидение, радио, газеталар аша таратылган коткылар — барысы да бүгенгедәй күз алдында. Россия Югары Советының махсус машиналары Татарстан шәһәрләренә төрлечә куркыту, янау белән сугарылган листовка һәм прокламацияләр таратып йөрделәр. Кешеләрнең почта ящиклары шундый чүп-чар кәгазьләр белән шыгрым тула торган иде. Ләкин халкыбыз курыкмады, артка чигенмәде. Республикабыз сайлаучыларының 61,4%ы бәйсезлегебезне яклап чыкты.

Әйе, кыска гына вакыт эчендә искиткеч үзгәрешләр булып үтте. Әле кайчан гына бер-беребезне күрергә тилмереп, Сак белән Сок шикелле бер-беребезне сагынып яши торган заманнар бар иде. Ә хәзер дөньяның теләсә кайсы почмагына барып, милләттәшләребез белән аралашу мөмкинлеге барлыкка килде. Совет чорында безне аерып килгән «тимер пәрдә» юкка чыкты.

Татар мәктәпләре аякка баса башлады. Казанда гына түгел,

Оренбургта, Самарада, Саратовта, Ижауда, Уфада, хәтта Мәскәүдә дә татар мәктәпләре барлыкка килде. Өр-яңадан татар теле гамәлгә керә башлады. Дистәләгән, йөзләгән милли оешмалар үсеп чыкты. Алар ныклап милли агарту эшен башлап җибәрделәр һәм бүген дә уңышлы дәвам итәләр.

Һәммә җирдә, хәтта ерак чит илләрдә дә, шул исәптән Нью-Йорк, Вашингтон, Сан-Франциско, Монреаль, Австралиянең Аделаидасында һәм берничә Төркия шәһәрендә гөрләтеп Сабантуйлар үткәрелә. Җир шарының төрле почмакларында татар җыры яңгырый. Йөзләгән үзешчән сәнгать коллективлары халыкның милли хисләрен уяталар. Күп шәһәрләрдә якшәмбе мәктәпләре эшли башлады, туган телгә тартылу артты. Халкыбызга милли рух һәм горурлык хисләре кайтты. Ул үзендә искиткеч, башкаларны таң калдырырдай яшәү көче таба алды.

СССРдан читтә яшәгән милләттәшләребез дә татар рухын, татар яшәешен саклый алдылар. Кытайдамы, Америкадамы, Финляндиядәме, татар кешесе туган теленә, гореф-гадәтләренә турылыклы булып, үзендәге яшәү көчен саклый алды. Әгәр дә 30-40 нчы елларда Сеул шәһәрендә яшәгән 26 татар гаиләсе мәктәп ачып, уку китаплары бастырып, мәчет салып, мили тормыш булдыра алганнар икән, бу юкка гына түгел. Шушы мәктәптә белем алган, бүген безнең арабызда булган Сәгыйть Сәлахның АКШка килеп, ике югары белем алуы, докторлык диссертациясе яклап, атом тикшеренүләре өлкәсендәге күренекле галим булуы, Америка энциклопедияләренә керүе очраклы хәл түгел. Мондый шәхесләр халкыбызда тик бер ул гына түгел. Аның Надир Дәүләт, Шамил Юлай, Айшә Рорлих, Рифат Таби, Әдиб Акчурин кебек илдән читтә җитлегеп тә, татар рухына, татар яшәешенә тугрылыклы булып калган зур галимнәре бар. Аның сигез баласын ияртеп Кытайдан Төркия аша Америкага килгән, шушы балаларны үстереп, белем биреп, аларны зур юлга чыгара алган зур яшәү көченә ия Нәфисә апа Алмакайдай ил аналары бар. Бу гүзәл апабызның токымы бүген 46 кешедән тора. Төпле һәм уңдырышлы тамыр бу.

Оркыя апа Сафалы да — шундый ук юлны үткән гүзәл ханым. Ул — үз балаларына гына түгел, башка яшь татарларга да милли оеткы салган изге зат, 1954 елны Нью-Йорк татар яшьләрен оештырып, Галиәсгар Камалның «Беренче театр»ын, аннары Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә»сен сәхнәгә куйган шәхес. Сан-Франциско шәһәрендә дә милли тормыш гөрләп торды, андагы татарлар да, театраль труппалар төзеп, Галиәсгар Камал әсәрләрен сәхнәләштерделәр. Әгәр дә бүген Америкада Рөстәм Яхин, Салих Сәйдәшев һәм халык җырлары яңгырап тора икән, димәк, милли тормыш дәвам итә.

Финляндиядә саннары беркайчан да бер меңнән артмаган татарларның үз милли мәгариф системасын булдыра алулары, милли җыр-моң белән сугарылып яшәүләре, аларның җәмгыятьтә лаеклы урын биләүләре — шулай ук милләтебезнең яшәү көчен раслый торган мисал. Мондый фактларны күпләп китереп булыр иде. Алар барысы да халкыбызның бөеклеген раслыйлар.

Татар уянды һәм горур адымнар белән халыкара мәйданга юл тотты. Ул яшәгән һәммә җирдә, яңгырдан соң чыккан гөмбәләр кебек, төрле оешмалары үсеп чыктылар. Казан университеты доценты Марат Мөлекев

җитәкчелегендә Татар иҗтимагый үзәге барлыкка килде. Марат Мөлекев, максатчан шәхес буларак, Бөтендөнья татар иҗтимагый үзәгенең төп бурычы итеп Татарстанның статусын күтәрү, аны союздаш республикага әверелдерүне куйды. Фәүзия Бәйрәмова җитәкчелегендәге Милләт мәҗлесе халкыбызны туплады, аңа көч-куәт һәм дәрт биреп тора башлады. Фәүзия ханым — ялкынлы, куркку белмәс шәхес. 90 нчы елларда аны бик күп митингларда, җыелышларда күреп була иде. Үтемле, һәр татарны дулкынландыра, аны азатлык, дәүләтчелегебезне торгызу өчен көрәшкә өнди торган нотыклары әле дә күпләребезнең исендә. Фәүзия ханым бүген дә шушы изге эшләрне дәвам итә. Архивлардан татар язмышына багышланган яңа документлар таба, аларны өйрәнеп, тирән мәгънәле хезмәтләр яза, бертуктаусыз диярлек, төрле җирләрдә яшәгән татарлар белән очрашып тора, аларда милли горурлык хисләрен уята.

Шушы дулкында Бөтендөнья татар конгрессы барлыкка килде. Бу киң җәмәгатьчелек һәм Татарстан хакимиятенең, республика Президенты Минтимер Шәймиевнең уртак инициативасы иде. Озак та үтмәде, Конгресс, кайнап торган татар дөньясының әзер җирлегенә таянып, үзенең эшен җәйләп җибәрде. Аның Башкарма комитетына милләтебезнең күренекле шәхесләре сайланды. Рәис урынбасарлары буларак, күренекле шагыйрь, Дәүләт Советы депутаты Разил Вәлиев, «Азатлык» радиостанциясенең Казандагы үзәк җитәкчесе Римзил Вәлиев, «Сөембикә» журналы мөхәррире, Татар хатын-кызлары җәмгыятен барлыкка китерүче һәм аның җитәкчесе Роза ханым Туфитулова, Башкарма комитетка алардан башка Татарстан Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов, мәгариф һәм мәдәният министрлары Фарис Харисов, Марсель Таишев, Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры Мирфатыйх Зәкиев сайланды. Бу шәхесләр Конгресс эшчәнлеген җәелдерүгә зур өлеш кертте. Тиз арада Конгрессның җирле оешмалары барлыкка килде.

Самара, Ульяновск, Мәскәүдәге оешмалар бигрәк тә зур активлык күрсәтте. Мәскәүдәге «Туган тел» җәмгыятен Нур Гарипов кебек милләтпәрвәр татарлар җитәкләде. Монда татар телен өйрәнү курслары, тел өйрәнү дәреслекләрен булдыру эшләре киң җәелдерелде. Шушы хәрәкәткә шактый күп эшкуарлар кушылып, бу изге эшкә үз өлешләрен керттеләр.

Самарада Шамил Баһаветдинов, Равил Хәйруллин һәм алар тирәсендә дистәләгән татар зыялылары тупланды. Шамил, сәләтле журналист буларак, «Азатлык» радиосы аша татар дөньясындагы яңалыкларны пропагандалауга зур өлеш кертте. Ул бүген дә шушы эшне дәвам итә. Инде мәрхүм Равил абый милли мәгариф эшләрен җиренә җиткереп башкара иде. Самарадагы гына түгел, өлкәнең һәрбер авылындагы мәгариф эшләре аның игътибар үзәгендә булды. Шушы милләтпәрвәр шәхес ничәмә-ничә мәктәпне ябылудан саклап калды. Ул, кирәк булса, теләсә кайсы түрәгә, хәтта губернаторга да кереп, мәгарифебезгә багышланган теләсә нинди мәсьәләне хәл итеп чыга торган иде.

Милли хәрәкәт киң җәелгән үзәкләрнең берсе — Саратов. Монда Фрид Рәшитов, мөфти Мөкатдәс Бибарсов, Митәсим Сөләйманов һәм дистәләгән милләтпәрвәр шәхесләр бүгенге көнгә кадәр милләтебезгә багышланган зур эшләр алып бара. Алар өчен төп мәсьәлә — милли мәгариф, мәдәният, гореф-гадәтләребезне сак-

Татарстан Республикасының Беренче Президенты М.Ш.Шәймиев һәм Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының беренче рәисе И.Р.Таһиров

лау. Аларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә шәһәр уртасында үрнәк булырдай татар гимназиясе барлыкка килде. Монда һәрбер фәннән дә төпле белем бирелә. Үткән ел «оптимизация зәхмәте» өлкәдәге ун татар авылындагы мәктәпкә куркыныч тудырды. Имештер, монда балаларны ашату җайга салынмаган, бәдрәфләре дә урамда. Күренекле эшкуар Камил Әбләзев шушы мәктәпләргә ремонт ясатты, компьютер һәм интернет булдырды. Нәтиҗәдә, мәктәпләр ябылмады.

Иваново шәһәренең Фәрит Ляпин җитәкчелегендәге Милли-мәдәни автономиясе инде күптән милли эшләрне оештыручы төп көчкә әверелде. Монда якшәмбе мәктәбе эшләп килә, Сабан туе бәйрәме традицион төс алды.

Төмән өлкәсендәге Ханты-Манси автономияле округындагы автономияне Чистай мишәре, ни кызганыч, инде мәрхүм Фәнис Рафаил улы Гатауллин җитәкли иде. Мондагы мәһабәт автономия бинасында Татарстан флагы җилферди. Өлкәнең күп шәһәрләрендә автономиянең бүлекчәләре бар. Берничә мәктәптә, шул исәптән Сургут һәм Нижневартовск шәһәрләрендә, татар төркемнәре барлыкка килде. Гомумән, монда милли мәгарифкә һәм мәдәнияткә зур игътибар бирелә.

Омск өлкә автономиясен күп еллар буе тәҗрибәле юрист Хәким Садыйков җитәкләде. Аның белән иңгә иң куеп, абыйсы — тәҗрибәле педагог Хәлил эшләде. Бу автономия дә зур авырлыкларны җиңеп, барлык булган милли оешмаларны берләштерә алды. Өлкә автономиясенең 37 җирле бүлеге бар. Автономия җирле хакимиятне әйдәп, татар теле укытучылары белән махсус эш алып бара. Татар балаларына телебезне өйрәтү, якшәмбе мәктәпләре булдыру эшләренә зур игътибар бирә. Өлкәнең үзешчән коллективлары Омск татарларына гына түгел, хәтта күрше өлкәләргә дә хезмәт күрсәтәләр. Автономия кысаларында Сания Мирхәлиева һәм Рузалия Сайганова радиода татар телендә тапшырулар алып баралар. Шул ук вакытта алар өлкәдәге татар тормышы яңалыкларын «Азатлык» радиостанциясе аша татар җәмәгатьчелегенә җиткереп торалар.

Мордовия милли-мәдәни автономиясен Шамил Закәр улы Бикмаев җитәкли. Ул — күп еллар губернатор киңәшчесе һәм Республика Парламен-

ты депутаты булып торган тәҗрибәле шәхес. Булдыклы эшмәкәр буларак, милли эшләрне башкаруга күп чыгымнар сарыф итә. Республикада татар телен өйрәнүгә, мәктәпләр эшен җанландыруга, бигрәк тә яшьләр, балалар белән эшләүгә зур игътибар бирелә.

Түбән Новгородта да шулай. «Туган як» җәмгыятенең төп эшләре районнарда, бигрәк тә Краснооктябрьский һәм Сергач районнарында алып барыла. Сергачта «Туган як» газетасы чыга. Монда шулай ук татар китаплары да нәшер ителә. Редакция тирәсендә әдәби көчләр туплана. Татарлар күпчелекне тәшкил иткән Краснооктябрьский районында мили тормыш кайный. Иң зур һәм матур Сабантуйлар да шунда үтә. Әмма милли эшләрнең идеология үзәге Түбән Новгородта урнашкан. Андагы Әлимҗан Орлов, Мансур Хафизов кебек гыйлем ияләре милли яшәешкә фәнни нигез биреп килделәр. «Туган як»ның башында торучы Совет җитәкчесе Марат Юнысов та — милли эшкә шулай ук җаны-тәне белән бирелгән шәхес. Бу шәхесләр башлаган изге эшләр бүген дә дәвам итә.

Җаннары-тәннәре белән милләткә хезмәт иткән дистәләрчә шәхесләребезне искә алып китеп булыр иде. Алар Ульян өлкәсендә — Азат Курчаков, Әстерханда — Әнвәр Алмаев, Наилә ханым, Төмәндә — Хәнисә Алишина, Ригада — Атанас Асанавичюс, Зөфәр Зәйнуллин, Илдус Сабитов һәм бик күпләр. Әгәр дә мин Ижау шәһәрендә зур колачлы эш җәелдереп җибәргән Мәсхүт абый Гаратуевны искә алмасам, һич кенә дә дөрес булмас иде. Ул — Удмуртиянең атказанган укытучысы, тирән белемле, зирәк акыллы, милләтебезгә тулысы белән бирелгән шәхес. Милли эшләрнең башында торучы буларак, ул — республикадагы татар мәгариф эшләрен җайга салучы, үз тирәсенә дистәләгән активист туплап, максатчан һәм нәтиҗәле рәвештә эшли торган оешма булдыра алган инсан. Монда да мәгариф эшләре беренче урында. Шәһәрнең татар гимназиясе республикадагы иң алдынгы мәктәпләрнең берсе булып санала. Ижауда татар газетасы чыга башлавында да аның роле бик зур.

Бу елларда туган телебезгә, гореф-гадәтләребезгә кайту, милләтебезне саклап калу, аның бөтенлеген тәэмин итү беренче урында булды. Әлеге юнәлештә «Ак калфак» оешмасы аеруча уңышлы эш алып барды. Ул татар гаиләсе проблемаларын бөтен тулылыгы белән колачлый алды.

Конгресс урыннарда Сабантуйлар үткәрү эшен дә җайлап җибәрде. Төмәндәге, Саратовтагы, Казахстанның Чимкент һәм башка күп шәһәрләрендәге Сабантуйлар меңләгән милләттәшләребезне берләштереп, аларның бер-берсе белән аралашып, аңлашып яшәүләренә юл ачты. Америкада, Төркиядә һәм Австралиядә дә Сабантуйлар үткәрү гадәткә кереп китте. Федераль Сабантуй үткәрелә башлады.

Максатларыбызның берсе — татарлар яшәгән төбәкләрдәге хакмиятләрне татар проблематикасына якынлаштыру, җирле татар оешмалары белән аңлашуны булдыру иде. Шуңа ирешү өчен, төбәкләрдә Конгресс Башкарма комитетының күчмә утырышларын үткәрү иң уңышлы чараларның берсе булды. Конгрессның беренче унъеллыгында алар Екатеринбург, Төмән, Омск, Ульяновск, Казахстанның Чимкент, Кыргызстан башкаласы Бишкәк шәһәрләрендә, Самара өлкәсенең Камышлы районында бик уңышлы үттеләр. Бу җыелышлар җирле хакимият җитәкчеләре һәм киң җәмәгатьчелек катнашында үтеп, бер яктан, бу ике тарафның үзара якынлашуына китерсә, икенче яктан, та-

тар яшәешен бөтен тулылыгы белән күзаллауга юл ачты. Кабул ителгән карарлар татар проблемасын хәл итү өчен мөмкинлекләр ача килде. Кайбер мөһим мәсьәләләр буенча утырышлар Санкт-Петербург, Киев, Минск, Уфа, Әстерхан, Иваново, Нижневартовск, Чиләбе, Пермь шәһәрләрендә булып үтте. Бу очрашуларның һәрберсен Конгресс Башкарма комитетының дипломатик эшчәнлеге дип карарга була. Нәкъ менә шуның аркасында әлеге һәм башка чараларның күбесендә җирле хакимият җитәкчеләре, губернаторлар үзләре катнаша килделәр. Милли эшләребезгә Екатеринбургта — Э.Э.Россель, Саратовта — Д.Ф.Аяцков, Омскида — Л.Полежаев, Санкт-Петербургта В.Яковлев зур кызыксынучанлык күрсәттеләр. Аларның урынбасарлары Конгресс Башкарма комитетының күчмә утырышларында татарлар өчен кылган гамәлләр хакындагы докладлар белән чыгыш ясый, аннан соң безнең оешма җитәкчеләренең докладлары тыңланып, фикер алышулар үткәрелә һәм тиешле карарлар кабул ителә иде. Шушы күчмә утырышлар кысасында Татарстан мәгариф, мәдәният министрлары үзләренең җирле коллегалары белән килешүләр төзүне гадәткә кертте. Шушы рәвештә эшләү җирле хакимият җитәкчеләре белән якынаеп, аларны татар проблемаларына җәлеп итүне җайга салды. Екатеринбургта өлкә губернаторы Э.Э.Россельнең безнең эшләребездә катнашуы үзе генә дә ни тора. Ул — акыллы һәм хәйләкәр немец. Аның белән берничә мәртәбә очрашу безнең Уралдагы вәкиллегебезне ачуга юл ярды, ике-яклы килешү төзүгә сәбәп булды. Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев, Дәүләт Совет Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин аның белән дуслашып та киттеләр. Мин үзем дә аның белән бик яхшы мөнәсәбәттә булдым. Россель, безнең мөстәкыйльлек идеясенә ияреп, Урал Республикасын игълан иткән иде. Мин аңа тәбрикләү телеграммасы җибәрдем. Бер очрашу вакытында аны онытмадыгызмы, дип сорадым. «Юк, һич тә онытмадым, чөнки тәбрикләүчеләр бер-ике генә булды, күпләр курыктылар», — диде. Билгеле ки, бу гамәле өчен Ельцин аны урыннан алган иде. Тик бу кеше альтернатив сайлаулар нәтиҗәсендә янә үз урынына кайты. Бервакыт мин, аңардан: «Ну как Уральская Республика?», — дип сорадым. Ул исә: «Живёт Уральская Республика, мы даже Конституцию сохранили, назвав её Уставом», — диде. Әгәр дә бүгенге көнндә Урал белән эшләр җайланган икән, ә бу чыннан да шулай, монда Татар конгрессының роле зур.

Саратов губернаторы Д.Ф.Аяцков шулай ук татар мәсьәләләре белән ныклап кызыксына, татарларга ярдәм кулын суза иде. Шәһәр уртасындагы гөрләп торган татар гимназиясе аның ярдәме белән аякка басты. Анда укырга керергә теләүчеләрнең саны артканнан-арта бара. Беренче класска керү өчен конкурс: бер урынга — алты кеше. Саратов татарлары аны яратып, Дамир Фатыйхович дип кенә атыйлар иде. Сабантуйларын җайлап җибәрүдә дә аның өлеше зур булды.

Татар конгрессы үзенең беренче унъеллыгында Берләшкән Милләтләр Оешмасының мәгълүмати үзәгендә теркәлде. Конгресс үткәргән чаралар турындагы мәгълүматның шактыен шушы Үзәккә җибәрү дә гадәткә керде.

Конгрессның Башкарма комитеты Бәйсез Дәүләтләр Парламентара Ассамблеясына да күзәтүче рәвешендә кабул ителде. Аның фән, мәгариф, мәдәният эшләре буенча комиссиясенең эшендә актив катнаша. Татарстанның Санкт-Петербургтагы даими вәкиле Шамил Әхмәтшин Кон-

гресс Башкарма комитеты исеменнән комиссиянең карарларын әзерләүдә катнаша.

Әйе, еллар үтә, заманалар үзгәрә тора. Татар халкы да шуларны тоеп яши, яңа шартларда, югалып калмыйча, үзенең татарлыгын күрсәтә тора. Ул —ербөтен бүленмәс халык, аның киләчәге үз кулында. Татар конгрессының егерме еллык тарихы да шуны раслый.

ФӘРИТ ЛЯПИН

Иваново өлкәсе Төбәк татар милли-мәдәни автономиясе советы рәисе

Иваново милли-мәдәни мохтарияте 1993 елның февраль аенда теркәлде. Беренче оешмабыз 15 кешедән тора иде. Безнең алда төп максат — төбәктәге татар халкын берләштерү, бердәм итү, телне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклап калу иде. Ә иң мөһим бурыч — мәчет һәм мәктәп төзү булды.

1994 елның июнь аенда беренче Сабантуй үткәрелде. Шул ук елның сентябрь аенда Якшәмбе мәктәбе ачылды. 25 татар баласы ана теле һәм татар халкы тарихы дәресләренә йөри башлады.

Татар милли оешмасын булдыргач, без Иваново шәһәрендә яшәүче татарлар белән генә түгел, ә төбәктә урнашкан Шуя, Тейково, Фурмонов, Кирнешма шәһәрләре белән элемтәдә торырга һәм җирле татар халкы белән эш алып барырга ниятләдек. Шуңа күрә хәзерге көндә әлеге шәһәрләрдән татарлар яратып фестивальләрдә катнаша һәм үзләрендә дә бик теләп Сабантуйларын уздыралар.

1997 елны мәчет төзү өчен беренче таш салынды, ә инде 2003 елны аны ачу тантанасы булды.

Якшәмбе мәктәбе яңа сулыш алып колач җәя башлады: балалар татар теле, әдәбияты, тарихы дәресләре белән генә түгел, ә җыр-бию, кул эшләре, көрәш белән дә кызыксыналар. Мәчет ачылгач, Якшәмбе мәктәбенә башка төрки халыкларның балалары да тартыла башлады. Аларның ата-аналары балаларга гарәп телен укыту мөмкинлеген сорап мөрәҗәгать итте һәм хакимият гарәп телен укытырга ризалык бирде. Шулай итеп, Якшәмбе мәктәбе үз канаты астына татарларны гына түгел, ә төрки халыкларның балаларын да җыйды. Белем бирүче укытучыларга хөкүмәт хезмәт хакы да түли.

Татар милләтенең, телен, гореф-гадәтләрен саклап калу, үстерү, киләсе буынга җиткерү максатыннан, ел саен мәктәп балалары катнашында Иваново шәһәре һәм өлкәсе өчен аерым-аерым сабантуйлар үткәрелә. Үзәк китапханәдә һәр елның 30 августында «Татарстан көне», ә октябрь аенда «Татар мәдәнияте көне» үткәрелә. Апрель исә «Тукай ае» дип санала һәм шуңа да төрледән-төрле чаралар, милләтнең олы шәхесләренә багышланган кичәләр оештырыла.

Телне саклап калуда, милләтне берләштерүдә «Милләтем» театр студиясенең роле бик зур. Татар классикасының күркәм үрнәге булган Туфан Миңнуллин әсәрләрен сәхнәләштерү, телне белмәгән яки белеп тә оныткан яшьләр белән моны оештырып чыгу җиңел эшләрдән түгел. Труппа хәзерге вакытта «Әниләр һәм бәбиләр» спектаклен сәхнәләштерү өстендә эш алып бара. Чараларны җиренә җиткереп оештырырга Тататарстан Республикасы һәм

Тәтеш районы администрациясе зур ярдәм күрсәтә.

Кыенлыклар турында да әйтеп китәргә кирәк. Ул — милләттәшләрнең битарафлыгы һәм финанс кысынкылыгы. Нинди генә эшне башкарырга тотынсак та, финанс ягыннан авырлыкларга килеп терәләбез, шунлыктан кайбер планлаштырылган эшләр елдан-ел артта калырга мәҗбүр.

БАКИР АКЪЕГЕТОВ
Пенза өлкәсе Төбәк татар милли-мәдәни автономиясе советы рәисе

Пенза өлкәсе татар авылларының 35ендә туган тел укытыла. Кызганычка каршы, соңгы елларда татар телен укыту сәгатьләре кими бара, күпчелек мәктәпләрдә ул факультатив формада гына укытыла. Ике татар авылында мәктәпләр бөтенләй ябылды, балаларны укырга күрше рус мәктәбенә йөртәләр. Үзгәртеп кору елларында күпчелек татар авылларыннан халык шәһәрләргә китте, шунлыктан авылларда кешеләр саны өчтән бергә кимеде. Мисалга, Кикин авылында совет чорында 2500 кеше булса, хәзер ике тапкыр азрак. Яшьләр кимү сәбәпле, Танкаевка авылында бөтенләй балалар туманган. Анда мәктәп тә, мәчет тә юк. Пенза шәһәрендә академик Әдһәм Тенишев яшәгән йортны җимереп ташладылар. Заманында аларның гаиләсе Пензаның хәзерге олы мәчетен үз чыгымнарына төзеткән. Гомумән, җирле җәмгыять өчен зур эшләр эшләгәннәр. Үзгәртеп кору елларында өлкәбезнең Кузнецк һәм Каменка район үзәкләрендә татарча телевизион тапшырулар башланып киткән иде, алар юк инде.

Өлкәбездә 1989 елдан «Якташлар» татар милли-мәдәни җәмгыяте эшләп килә. 2003 елда милли мохтарият барлыкка килде, дини оешмалар да эшли.

Автономиянең эшенә килгәндә, өлкәнең 12 районында татар милли-мәдәни автономияләре булдырылды, алар белән элемтәбез нык. Татар автономиясе булмаган авылларда милли мәсьәләләрне чишү белән активистлар шөгыльләнә. Алар белән бергә Сабантуй бәйрәме үткәрәбез.

Инде икенче ел татарча «Пенза татарлары» һәм русча «Пензенский меджлис» газеталары аена бер мәртәбә чыгарыла, 2011 елдан автономиябезнең сайты да эшли. «Татары Пензенского края» исемле китап бастырып чыгардык.

2012 елда өлкә автономиясенең бинасын төзекләндерә башладык. Анда татар мәктәбе, Пенза өлкәсе татарларының музее, китапханә, балалар бакчасы ачарга ниятлибез. Ул яшьләргә кичәләр үткәрергә һәм өлкәннәргә җыелыр өчен урын булыр дип уйлыйбыз. Өлкә телевидениесендә «хәбәрче пункты» ачарга планлаштырабыз.

Татар мәктәпләренә китаплар, методик әдәбият белән булышабыз, татар газеталары аша аларга милли тормыштагы бөтен яңалыкларны җиткерергә тырышабыз.

2011 елны Пензада яңа мәчет төзелә башлады, «Сияние» исемле хәйрия фонды оештырылды. Дини оешма тарафыннан хәзерге Тенишевлар мәчете янындагы мәйдан базар оештыру өчен арендага бирелде. Шуннан кергән акча мәчет төзелешенә файдаланыла. Мәчет төзелешендә дини оешмалар белән берлектә безнең

автономия дә актив катнаша. Тиздән бу мәчет төзелешен тәмамлап халыкка тапшырырбыз, дип өметләнәбез.

Шунысын да әйтергә кирәк: төрле елларда аерым милләтпәрвәрләр тырышлыгы белән авылларга багышланган 8 китап чыгарылды.

ӘНВӘР АЛМАЕВ
Әстерхан Өлкә Думасы депутаты, Дума рәисенең беренче урынбасары, Әстерхан «Дуслык» милли-мәдәни җәмгыяте рәисе

Әстерхан «Дуслык» милли-мәдәни җәмгыяте 20 ел дәверендә татар милли йолаларын тергезүдә, үстерүдә шактый эшләр башкарды. Шуларның иң мөһиме — төбәктә юкка чыгып барган Сабантуй, Нәүрүз бәйрәмнәрен кабат тормышка кайтару булды. Төбәктә Сабантуй 1988-1989 елларда Яңа Болгар, Җәмәли авылларында яңарыш алса, ел саен бу бәйрәмнең географиясе киңәя барды, эчтәлеге тулыланды. Ә 2008 елда Әстерхан Федераль Сабан туе 40 төбәктән милләттәшләребезне кабул итте.

Төбәктә 1990 елда «Дуслык» оешмасында «Идел» татар яшьләр инструменталь (җитәкчесе Р.Садретдинов) һәм «Ялкын» татар фольклор ансамбльләре (хәзерге җитәкчесе Г.Аҗгильдиева) оешты, ә 1992 елда «Умырзая» балалар-яшүсмерләр ансамбле (җитәкчесе Т.Сармульдиев) эшли башлады. Шулай ук милли «Нур» балалар студиясе (җитәкчесе М.Яваева) һәм вокал буенча яшьләрне әзерли торган «Сандугач оясы» төркеме (җитәкчесе Р.Идиатуллина) эшчәнлекләре дә игътибарга лаек.

Әстерхан өлкәсендә бай тарихлы татар халык театры яңарыш алуы турында да әйтеп китәргә кирәк. Труппа Әстерхан өлкәсенең Яшь тамашачылар театры, филармония кебек зур сәхнәләрендә үзләренең спектакльләрен, милли концертларын куя. 1998 елдан театрның репертуары киңәя, ел саен бер-ике яңа спектакль куела, сирәк-мирәк булса да гастрольләргә дә чыккалыйлар. Шушы 20 ел эчендә генә дә театр тарафыннан 220 спектакль сәхнәләштерелде һәм концерт программасы әзерләнде.

2002 елдан алып бу көнгә кадәр өлкә күләмендә беренче татар милли китапханәсе эшләп килә. Ул, татар авылларының мәктәп китапханәләре белән элемтәдә торып, Казаннан яңа килгән китапларны тапшыру, истәлекле даталарны билгеләп үтү, олуг татар шәхесләренә, шигърияткә бәйле әдәби һәм мәдәни чаралар уздыру кебек эшләрне башкара. 2002-2005 елларда китапханә кысасында татар теле укытыла торган якшәмбе мәктәбе эшләп килде. Хәзерге көндә якшәмбе укулары бары тик аерым теләк белдерүчеләргә индивидуаль рәвештә генә уздырыла.

Татар теле, факультатив рәвештә булса да, татарлар күпләп яшәгән район, авыл мәктәпләрендә укытыла. Әстерхан дәүләт университетының филология факультетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге эшләп килә. Өлкәдә Федерация күләмендә беренче тапкыр татар теле укытучылары бәйгесе оештырылды.

Әстерхан өлкәсендә аена ике мәртәбә мең данә тираж белән рәсми теркәлгән «Идел» газетасы чыга. «Идел» газетасының 100 еллыгы уңаеннан олуг татар мәгърифәтчесе Габдрахман Гомәригә багышланган

фәнни-гамәли конференция уздырылды, аның материаллары китапчык итеп бастырылды.

Әстерхан төбәге шагыйрьләре М.Умәрова, С.Досаева, З.Иждбирдиева, Я.Измайлов, Р.Җаббаровларның татар телендә китаплары нәшер ителде. Шулай ук 2010 елда «Культура астраханских татар» исемле китап басылып чыгу да тарихи әһәмияткә ия.

Әмма милли тормышыбызда зур югалтулар да булды: 2004 елда телевидение һәм радиодан атнага бер мәртәбә эфирга чыга торган «Туган тел» тапшыруының бетерелүе, «Идел» һәм «Умырзая» яшьләр инструменталь ансамбльләре әгъзаларының зур иҗади төркемнәргә кушылуы, 21 нче «Теремкәй» балалар бакчасында милли тәрбиянең бетерелүе шундыйлардан.

Киләчәктә Әстерхан өлкәсендә милли тормышны саклап калу һәм үстерү өчен «Дуслык» җәмгыяте татар гимназиясе ачуны; телевидение һәм радиода татар телендә чыга торган «Туган тел» тапшыруын яңартуны; татар театрының үз бинасын булдыруны; татар телендә иҗат итүче җирле авторларның әсәрләрен нәшер итүне; Г.Тукай скверын һәм һәйкәлен урнаштыру эшләрен төгәлләүне; Әстерхан өлкәсендә туып-үскән, шунда яшәгән беренче татар хатын-кыз шагыйрәсе Газизә Сәмитованың 150 еллык юбилее уңаеннан фәнни-гамәли конференция уздыруны һәм аңа багышланган китап чыгаруны; «Әстерханның асыл татар ир-атлары» чарасын үткәрүне планлаштыра.

Әлбәттә, кыенлыклар да юк түгел. Алар финанс мөмкинлекләре җитмәүгә барып тоташа. Хөкүмәттән бик кечкенә генә ярдәм бары тик сабантуйларны уздыруга гына бирелә. Шуңа күрә төп таянычыбыз иганәчеләрдә. «Лукойл» кара алтын компаниясе дә ярдәмсез калдырмый. Үзебезнең иҗади төркемнәр, концертлар биреп, берникадәр матди ярдәм итә. Шулай ук Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының да ярдәме бәяләп бетергесез.

Шунысын да әйтергә кирәк: бездәге татар милли тормышында Әстерхан Өлкә Думасының татар депутатлары да зур роль уйный. Без бүген Думада 7 татар вәкиле эшлибез.

ЗӨФӘР ХӘКИМОВ

Саратов өлкәсе Төбәк татар милли-мәдәни автономиясенең Башкарма комитеты рәисе

Саратов Төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте 1994 елда оешты. Совет үз эченә 35 кешене ала, ә Саратов милли-мәдәни мохтарияте 9 кешедән тора. Саратов милли-мәдәни мохтарияте эшчәнлегенең мөһим юнәлешләре булып татар мәдәниятен, телен һәм мәгърифәтен үстерү санала. Өлкә Мәгариф министрлыгы ярдәмендә 10 урта мәктәп, Президентның милли мәгариф программасы буенча 3 грант иясе һәм Татарстан Республикасы Президенты 1 млн сум акчалата ярдәм иткән Саратов милли (татар) гимназиясе татар милли компоненты нигезендә эшли.

Саратов милли-мәдәни мохтарияте татар ветераннарына, пенсионерларына, күпбалалы гаиләләренә даими ярдәм итеп тора. Һәр ел саен Җиңү көнендә Бөек Ватан сугышы ветераннарына акчалата премия һәм атап алынган бүләкләр тапшырыла. К.Әбләзев җитәкчелегендәге Саратов

татар милли-мәдәни мохтарияте советы Саратов шәһәре җәмигъ мәчете, татарлар күпләп яши торган 5 шәһәр һәм авыл мәчетләре төзелешендә актив катнашты. Хәзер мохтарият хисабына һәм шәхси эшмәкәрләр ярдәмендә Энгельс шәһәрендә Сажидә мәчете салына. Мохтарият Рамазан аенда шәһәр һәм авылларда хәйрия ифтарлары үткәрә. Мохтарият химаясенә эшли торган мәчетләр дә бар. 2010 елны Биктимер авылында һәм шул елның июнь аенда Күчүмбәт авылында, ә 2011 елны К.Маркс һәм Татар Пакаевкасы авылларында мәчетләр ачылды. Саратов милли-мәдәни мохтарияте һәр елны Саратов өлкә хөкүмәте һәм Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты ярдәмендә өлкәдә Татар мәдәнияте көннәре үткәрә.

Татарстан Республикасы вәкиллеге һәм Саратов татар милли-мәдәни мохтарияте ярдәмендә өлкәдә татар телендә «Сары тау» газетасы чыга.

2010 елның апрелендә «Нарат-К» ҖЧҖ хисабына «О прошлом и настоящем татар Саратовской области» китабы кабат бастырып чыгарылды. 2011 елны Саратов өлкәсенең «Идел» татар-башкорт мәдәни-мәгариф оешмасына 20 ел тулу уңаеннан, Саратов өлкәсе татарлары тарихын чагылдырган (авторы тарих фәннәре докторы, профессор Ф.Рәшитов) китап басылып чыкты.

Рөстәм Гыйльметдинов җитәкчелегендәге «Сары тау» татар яшьләр оешмасы актив эшләп килә. Татар егетләреннән оешкан футбол командасы 2010 елның май аенда, 2011 һәм 2012 елларның июнь айларында үткәрелгән милләтара футбол турнирларында беренче урын яулады. Моннан тыш яшьләр очрашулары һәм диспутлары, ял кичәләре үткәрелә, «Баш кода» исемле таныштыру клубы эшләп килә.

Саратов татар милли-мәдәни мохтарияте Саратов шәһәренең Соколов тавында урнашкан Җиңү паркындагы милли авыл эшендә катнаша. Татар көнкүреше атрибутларын үз эченә алган Татар йорты эшләп килә. 2012 елның 28 сентябрендә Татар йортында Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов булып китте, татар җәмәгатьчелеге һәм эшмәкәрләре белән очрашу үткәрде. Очрашу тәмамлангач, Саратов татар миллли-мәдәни мохтариятенә музей-йорт, татар мунчасы, каралты-курадан торган, Татар йорты өчен яңа комплекс бүләк итте.

Һәр елны «Идел йолдызчыклары» балалар фестивале, татар теленнән олимпиадалар үткәрелә, инде 15 нче тапкыр «Народы Поволжья: история, образование и культура» темасына фәнни-гамәли конференцияләр үткәрелде.

Саратов татар милли-мәдәни мохта-

рияте татар телен өйрәнә торган авыл мәктәпләрен яңа уку елына әзерләүдә актив катнаша, бу максаттан һәр елны Саратов татар милли-мәдәни мохтарияте җитәкчесе К.Әбләзев идарә итә торган «Нарат-К» компаниясе тарафыннан аларны төзекләндерү өчен акча күчерелә.

ФӘРИТ ГЫЙБАТДИНОВ
Чувашстан Республикасы Төбәк татар милли-мәдәни автономиясе советы рәисе, Татарстанның һәм Чувашстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

Чувашстан җирлегендә 20ләп татар авылы бар. 13 татар урта гомуми белем бирү мәктәбе, 6 катнаш мәктәп, 4 татар балалар бакчасы, 4 татар авылында сәнгать мәктәбе эшли. Республикабызда Фәрит Чабатов җитәкчелегендә «Татарча көрәш» федерациясе эшләп килә. Чувашстан мөселманнары Дения нәзарәтен 1994 елдан җитәкләгән Әлбир хәзрәт Кргановның иҗтимагый тормышта роле зур.

Бездә татар иҗтимагый хәрәкәте 1997 елда барлыкка килде. Мәчетмәхәлләләр Үзәк Диния нәзарәтенә караса, Чувашстан татарларының милли-мәдәни мохтарияте Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчелегендә эш итә. Чабаксар, Яңа Чабаксар, Канаш шәһәрләрендә, Ибрәс, Батыр, Комсомол районнарында җирле милли-мәдәни мохтариятләр эшләп килә.

Авылларыбызда эшкуарлык җәйләнып китте. Тик авыл хуҗалыгы елдан-ел мескен хәлдә кала бара. Республиканың татар иҗтимагый хәрәкәте әйдәманнары фикеренчә, бүгенге татар авыллары көчле, татар рухлы булсын өчен барлык дини, иҗтимагый хәрәкәтләр, социаль көнкүреш оешмалар, мәгариф, мәдәният, спорт учреждениеләре, эшмәкәрләр берләшеп хезмәттәшлек итәргә тиеш.

Һәр татар авылында бертигез эш алып барыла дип булмый әле. Бигрәк тә шәһәрләрдә татарлар белән эшләү җайга салынмаган. Шулай да һәрбер торак пунктында авыл мәчете тирәсендә мәхәлләне торгызу өстендә эшчәнлек алып барыла, җирле милли-мәдәни мохтариятләр төзелә. Араларында бу процессны күптән түгел генә башлаган авылларыбыз булса да, инде бу юнәлештә шактый алга киткәннәр дә бар. Батыр районының Шыгырдан, Татар Сыгыты, Кыр Бихшиге, Озын куак, Кызыл чишмә авыллары, Комсомол районының Урмай, Тукай, Чичкан авыллары, Козловка районы Кармыш, Шемурша районы Байтирәк, Балтай, Яльчек районыннан Сыриле авылы турында мактанып бөтен татар дөньясына сөйләп була.

Шыгырдан авылы — Чувашстан мөселманнарының Диния нәзарәте үзәге. Биредә Икенче Бөтенроссия татар авыллары Сабан туе үтте, тугызынчы тапкыр «Шыгырдан укулары» төбәкара конференция уздырыла. Зурлыгы буенча икенче урында торган Урмай авылын бүген Чувашстан татарларының мәдәни үзәге дип әйтергә була. Аның җирлегендә чирек гасыр дәвамында һәр ел саен «Урмай моңы» халыкара татар эстрада фестивале үткәрелә, соңгы алты ел дәвамында «Art-Madhia» мөселманча җырлар, мөнәҗәт-бәетләр, нәшидләр фестивале «Зикер, фикер, шөкер» шигаре астында унышлы гына бара. Киләсе елда Россия күләмендә төрки

халыкларның традицион мәдәнияте буенча «Зәлидә» фестивален башларга ниятлибез.

Шунысы куанычлы: авылларыбызда үлүчеләргә караганда туучылар саны ике мәртәбә күбрәк. Ел саен Шыгырданда уртача 80-100, Урмайда 40-50, Тукайда 35-45 бала дөньяга килә. Яшьләр авылда төпләнә. Шуңа күрә авылларыбыз зурая, үсә. Татар мәктәпләре гөрләп яши. Россия күләмендә татар теле буенча үткәрелгән олимпиадаларда Шыгырдан, Чичкан, Тукай, Урмай авылы мәктәпләренең укучылары дистә ел дәвамында җиңүчеләр исемлегендә. Ел саен татар мәктәпләре арасында «Туган ягым, моңлы ягым» исемле күчмә бәйгеләр үтә.

Шыгырданда алты мәчет, Урмайда, Татар Сыгытында — өчәр, Кыр Бихшигендә ике мәчет бар. Бу авылларда мәдрәсәләр эшләп килә. Шыгырданның «Өч сәхабә», Урмайның «Кара пулат» мәчетләре Болгар архитектура тыюлыгы ядкәрләре үрнәгендә төзелгән.

Бигрәк тә зур авылларда (Шыгырдан, Урмай, Тукай, Озын куак) йөзләгән милләттәшебез, кече эшкуарлык белән шөгыльләнеп, туган авылларына хезмәт итәләр, зәкятләрен, матди ярдәмнәрен авыл тормышын, динен, мәдәниятен, спортын үстерүгә сарыф итәләр. Милли көрәш, волейбол, футбол, хоккей буенча төрле бәйгеләр уздырыла.

Урмайдагы «Мишәр» халык фольклор һәм эстрада ансамбле әле шушы көннәрдә генә Самара шәһәрендә үткән фольклор фестивалендә ике номинациядә икенче һәм өченче урыннарга лаек булды. Ансамбль артистлары ел саен Төркиянең Әнкара, Истанбул шәһәрләрендә халыкара фестивальләрдә катнашалар, Мәскәү, Мурманск, Төмән, Кабардин-Балкар Республикасы, Идел буе шәһәрләрендә һәм татар авылларында, бигрәк тә Чувашстанда кызыклы концертлар куялар. Фәтхи Бурнашның туган авылы Кыр Бихшигендә эшләп килә торган, «Халык» театры исеменә лаек булган тагын бер үзешчән коллектив Батыр районында ярты гасыр дәвамында милләттәшләребезне татар драматургиясенең иң гүзәл үрнәкләре белән даими таныштырып бара.

Авылларда рәсми рәвештә теркәлгән йөздән артык эре эшкуар бар. Безнең яклар — төзүчеләр төбәге. Алар Мәскәүдән алып ерак Себерләргә кадәр барып житәләр. Еракта эшләсәләр дә, туган авылларына кайтып, гаиләләрен тәэмин итәләр, искитәрлек зур йортлар төзиләр.

Башка төбәкләрдәге кебек Чувашстанның татар авыллары да дәүләттән әллә ни ярдәм күрмәде. Авыл халкы: «Дәүләттән көтеп ятып булмый, үзебезгә тырышырга кирәк», — дигән нәтиҗәгә килде, үз хисапларыннан юлларны тәртипкә китерде, ун ел элек авылларга газ кертте.

2007 елда баш мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин мәчетләр каршында иҗтимагый киңәшмә төзү турында карар чыгарды. Тукай, Шыгырдан, Урмай авылы мәхәлләләрендә Россиядә беренчеләрдән булып шундый киңәшмәләр оештырылды.

Республикада «Вакыт» исемле татар газетасы чыгып килә, интернет челтәрендә татар авылларының сайтлары бар. Urmai.ru сайтында «Көмеш каләм» дип аталган конкурс уңышлы гына үткәрелеп килә.

Бүгенге көндә татар авылында гореф-гадәтләребезгә, мәдәниятебезгә, дини кануннарга нигезләнгән чын демократик җәмгыять тергезелде. Әлеге эшчәнлегебез халык җыеннары аша легальләштерелде.

РӘМИС САФИН
Ульяновск өлкәсе Төбәк татар милли мәдәни-автономиясенең Башкарма комитеты рәисе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Татарстан — Яңа гасыр» телеканалының Ульяновск филиалы директоры

Соңгы җанисәп нәтиҗәләре буенча, Ульяновск өлкәсенең 67 торак пунктында 150 меңнән артык татар гомер кичерә, алар өлкәдә яшәүчеләрнең 12%ын алып тора. Бүген Өлкә законнар чыгару җыелышына һәм Ульяновск шәһәр Думасына дүртәр татар депутаты сайланды. 14 милләттәшебез профессор исеменә, 105е фән кандидаты гыйльми дәрәҗәсенә ия.

Хакимият, мәгариф һәм мәдәният органнарында татар халкының мәнфәгатьләрен илдә беренчеләрдән булып төзелгән Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясе яклый. Безнең Башкарма комитет составына 5 профессор һәм фән кандидаты, 15 Россиянең һәм Татарстанның атказанган эшлеклесе, 9 мәгариф хезмәткәре, 12 эшмәкәр — барлыгы 96 кеше керә. Соңгы елларда барча муниципаль берәмлекләрдә дә Миллимәдәни автономиянең район советлары булдырылды. Алар, җирле район хакимияте белән уртак тел табып, нәтиҗәле эш алып баралар.

Мәгариф өлкәсендә горурланырлык уңышларыбыз бар. 2004 елда Димитровград шәһәрендә татар мәктәбе ачылды. Бүген анда укырга теләүчеләрне конкурс нигезендә кабул итәргә кирәклеге турында уйланабыз. Мәктәптә урын җитмәгәнлектән, балаларның күбесе башка мәктәпләргә китә. Шунысы сөендерә: әлеге мәктәпне тәмамлаган укучыларның 98%ы Казанда, Ульяновскида һ.б. шәһәрләрдәге югары уку йортларына керә.

Ун ел элек татар теле өлкә мәктәпләрнең 25-30%ында өйрәнелсә, соңгы елларда бу сан 50%ка якынлашты. Бүген Ульяновск өлкәсе мәктәпләрендә белем алучы балаларның 50%тан артыгы (10 ел элек 32% иде) ана телен фән буларак яки факультатив дәресләрдә һәм түгәрәкләрдә өйрәнә. Кызганычка каршы, һәр төбәктәге кебек, өлкәдә мәктәпләр һәм укучылар саны, шул исәптән татар балалары саны елдан-ел кими бара. Мәктәпләргә акчаны бала санына карап бүлеп бирә башлау тискәре йогынты ясады. Шунлыктан 2006 елда Ульяновск шәһәрендә ачылган татар мәктәбе быел янәшәдәге мәктәп белән берләштерелде. Авырлык белән булса да, шәһәр Мәгариф идарәсе белән уртак тел табып, биредә татар телен дәрес буларак укытуны калдыра алдык. Мәктәптә татар, чуваш һәм мукшы балалары ана телләрендә белем ала. Монда һәр милләтнең үз мәдәни үзәге дә булдырылды. Без бүген биредә татар халкы тарихы һәм мәдәнияте музеен оештырырга йөрибез.

Проблемалар һәм югалтулар турында сөйләгәндә, Ульяновск дәүләт педагогия университетындагы милли төркем турында да әйтми мөмкин түгел. Узган гасырның 90 нчы елларында ачылган һәм бюджет хисабына укытыла торган татар һәм чуваш төркемнәре, укырга килүчеләр булмаганлыктан, бүген ябылу алдында тора. Бүлекнең абруен күтәрү һәм абитуриентларны җәлеп итү өчен вуз җитәкчелеге татар теле укыту-

чыларына рус теле укыту хокукын да бирә башлаган иде. Ләкин куйган уртак максатыбызга барыбер дә ирешә алмадык. Алдагы уку елында да килүчеләр булмаса, бу төркемнең киләчәге өметсез...

Соңгы 20 елда татарлар яши торган авылларга Казан артистлары килми башлады. Бу бушлыкны тутыру максатыннан, Өлкә милли-мәдәни татар автономиясе Татар мәдәнияте үзәге артистлары белән бергәләп һәр ай саен «Татар теле һәм сәнгате көннәре» уздыра. Чарада концерт куеп, күңел ачу белән генә чикләнмибез, җирле милли тормышны җанландыру, андагы проблемалар хакында да сөйләшәбез, аларга район башлыкларын, мәдәният һәм мәгариф бүлеге җитәкчеләрен чакырабыз. Шундый чараларның берсе Павловка районы хакимияте җитәкчесе катнашында Татар Шмалагы авылында узды. Андагы китапханәгә татар китаплары соңгы тапкыр моннан 20 ел элек кайткан булган, акча юклыкка сылтау итеп, өлкәбезнең «Өмет» газетасына да язылмый башлаганнар. Бу сөйләшүдә район башлыгы әлеге кимчелекләрне төзәтергә күрсәтмә бирде.

Китапханәче Гөлфия Сәмигуллина тырышлыгы белән бер-берсен кабатламый торган чаралар уйлап табыла һәм мавыктыргыч итеп уздырыла. Ульяновск шәһәренең 17 нче китапханәсе милләттәшләребезнең китап алу яисә китап уку урыны гына түгел, ә төрле бәйрәмнәр, очрашу һәм кичәләр үткәрү үзәгенә әверелде. Шунысы игътибарга лаек: бирегә әби-бабалары белән бергә сабыйлар да җыела.

Халкыбызның гореф-гадәтләрен саклауда һәм үстерүдә дүрт ел элек өлкә бюджеты хисабына Татар мәдәнияте үзәге ачылу зур этәргеч ясады. Аның составындагы 21 кеше (иҗади һәм техник хезмәткәрләр белән бергә) татар мәдәниятенә хезмәт итә. Үзәкнең иҗат коллективларына 5 яшьтән алып 75 яшькә кадәрле үзешчәннәр йөри. Татарстанның атказанган артисты, Ульяновск өлкәсенең атказанган мәдәният хезмәткәре Әлфия Рамазанова җитәкләгән төркемнәр өлкәбездә генә түгел, якынтирәдәге төбәкләрдә уза торган фестиваль-конкурсларда катнашып, призлы урыннар алып кайталар. Әлфия ханым мәктәбен узган татар балалары бүген Казан дәүләт консерваториясендә һәм сәнгать университетында белем ала. Үз эшенең остасы, тәҗрибәле музыка җитәкчесе Гөлнара Тарасова һәм Алсу Әлмәтовалар төркемнәренә сабыйлар яратып йөри.

Мәдәни үзәктә халкыбыз мәгарифенә һәм мәдәниятенә багышланган даими эшли һәм яңартылып тора торган күргәзмә ачылу да бирегә килүчеләрдә зур кызыксыну уята. Ә узган ел Мәдәният үзәге җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рамилә Сафина инициативасы белән беренче тапкыр «Сембер сөлгесе» дигән гаҗәеп кызыклы күргәзмә эшләде. Биредә өлкәбездә яшәп иҗат итүче рәссамнарыбызның эшләреннән торган күргәзмәләр дә оештырыла. 2010 елда өлкәбездә тагын бер яңа проектка нигез салынды — беренче тапкыр Яңа Малыклы районында татар гармунчыларының «Уйна, Сембер гармуны!» дигән фестиваль уздырылды. Анда 30дан артык гармунчы катнашты. Шунысы сөенечле: бу чарада балалар һәм яшүсмерләр дә зур активлык күрсәтте.

Өлкәбездә Иске Кулатка (уникаль) районы бар. 96% татарлардан торган бу районда 1932 елдан бирле татар телендә «Күмәк көч» исемле газета чыга, үзләренең «Яңа дулкын» телеканалы эшли. Авыл мәктәпләрендә программа нигезендә балаларга татар теле һәм әдәбияты укытыла, мәчетләр, алар каршында

мәдрәсәләр эшләп килә. Тагын бер күңелле күренеш — кайбер авылларда 90 нчы елларда ябылган балалар бакчалары яңадан ачыла, балалар туу арта.

23 ел элек өлкә телевидениесендә татар телендә «Чишмә» һәм чуваш телендә «Еткер» исемле тапшырулар эфирга чыга башлады. Төрле сәбәпләр табып, аларны 18 елдан соң яптылар. Әлбәттә, бу халыкта зур ризасызлык тудырды. Шуңа күрә өлкә Губернаторы Сергей Морозов бу тапшыруларны өлкә бюджеты хисабына яңадан эфирга чыгарырга дигән карарга кул куйды. Бүген әлеге тапшырулар аена ике тапкыр 20шәр минут тамашачыларны милли тормыш белән таныштырып бара. 1990 елдан бирле чыгып килә торган «Өмет» газетасының да тиражы елдан-ел арта бара. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Исхак Хәлимов җитәкли торган бу редакция базасында соңгы елларда Сембер төбәгендә иҗат итүче татар язучы һәм шагыйрьләренең 40тан артык китабы басылып чыкты. Бу эш бүген дә уңышлы дәвам итә.

Татарстаннан читтә яшәүче татарларга милли мәгариф системасын җайга салу элек тә авыр булган, хәзер дә җиңел түгел, алга таба тагын да катлаулы булачак. Федераль Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан елдан-ел милли телләрне укытуны тыя торган кырыс карарлар кабул итә. Татар авылларында мәктәпләр ябылу безгә икеләтә авырлык тудыра, балаларыбызны күрше рус яисә чуваш авылы мәктәпләренә автобуслар белән йөртеп укыта башладылар. Анда мохит тә, тәрбия дә безнеке түгел, татар телен укыту турында бары тик хыялланырга гына кала.

Моннан биш ел элек, федераль укыту программасына сылтау итеп, татар авылларында беренче сыйныфта «Әлифба» буенча укытмый башлаганнар иде. Безнең өлкәдә узган Бөтендөнья татар конгрессының күчмә утырышында бу хакта губернаторга әйттек. Ул мәгариф чиновникларына яңа уку елыннан әлеге хатаны төзәтергә күрсәтмә бирде. БТК ярдәме белән 300дән артык «Әлифба»

китабы алып кайттык һәм татар авылларына тараттык.

Бүген шундый заман: яшел флаглар күтәреп яисә ачлык игълан итеп һәм урамнарга чыгып кына нәрсәгәдер ирешеп булмый. Күп әйбергә җирле хакимият белән уртак тел табып, уртак фикергә килү юлы белән ирешелә. Биш елдан бирле өлкә губернаторы рәислегендә Милләтләр Советы эшләп килә. Анда өлкәдә эшләүче һәр милли оешма җитәкчесе әгъза булып тора. Өч айга бер тапкыр уза торган киңәшмәдә без үзебезне борчыган барлык мәсьәләләр хакында сөйләшәбез. Барысы да булмаса да, аларның күбесе иртәме-соңмы чишелеш таба. Әлбәттә, ярдәм икеяклы булырга тиеш. Без үзебез дә хакимият алдында бурычлы булып калмыйбыз. Һәртөрле сайлауларда, хөкүмәт уздыра торган социаль акцияләрдә, мәдәни чараларда актив катнашабыз.

ФӘВИЯ САФИУЛЛИНА
«Урал татарлары» конгрессы идарәсе рәисе урынбасары, «Милли медиа-холдинг» директоры, «Саф чишмә» газетасының баш мөхәррире, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

Милли яңарыш чоры дип без XX гасырның 80 нче еллар ахыры — 90 нчы еллар башын атыйбыз. Милләт язмышына битараф булмаган милләтпәрвәрләребез — Сөфхәт Надыйров, Фәрит Шәңгәрәев, Элиза Сафиуллина һәм башкалар — 90 нчы еллар башында татар милләте үсешен җанландырып җибәрүдә үзләреннән күп өлеш керткән шәхесләр.

1992 елда Казан шәһәрендә җир шарына сибелеп яшәгән татарларны бергә туплап уздырылган иң беренче корылтай барлык төбәкләрдә татар тормышын җанландырып җибәргән зур бер этәргеч булды. 1993 елдан Свердловск өлкәсендә Артёмовский шәһәре телерадиокомпаниясе нигезендә «Безнең көн» исемле татарча тапшырулар чыгарыла башлады, Свердловск дәүләт телерадиокомпаниясе ярдәме белән «Мирас» дип аталган атналык татарча радиотапшырулар яңгырады, «Яраткан моңнар» исемле татар җыры фестивальләре, сабантуйлар, концертлар колач җәйде. 1997 елда Свердловск өлкәсе татарларының милли-мәдәни автономиясе төзелде. Шулай ук өлкәнең төрле шәһәр һәм районнарында татар милли оешмалары барлыкка килде. Кызганыч, 90 нчы елларда төзелеп эшли башлаган ул оешмаларның кайберләренең эшчәнлеге бары тик кәгазьдә генә калды…

Үсешнең яңа баскычы 2002 елларга (Бөтендөнья татар конгрессының Өченче корылтаеннан соң) туры килә. Милли тормыш нәкъ шулчакта энтузиазм дәрәҗәсеннән хөкүмәт югарылыгына күтәрелде дип санарга нигез җитәрлек. Татар милләте язмышына битараф булмаган яңа буын — эшмәкәрләр буыны үсеп чыкты. Ринат Садриев, Ринат Әскәров, Альберт Абзалов, Фәрит Нәбиуллин һ.б. үз халкын яратучы, аның киләчәге өчен җан атучы егетләр өр-яңа проектларны тормышка ашыра башлады. Алар арасыннан ел саен хөкүмәт карарлары нигезендә зурлап уздырыла торган Өлкә сабантуйларын, «Урал сандугачы» төбәкара татар җыры фестивальләрен, «Сәләтле балалар» проектын, ун елдан артык чыгып килә торган «Саф чишмә» татар газетасын,

«Урал татарлары» сайтын һ.б. бик күп чараларны атарга булыр иде.

Бүгенге көн мөмкинлеге — интернет челтәрендә «Урал татарлары» (www.tatary-urala.ru) конгрессы сайты булуы уңышларыбызны арттырды. Сайтка керүчеләр Урал татарлары тормышыннан яңалыклар, конгресс эшчәнлеге, даими партнёрларыбыз турында мәгълүмат алу белән бергә «Саф чишмә» газетасы язмаларын да укый ала.

Әйтергә кирәк, сайт белән кызыксынучылар саны көннән-көн арта бара. Укучылар язмалар белән танышып кына калмый, ә һәрберсенә карата үзенең фикерен белдерү мөмкинлегенә дә ия. Татар тормышындагы проблемаларны халык белән уртага салып сөйләшү мөмкинлеге дә шушы сайт аркылы алып барыла.

Татар депутатлары бүгенге көндә хакимиятнең төрле тармакларында сайланып эшли. Соңгы ун ел эчендә башкарылган иң зур казаныш — татар активистлары һәм татар депутатлары хакимият органнарының игътибарын татар милли мәсьәләләренә юнәлтә алдылар.

Әмма күп кенә проблемаларны чишүдә эш хакимияттән түгел, ә бәлки, ни кызганыч, татарларның үзеннән тора.

Безнең өлкәдә яшәүче татарларның милли тормышында өч төп проблема бар. Беренчесе — милли мәгариф проблемасы. Шәһәрләрдә этномәдәни уку йортлары, мәктәпләр юк, авылларда татар теле дәресләрен укыту елдан-ел кими бара. Бүгенге көндә нибары 15 татар авылы мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты фән буларак укытыла. «Мәгариф турында»гы Федераль канунның 6 нчы маддәсе гамәлдә декларатив булып кала, бөтенләй диярлек үтәлми. Иң төп сәбәп — ата-аналарның балаларны туган телдә укытырга теләмәве. Бүгенге сабыйларның әти-әниләре үзләре дә инде күптән «телсез» калып, ана телен белми үскән. Балага ана телен өйрәтү өчен, ана телле мохит кирәк. Моның өчен милли яисә этномәдәни балалар бакчаларын ачу зарур. Эш балаларга гына кагылмый.

Икенче мәсьәлә — ярдәмгә мохтаҗ, караучысыз калган мөселман ветераннарга картлар йорты булдыру. Хәләл ризык белән туклану, дини йолаларны үтәү олы яшьтәге мөселманнар өчен бик әһәмиятле, аларга кирәкле шартлар тудыру бик мөһим.

Өченче мәсьәлә дип милли массакүләм мәгълүмат чаралары хөкүмәт тарафыннан берничди яклау тапмауны атасак та, ялгыш булмас. Россиянең бер-ике төбәгендә генә татар газеталары яки тапшырулары җирле хакимият тарафыннан финанслана. Ә күпчелек төбәкләрдә, шул исәптән Свердловск өлкәсендә, бу чыгымнар әлегә хөкүмәт кесәсенә салынмаган. Ул гына да түгел, 2011 елның декабреннән башлап Өлкә телевидениесе каналында ун елга якын чыгып килгән «Минем илем» исемле атналык телевизион тапшыру, финанслау җитмәү аркасында, эшчәнлеген туктатты.

2012 елның май аенда «Урал татарлары» конгрессының II съезды узды. Урал татарларының милли үсеше буенча бик мөһим мәсьәләләр күтәрелгән бу чарада Губернатор хакимиятеннән югары дәрәҗәле чиновниклар катнашты һәм бүгенге көндә алар белән съезд карарларын үтәү буенча җитди хезмәттәшлек бара.

Әмма иң зур, глобаль темага кагылмыйча үтеп булмый.

Күптән түгел 2010 елда булып узган җанисәп нәтиҗәләре халыкка мәгълүм булды. Саннар сөендерми. Свердловск өлкәсе буенча тулаем алганда, сан ягыннан икенче урынны саклап калганбыз-калуын. Тик 168143

кешедән (2002 ел күрсәткечләре) 143803 кешегә калганбыз. 24340 кешегә кимегәнбез!

Тагын бер уйланырга мәҗбүр итәрлек факт: Свердловск өлкәсенең кайбер төбәкләрендә татарлар сан ягыннан икенче урында түгел. Әйтик, гомергә татар районы булып саналган Әртә районында руслардан кала икенче урында марилар, Волчанск, Карпинск, Краснотурьинск, Ивдель шәһәрләрендә — немецлар, Верх-нейвинскида — таҗиклар, Махневода — азәрбайҗаннар, «Свободный» ябык территориясендә —украиннар, Таборыда, Талицада, Туринскида — чувашлар, ә татарлар — өченче урында.

Соңгы җанисәп нәтиҗәләре борчулы уйларга сәбәп бирә. Әгәр дә бу тенденция шулай дәвам итсә, татарлар, хисаплашырлык көч булудан туктап, азсанлы милләт булып калагына шик юк.

Татарлар кая югала? Сабыйларның теле «әни» дип түгел, «мама» дип ачылганда, татар авылы мәктәбе коридорларында тәнәфес вакытында чабышып йөргән балаларның бер-берсе белән рус телендә аралашкан чагында, гомер-гомергә татарның бишеге булып саналган авылларның бетеп баруында, сылу татар кызларының башка милләт егетләренә пар булып, туачак сабыйлар, атасының исемен һәм фамилиясен алып, нәселен алыштырган вакытта, динсезлектә, әхлаксызлыкта, таркаулыкта, хөсетлектә югала.

Яшьләр — милләтнең киләчәге. Арабызда милләт өчен, рухи яңарыш өчен җан атып торган яшьләребез барлыгы куандыра, милләт бетеп бара дигән төшенке фикерләрне артка чигерергә мөмкинлек бирә. Юк, милләт бетмәскә тиеш, бары тик милли хәрәкәткә үзгәрергә вакыт җитте дип саныйм. Милли яңарышны башлап җибәргән өлкән яшьтәге аксакалларның тәҗрибәсенә, акыллы киңәшләренә таянып, телебезне, милли гореф-гадәтләребезне яшәеш кагыйдәсе иткән урта яшьтәгеләр белән бергә эшләүгә яшьләрне тартырга кирәк.

ИРЕК САБИРОВ

Чиләбе өлкәсе Татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Еманжелинск муниципаль районы башлыгы урынбасары

Иҗат һәм хезмәт активлыгы 1970-1990 елларга туры килгән буын өчен Чиләбе өлкәсендә милли хәрәкәт узган гасырның 80 нче еллары ахырында җәелеп китте. Әйе, без 1987 еллар тирәсендә «кайный» башладык, 1988 елны өлкә татар-башкорт мәдәният үзәге оештырып, үсмерләрчә дәрт белән ашкынып эшли башладык. Өлкә милли оешмасы эшләре артыннан район-калаларда да милли мәдәният оешмалары үсеп чыга башлады. 1990 елны татар телендә «Дуслык» газетасы чыгара башладык, өлкә радиосында атналык татарча тапшыруларыбыз да барлыкка килде, аннары, Салисә Гәрәеваны Казанга озаткач, Сания Шевченко «Чишмә», «Иман» исеме белән телевизион тапшырулар алып бара башлады.

Без 1990 елларның икенче яртысыннан сүрелә башладык. Газетабызны хакимият тарафыннан финанслау туктатылды (хәер, үзебезнең «тешебез» дә җитмәгәндер дип уйлыйм), телевидение, радионың да үз мәнфәгатьләре безнең тапшыруларны

әкренләп кысрыклап бетерде. Сабантуйларын да юк-бар акчага, ә нигездә фидакарьләребезнең хирыслыгына таянып кына үткәрә башладык. Барыбер бөтен төбәкләрдә милли кануннарны җиренә җиткереп үтәп, ел саен уздырып бардык, хәтта өлкә балалар Сабан туен да оештыра идек.

Яңарыш дулкынында чайкалып, «Телебез!» — «Сәнгатебез!» — «Милләтебез!» — дип җилкенеп йөргәннәребезнең кайберләре, «учагында утыны бетеп»ме, милли хәрәкәттән читләште, кайберәүләр бу эшебездән коммерция мөмкинлеге эзләп, тапмагач, бизнес сазлыгында юкка чыкты. Ниндидер яңа көч, яңа күтәрелеш кирәк иде. 1998 елның язында өлкәбезнең бөтен төбәкләреннән татар делегатларын җыеп, Чиләбе опера-балет театрында губернатор катнашында Өлкә Татар конгрессы оештырдык. Оешма җитәкчелеге башына татарлардан зур чиновниклар куелды. Бераз тернәкләнеп киткәндәй булдык.

Юк, 90 нчы елларда да, «нуленче» елларда да төшенкелеккә бирелеп, тынып-тукталып калганыбыз булмады, билгеле. Милли массакүләм гаммәви чараларның бер үзәге — Чиләбе милли китапханәсендә, аеруча анда мөдир булып Әлфира Усманова эшләгәндә, шаулап торды. Монда без Әхмәт Рафиков, Ришат Садыйков, Нурлыхак Фәйзуллин, Венера Нуретдинова, Айбулат Нурисламов һ.б. каләм ияләре белән Акмулла исемендәге әдәби берләшмәбез утырышларына җыела идек. Минем үземнең дә байтак әдәби кичәләрем шушында узды. Җырчыларыбыз Марат Канафин, Наилә Әделшина, Нәзифә Хәбибуллина, Җәүһәрия Нәфыйкова, Хәтим Мөхәррәмов, Дамир Сафиннар «ЧТЗ театры» мәдәният сарае сәхнәсендә туктаусыз «сайрап» яши, үзләрен өлкәнең бүтән төбәкләренә дә чакырып торалар. Урал тудырып үстергән композиторларыбыз Нил Минәҗев, Рафаил Бакиров, Әлфия Кәримова һәм Равил Газизов җырлары аларның репертуарларында алгы рәттә.

Чиләбедә дә, Магнитка, Златоуст, Троицк, Миас, Копейск, Еманже-

линск һ.б. төбәкләрдә татар җырлары, бәйрәмнәре, күргәзмәләре һәм, билгеле, сабантуйларының тынып торганы булмады. Тик шулай да 2008-2009 елларда бергә җыелган мизгелләрдә эшебезне ничектер үзгәртеп кору кирәклеген аңлап, борчылып сөйләшә башладык.

2009 елның ноябрендә, Конгресснең өченче съездын җыеп, өлкәнең бөтен почмакларыннан килгән биш йөз милләттәшебез белән киңәшләштек тә Конгресс Башкарма комитетының дилбегәсен Уралдагы «Классика» аптекалар челтәренең генераль директоры Лена ханым Колесниковага тапшырдык. Шуннан соң бу өч ел эчендә күп кенә үзгәрешләр булды. Әүвәл Чиләбе театрларының берсендә Муса Җәлилгә багышланган махсус спектакль куеп, Казаннан Гәзинур Морат, Рамил Миндияр, Илдус Әхмәтҗановларны чакырып бәйрәм үткәрдек. Кемгә ничек, ә безнең татарларга бу моңарчы күрелмәгән тамаша булды. 2011 елда Җәлил көннәрен киңәйттек: бөтен өлкә мәктәпләрендә шагыйрьнең әсәрләрен уку конкурслары уздырдык. Аның финалын өлкә үзәгенең бер гимназиясендә үткәреп йомгакладык. Ә менә быел бу чараны тагын да югары күтәрдек: «Җәлил укулары» өлкә Мәгариф министрлыгы тарафыннан мәктәп (рус мәктәпләренең дә) программасына кертелде, масштабы да, сыйфаты да күптапкыр киңәйде.

Соңгы елларда татар телен өйрәнергә теләүчеләр саны кинәт артып китте. Уй, Нязепетровски, Коншак районнарында, Копейск каласында факультатив дәресләр һәм түгәрәкләр эшли башлады... Татар теле укытучылары җитми, былтыр Чиләбе педагогия университетында татар теле мөгаллимнәре хәзерли торган төркем ачып җибәрдек. Аның башында торучы яшь галим Марат Әхәтов, Аллаһ боерса, тиздән кандидатлык диссертациясен дә яклаячак.

2010 елдан өлкәбездә сабантуйлары үткәрелә торган урыннар саны бермә-бер артты. Нәкъ менә бу елны өлкә Сабан туен Чиләбенең үзендә түгел, Коншак районы болыннарының берсендә — авыл җирендә үткәрдек. Губернаторыбызның шунда сәхнәдән: «Исәнмесез!» — дип татарчалап сәламләвен халык алкышка күмде. Шуннан бирле татарлар аз яшәгән рус авылларында да шаулатып, хакимият башлыгы инициативасы буенча татар бәйрәмнәрен үткәрә башладылар.

2012 елны «Татар кызы: матурлык һәм сәләт» бәйгесен үткәрдек. Безнең төп максатыбыз — татар кызларының матурлыгы, акыллылыгы, зирәклеге, булдыклылыгы аркылы, гомумән, татар халкының, милләтебезнең иң күркәм сыйфатларын күрсәтү. Кызларыбыз тормышка бик тә җитди карашлы булуларын, әхлаклы, вөҗданлы икәнлекләрен күрсәттеләр.

Татар милли яңарыш хәрәкәтенең шушы яңа чорында, ягъни соңгы өч ел эчендә, Чиләбе өлкәсе татарларының руслашканнары арасында «мин татар бит», дип туган теле, милләте турында уйланып, үз тамырларына кайтырга теләүчеләр барлыкка килде. Хәтта татар исемен йөртеп тә, элек үзен милли тормыштан ерак тоткан татар эшмәкәрләре безнең эшкә финанс ягыннан шактый ук өлеш кертә башлады.

Бүген «Хәзинә» исемле күпбитле һәм төсле айлык газетабыз чыга. Өлкә телевидениесендә атна саен чыга торган егерме минутлык тапшыруыбызның да исеме «Хәзинә». Казанлылар безнең тормыш белән «congresstatar74.ru» һәм «tatarochka74.ru» сайтларында таныша ала.

Ләкин безнең миллионлаган чыгымнарның төп иганәчесе — Лена ханым үзе. Төгәлрәк әйтсәк — гаи-

ләсе. Аның ире, чыгышы белән рус булса да, Татар конгрессы тормышы белән кайный. Сабантуйларында губернаторыбыз янында чиккән чапан һәм затлы түбәтәй киеп, елмаеп тора торган кешене күрсәгез, ул Олег Колесников булыр. Хатыны кебек үк тирән акыллы, олы җанлы кеше.

Киләсе елда икетомлы зур проект — «Чиләбе өлкәсе татарлары энциклопедиясе» дөнья күрәчәк. Бу хезмәтне хәзерләгәндә, танылган әдипләрнең, сәнгать әһелләре, галимнәр, гомумән, зур шәхесләрнең язмышы Чиләбе ягы белән бәйле булуы аңлашылды!

Менә шулай, өлкә татарлары күтәрелеш чоры кичерә. Әмма өч ел — татар тарихында бик аз вакыт. Төп бурычыбыз — ирешелгән уңышларны саклап, ныгытып, ишәйтеп яшәү һәм үзебезгә алмашка яшьләребезне хәзерләү!

ВӘГЫЙЗ ФӘЙЗУЛЛИН
Красноярск крае Төбәк «Яр» татар милли-мәдәни автономиясе советы рәисе

Красноярск краенда сан буенча татарлар өченче урынны алып тора. Бүген крайда 1925 елда теркәлгән 72 татар авылның 29ы гына сакланган. Шулай ук татарлар крайдагы эре шәһәрләрдә яшиләр. Авылларга халык, нигездә, XX йөз башында хәзерге Татарстан Республикасының Саба, Мамадыш, Актаныш районнарыннан күченгәннәр.

Крайда татарларның «Яр» миллимәдәни һәм «Кызыл яр» яшьләр оешмалары теркәлгән.

Соңгы елларда татарлар тарафыннан 7 мәчет төзелде. 1998 елда Норильск шәһәрендә дөньяның иң төньягында урнашкан мәчет ачылды. 2011 елда Казачинский һәм Пировский район үзәкләрендә мәчетләр булдырылды. Шулай ук соңгы елларда ике йөзьеллык мәчет төзекләндерелде. Шулар арасында Казанка авылындагы икекатлы агач мәчет тә бар. Ә Енисейск шәһәрендәге иң борынгы таш мәчет шәһәрнең 400 еллык юбилеен үткәргәндә төзекләндереләчәк объектлар исемлегенә кертелде.

Автономиянең зур уңышы — милли бәйрәмебез Сабантуйның чикләрен киңәйтү. Бүген Сабантуй бәйрәме татар авылларында гына түгел, ә зур шәһәрләрдә дә үткәрелә. Безнең тырышлык белән 70 ел тынып торган Сабан туе Красноярск шәһәренә 20 ел элек, Енисейск каласына — 7 ел, Шарипово шәһәренә 2 ел элек кире кайтты. Әгәр дә 90 нчы елларда Сабан туе 8-9 авылда гына үткәрелсә, хәзер ул 23 торак пунктта һәм 4 шәһәрдә оештырыла. Крайда иң зур сабантуйлар Красноярск һәм Лесосибирск шәһәрләрендә үткәрелә. Узган ел Красноярск краендагы сабантуйлары турында фотоальбом чыгардык.

2010 елда автономия инициативасы белән керәшен татарларының Питрау бәйрәмен үткәрдек.

Соңгы дүрт елда автономия крайдагы татар авылларының 100 еллыкларын үткәрүне оештыра башлады. 18 авылның 100 еллык юбилеен үткәрдек инде. Бәйрәм кысаларында ике авылда Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл төзелде, ә икесендә төзекләндерелде.

Солоухо, Долгово, Куренная Ошма авыллары тарихына багышланган китаплар басылып чыкты.

Автономия тырышлыгы белән 1997 елда — Татарстан Республикасы һәм Красноярск крае, 2002 елда Казан һәм

Красноярск шәһәрләре, Красноярск крае админстрациясе һәм «КамАЗ» арасында икътисад, мәдәният һәм фән өлкәләрендә хезмәттәшлек итү турында Шартнамәгә һәм килешүгә кул куелды. Шулай ук Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән Край фәнни китапханәсендә татар әдәбияты бүлеге ачылды, ТР ярдәме белән авыл китапханәләре меңнән артык данә китап белән тулыланды. Крайның татар яшьләре оешмасы автономия белән берлектә квартал саен яшьләр өчен Татар-пати, ә өлкән буын өчен Кич утыру мәҗлесләре оештыра.

Шәһәрләрдә һәм авылларда татар иҗат төркемнәре уңышлы гына эшләп килә. Краснояркк шәһәренең «Йолдыз» вокал-хореографик коллективы край губернаторы Указы нигезендә «Халык коллективы» исемен алды. Төркемгә йөрүчеләрнең саны 40 кешедән артып китә. Алар үзләренең иҗатлары белән Красноярк шәһәре халкын гына түгел, ә, гастрольләр оештырып, крайдагы авыллар халкын да куандыра. Әмма авылларның край үзәгеннән читтә булып (татарлар күпләп яшәгән районнар Красноярск каласыннан 200-250 чакырым төньяктарак), автономиянең үз транспорты булмау бу эшне киңрәк җәелдерергә мөмкинлек бирми.

Кызганыч, крайда татар телен укыту бары тик бер мәктәптә генә калды. Биш мәктәптә татар телен укыту бары тик түгәрәк формасында гына. Шулай ук җиде авылда төбәк музее эшләп килә.

2010-2011 елларда Карасноярскта һәм авылларда автономия татар киносы атналыгын үткәрде.

Шунысын да әйтергә кирәк: край һәм җирле хакимият ярдәменнән башка югары санаганнарны гамәлгә ашырып булмас иде. Һәрбер чара автономия тарафыннан гына түгел, ә край бюджетыннан да финанслана. Шулай ук хакимияттә эшләүче татарларның да ярдәме зур. Бүгенге көндә ике шәһәр (Красноярск, Ачинск) һәм дүрт районның (Северо-Енисейск, Ужур, Пировский, Боготольский) башлыклары — татар.

ӘЛФИЯ САФУГАНОВА
Приморье краеның «Туган ил» татар һәм башкорт җәмгыяте оешмасының «Владивосток» бүлекчәсе җитәкчесе

Приморье краенда 1992 елдан «Туган ил» татар һәм башкорт җәмгыяте оешмасы эшләп килә. Аның беренче рәисе Җәүдәт Гыйззәтуллин иде. Шул вакыт эчендә оешманың рәисләре вазифасында Ринат Якуб, Марс Миңнәхмәтов, Любовь Сермягина, Урал Сафуганов, Риф Харисов булды. 2009 елның апрель аеннан — Рамил Килмөхәммәтов. Оешма составына Находкадагы «Туган тел» (рәисе Нуретдин Садретдинов), Артём шәһәренең «Туган дин» (рәисе Гаястин Ситдыйков), Партизанск шәһәренең «Туган як» (рәисе Людмила Котова), Арсеньев (рәисе Хәким Дукин), Владивосток (җитәкчесе Әлфия Сафуганова), Уссурийск (рәисе Әхтәм Хасбиуллин) шәһәрләре бүлекчәләре керә.

Оешма край һәм Владивосток, Находка, Артём, Уссурийск шәһәрләре көненә багышланган бәйрәмнәрдә татар һәм башкорт халык ашларын әзерләп, төрле чараларда чыгышлар ясый. Һәр елның июнь аенда халкыбызның күркәм милли Сабан-

туй бәйрәмен уздыра. Бөтенроссия күләмендә уза торган Федераль Сабантуй 2012 елның 30 июнендә Владивосток шәһәрендә үткәрелде. Бу зур бәйрәм Татарстан Республикасы белән берлектә оештырылды. «Туган ил» оешмасы да зур өлеш кертте. Сабантуй тантанасы Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Приморье крае губернаторы Владимир Миклушевский катнашында узды. Шул ук көнне Владивостокта төзеләчәк мәчет нигезенә беренче таш салу тантанасы да булды.

Соңгы биш ел эчендә оешма бик зур үзгәрешләр кичерә. Бу көнгәчә Находка, Артём, Арсеньев шәһәрләре оешмалары рәсми рәвештә теркәлгән булса, 2011 елның ноябреннән шул исәпкә Партизанск шәһәре дә кушылды. Владивосток һәм Уссурийск шәһәрләре дә рәсми рәвештә теркәлү алдында. «Туган ил» оешмасы Приморье краеның Эчке сәясәт эшләре идарәсе белән тыгыз мөнәсәбәттә тора. 2003 елны Приморье халыклары Ассамблеясы ачылды.

2010 елда Ерак Көнчыгышта Урал Сафуганов тарафыннан оештырылып, Д.Гыйззәтуллин исемендәге беренче үзешчән татар һәм башкорт театры ачылды. 2011 елда театр, Г.Исхакыйның «Җан Баевич»ын сәхнәләштереп, Владивосток, Артём, Уссурийск, Находка, Хабаровск шәһәрләрендә чыгышлар ясады. Туган якларыннан еракта яшәүче якташларыбыз өчен бу истә калырлык зур вакыйга булды. Спектакль телне, гореф-гадәтләрне, халкыбызны саклап калуга багышланган чараларның берсе буларак бик уңай тәэсир итте. Театрда уйнаучы яшь буын егет һәм кызлары, телне өйрәнеп, татарча сөйләшә башлады. Безнең театрыбыз — Приморье краенда, корея халыклары театрыннан кала, икенче үзешчән халык театры.

2012 елның февраль аенда Владивостокта беренче тапкыр яшьләр кичәсе уздырылды. Кичәгә 18дән алып 35 яшькәчә иллеләп кеше җыелды. Аның оештыручылары Әлфия һәм Урал Сафугановлар булды.

Оешмабызда концерт төркемнәре дә оештырдык. Аларның эшли башлавы 1992 елда рәсми рәвештә оештырылып эшләп киткән, 1996-1998 елларда беренче Приморье халыклары фестивальләрендә катнашкан төркем белән бәйле. 2000 елларда икенче сулыш алып, Татарстан белән тыгыз элемтәгә керү, татар сәнгать осталарын каршы алу, аларның уңышлы чыгыш ясауларын тәэмин итү дә нәтиҗәләр бирде.

Дини бәйрәмнәребезне дә онытмыйбыз. Приморье краенда — Находка шәһәрендә бердәнбер мәчетебез бар, ә Владивосток һәм Артём шәһәрләрендә намаз уку йортлары эшли.

Әлбәттә, барысы да без теләгәнчә генә шома бармый. Туган якларыбыздан шактый ерак булуыбыз, телне белүчеләр санының азлыгы, оештыру эшләре барышында үз эшенең чын осталары, белгечләр аз булу, әти-әниләрнең, әби-бабаларның туган телебезне балаларына тиешенчә өйрәтмәве зур кыенлыклар тудыра. Алдагы көннәрдә бу хәлләрнең яхшы якка үзгәрүенә өмет итәбез. Ерак тарихи ватаныбызның хәзерге көннәрдә ирешкән уңышлары шушы юнәлештә эш алып барырга безгә тагын да көч өсти. «ТНВ-планета» каналыннан без милли тормышыбыз яңалыклары белән һәрвакыт танышып барабыз. Үзебездә уздырылган чаралар турында да мәгълүматлар җибәреп торырга тырышабыз. ■

***Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.*

«МИЛЛИЛЕК – БЕЗНЕҢ ТӨП ӨСТЕНЛЕГЕБЕЗ»

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРЕЛӘ ТОРГАН АКТАНЫШ «СӘЛӘТ» ГИМНАЗИЯСЕ БИК КҮП ТӨБӘКЛӘРДӘН УКЫРГА КИЛГӘН МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗНЕ БЕРЛӘШТЕРӘ. ОКТЯБРЬ АЕНДА БИРЕГӘ СӘЯХӘТЕБЕЗ ВАКЫТЫНДА, МИЛЛИ МӘГАРИФ ҮЗӘГЕНЕҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ БЕЛӘН ЯКЫННАН ТАНЫШУ МАКСАТЫННАН, АКТАНЫШ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ ВАЗИФАЛАРЫН БАШКАРУЧЫ **ФАИЛ МИСБАХ УЛЫ КАМАЕВ** БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ КОРДЫК.

– Татар халкының зыялы катламын тәрбияләү үзәге – киләчәк мәктәбе нәкъ менә Актаныш районында ачылды. Актаныш милли әдәбиятыбызга, сәнгатебезгә бик күп күренекле шәхесләр бирсә дә һәм бүгенге көндә барлык юнәлешләрдә республикабызның иң алдынгы районы булса да, ул бит әле, ни әйтсәң дә, үзәктән читтә... Бу олуг максатка ирешү барышында кыенлыклар да булгандыр? Милли элита, татар телен, гореф-гадәтләрен, йолаларын камил белгән яшьләр тәрбияләү, мондый мәктәпләрдә эшләү өчен белгечләр җитәрлекме?

— Бу зур җаваплы эшкә алыну буш урында гына барлыкка килмәде, әлбәттә. Татар районы саналсак та, бездә дә мәдәни, рәсми чаралар, җыелышларны рус телендә уздыра башлау модасы кергән иде. Бүгенге ТР Мәгариф һәм фән министры, ул вакытта әле Актаныш районы башлыгы Энгель Фәттахов тәкъдиме белән янә үз асылыбызга кайту юнәлешендә хәрәкәт башланды. Нәкъ шул вакытларда инде укучылар, яшьләр арасында якташ шагыйрьләребез Нур Баян, Гамил Афзал исемендәге әдәби бәйгеләр оештырыла башлады. Чын татар концерт-спектакльләре белән үзебезнең район сәнгатькәрләре Актанышта гына түгел, республика күләмендә уздырылган чараларда лаеклы урыннар яуладылар. 75 яшен тутырган Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбленнән тыш, бердәнбер дәүләт ансамбле статусы быел Актанышның «Агыйдел» җыр һәм бию ансамбленә бирелде. Әдәбият, сәнгать әһелләре белән даими очрашулар, кичәләр оештырылып тора. Моның белән нәрсә әйтергә телим: районыбызда мәдәният, әдәбият, тел, мәгарифне үстерү мәсьәләләренә игътибар бик зур. Шуңа күрә татар зыялыларын, безнең татар халкының затлы катламын тәшкил итәрдәй яшь буынны тәрбияли торган махсус уку йорты булдыру ихтыяҗы да коры җирлектә барлыкка килмәде. Бу тәкъдимне дә Энгель Нәвап улы ясады. Аның җиңел кулы белән әлеге катлаулы эшкә тотындык, нәтиҗәсе — күз алдыгызда. Әле шушы көннәрдә генә «Татарга тылмач кирәк» дип аталган республика олимпиадасында безнең Актаныш гуманитар гимназиясе укучысы Айдар Шәйхин Гран-при, Алёна Валькова дигән кызыбыз III

урынны яуладылар, шул ук А.Шәйхин татар теле һәм әдәбиятыннан халыкара олимпиадада I урынга лаек булды (фәнни җитәкчеләре — Л.Г.Әминова). Димәк, гимназия татлы җимешләрен бирә башлады.

Гимназияне ачуда, әлбәттә, кыенлыклар бихисап булды — республикабызда дәүләт учреждениесе саналган бер генә мәктәп тә калмаган. Уку йортының юнәлеше, гуманитар гимназия нинди булырга тиеш дигән тәгаен генә бер үрнәк тә булмаган килеш документлар әзерләү, Устав эшләү — һәммәсе сукыр капшануга тиң иде. Безнең бу уку йорты Татарстандагы беренче гуманитар гимназия, беренче карлыгач булды бит.

Үзәктән читтә урнашуның өстенлекле яклары да, үз кыенлыклары да бар. Россиянең башка төбәкләрендә яшәүчеләр безгә балаларын алып килгәндә, нәкъ менә татар мохите, чиста татар районы булган өчен сезгә килдек, дигән фикерне әйтәләр. Миллилек — безнең төп һәм иң зур өстенлегебез.

Кыенлыкларга килсәк, үзәктән ерак булу белгечләр белән хезмәт-

тәшлек итүдә чагыла. Бу юнәлештә ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы белән кулга-кул тотынып эшлибез, көчле, сыналган педагогларны җәлеп итәргә тырышабыз. Шулай ук әле студент елларында ук үзен танытырга өлгергән, көчле, булдыклы яшь мөгаллимнәр өчен дә бездә тулы куәткә бар сәләтләрен эшкә җигәргә, хезмәт эшчәнлеген башларга мөмкинлек зур. Киләчәктә гимназиядә кайбер фәннәрне инглиз телендә укытырга ниятлибез. Татар шагыйрь-язучылары, ТР Дәүләт Советы депутатлары, сәясәтчеләр — гимназиябезнең даими кунаклары. Үзәктән читтә булсак та, без татар казанының уртасында кай-

нап яшибез. Төрле фән галимнәре белән даими хезмәттәшлекнең яңа юлларын, яңа алымнар эзлибез.

– Әлеге замана мәктәбендә бары тик татар балалары гына белем алалар? Укучылар кайсы төбәкләрдән тупланды?

— Әйе, гимназиядә җитди конкурс нигезендә сайлап алынган татар балалары гына белем ала. Безгә килгәндә, иң мөһиме — балаларның телебез, тарихыбыз, мәдәниятебезне өйрәнүгә теләге, омтылышы булырга тиеш. Гимназиядә узган бер ел эчендә укучылар саф татар телендә сөйләшергә генә өйрәнеп калмыйча, татар халкының мәдәнияте, тарихы, гореф-гадәтләре белән якыннан танышалар, күңелләрендә милләтебезгә карата мәхәббәт, хөрмәт, горурлык хисләре тәрбияләнә. Әйтик, узган ел гимназиягә ерак Таҗикстаннан килгән кызның инде гаиләсе дә бирегә күченергә тели, Красноярск, Оренбургтан килгән балалар саф татарча аралаша. Укучылар гимназиягә, әлбәттә, иң элек үзебезнең Актаныш районыннан, Татарстаннан туплан-ды. Чит төбәкләрдән алдарак әйтеп үткән Таҗикстанның Торсынзадә шәһәреннән, Оренбург, Красноярск, Магнитогорск, Уфа, Башкортстан Республикасының Дүртөйле районы кыз-егетләре бар.

– Татар телендә белем алу туктап барган бер заманда бу укучылар бар фәннәрне дә ана телебездә үзләштерәме? Мәктәпне тәмамлагач, алар кайсы юнәлештә, нинди югары уку йортларында белем алу мөмкинлегенә ия булачак?

— Безнең максатыбыз — гимназиядә белем алган бала татар, рус, инглиз телләрен камил белергә тиеш. Гимназия гуманитар юнәлештә белем бирә, ягъни төп басым тел гыйлеме белән бәйле фәннәргә, бигрәк тә татар

теле, әдәбиятына, тарих, җәмгыять белеме, журналистикага ясала. Гимназия укучылары Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм сәнгать кече институты студентлары булып санала. Гимназияне тәмамлагач, алар әлеге һәм үзләре теләгән башка уку йортларына да керә алалар. Күбесе үзенең киләчәген татар телен, милләтен саклап калуда халкына хезмәттә күрә, тарихчы, телче, журналист булырга, мәдәният-сәнгать өлкәсендә эшләргә тели.

– Сезнең тәҗрибәгә һәм проектка нигезләнеп, республикабызның башка төбәкләрендә дә шундый мәктәпләр ачу мөмкинме? Кызыксынучы районнар һәм тәҗрибәгезне өйрәнүчеләр бармы?

— Әлбәттә, башка төбәкләрдә дә мондый уку йортлары ачарга мөмкин һәм алар ачыла да бит инде. Әйтик, Казанда быел эшчәнлеген башлап җибәргән егетләр IT-лицее бар, Яр Чаллыда лицей-интернат ачарга җыеналар. Безнең гимназиябез бик яшь — быел ул икенче елын гына эшли әле. Шуңа карамастан, тәҗрибәбезне өйрәнү максатыннан мөрәҗәгать итүчеләр дә бар.

– Республикабызда милли мәгарифнең торышы төрле чорларда төрлечә булды. Узган гасыр ахырында көчәеп киткән үсеш бүген тагын сүлпәнәйде кебек. Киләчәк мәктәбен оештыручыларның берсе буларак, алдагы көннәргәниләр фаразлый аласыз?

— Әгәр республикабызның башка районнарында да мондый уку йортлары ачарга ниятлиләр икән, ягъни татар телен, мәдәниятен, мәгарифен, гомумән, татар халкының үткәнен яхшы белеп, киләчәген төзергә теләүче һәм шул изге максатка әзер яшьләр хәзерләргә телиләр икән — милли мәгарифебезнең дә киләчәге өметле, якты булыр. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министры итеп нәкъ шушы хәрәкәтне башлап йөрүче, гимназиянең зарурлыгын аңлап, исбатлый һәм дәүләт җитәкчеләрен дә шуңа ышандыра алган шәхес — татарлыгы белән горурланып, милләтенең киләчәге өчен җан атып яшәүче Энгель Фәттахов куелуы да әлеге ышанычны ныгыта.

*Әңгәмәдәш — **Рамил Ханнанов***

САРАТОВ ТАТАР МИЛЛИ ГИМНАЗИЯСЕ

КАМИЛ ӘБЛӘЗЕВ,
Саратов өлкәсе Төбәк татар милли-мәдәни автономиясе советы рәисе, «Нарат-К» ҖЧҖ президенты, Татарстан Республикасының Саратов өлкәсендәге сәүдә-икътисад вәкиллеге рәисе

ТАТАР МИЛЛИ ГИМНАЗИЯСЕ – САРАТОВ ШӘҺӘРЕ ТАТАРЛАРЫ ҖӘМГЫЯТЕ ИНИЦИАТИВАСЫ ҺӘМ ӨЛКӘ МӘГАРИФ МИНИСТРЛЫГЫ БЕЛӘН ОЕШТЫРЫЛГАН ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ. ИДЕЛ БУЕНДА ТАРИХИ ШАРТЛАРДА БАРЛЫККА КИЛГӘН АССИМИЛЯЦИЯ ҺӘМ ИНТЕГРАЦИЯДӘН ГИМНАЗИЯ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ТЕЛЕН, МӘДӘНИЯТЕН САКЛАУ ҺӘМ ТОРГЫЗУНЫ МАКСАТ ИТЕП, УКУЧЫЛАРГА ТИЕШЛЕ ТӘРБИЯ БИРЕРГӘ, ТУГАН ТЕЛГӘ МӘХӘББӘТ ТӘРБИЯЛӘРГӘ ОМТЫЛА.

Татар гимназиясенең бурычы булып инновацион эшчәнлек алып барырга сәләтле яхшы әхлаклы, җаваплы, инициативалы, компетентлы Россия гражданинын тәрбияләү һәм үстерү; илебез чәчәк атсын һәм татар халкының якты киләчәге өчен хезмәт итәчәк татар милли элитасын тәрбияләү тора.

Шәхеснең рухи-әхлакый потенциалын формалаштыру максатыннан, гимназиядә халкыбызның традицион халык кыйммәтләренә нигезләнгән тәрбия системасы булдырылган. Татар милли гимназиясендә укыту процессында катнашучы администрация вәкилләре, укытучылар, укучылар һәм ата-аналарны гимназиягә «икенче өйгә» караган кебек сакчыл мөнәсәбәт берләштерә. Укучыларга тәрбия бирү буенча уздырылган өлкә конкурсында гимназиябезнең коллективы икенче урынны алды. Уку-укыту методикаларын яңарту юнәлешендә дә уңышлы эш алып барыла, мәгълүматикоммуникация технологияләрен куллану да моңа ярдәм итә. Гимназия Президентның милли мәгариф про-

граммасы юнәлешендә 3 ел рәттән (2006, 2007, 2008 елларда) мәктәпләрдә инновацион технологияләр куллану буенча өлкә конкурсында җиңү яулады. Җиңгән өчен бирелгән акчалата грантларның күп өлеше информатизацияләүнең матди базасын үстерүгә тотылды. Бүген һәр кабинетта проектор һәм интерактив такта белән компьютер куелган, һәр сыйныфтан интернетка чыгу мөмкинлеге тудырылган. Болар барысы да гимназиянең уку-укыту, тәрбия, идарә итү процессына информацион технологияләрне нәтиҗәле кулланырга булышлык итә.

Татар милли гимназиясе Саратов өлкәсе татар мәктәпләре өчен милли мәгарифне үстерү буенча уку йорты вазифасын үти, директорларга һәм укытучыларга методик ярдәм күрсәтә, семинарлар һәм бәйрәмнәр үткәрә. Һәр елны гимназия базасында татар теле һәм әдәбиятыннан өлкә олимпиадалары, «Идел йолдызчыклары» милли мәдәниятләр фестивале үткәрелә. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты гимназиябезнең оешуы һәм үсеш этаплары белән якыннан таныш. Ул укытучылар коллективының тәҗрибәсен башка татар мәктәбендә куллану, җәелдерү тәкъдиме белән чыкты. Хәзер бу төрдәге мәктәпләрне ачу, аякка бастыру тәҗрибәсен өйрәнер өчен өлкә районнарыннан һәм Россиянең төрле төбәкләреннән киләләр.

Гимназиядә «Чагылу» фәнни-практик җәмгыяте уңышлы эшләп килә. Җәмгыять әгъзалары төрле чыгышлар ясап, конференцияләрдә үзләренең тикшеренү эшләре нәтиҗәләре белән таныштыралар. 1999 елдан башлап, гимназиядә Саратов өлкәсе мәгариф министрлыгы һәм Саратов Төбәк татар милли-мәдәни автономиясе ярдәме белән һәр елны «Идел буе халыклары: тарихы, мәгарифе, мәдәнияте» исемле фәнни-практик конференция үткәрелә. Конференция кысаларын-

да кызыклы темалар тәкъдим ителә. Чөнки һәр халыкның нәрсәсе белән булса да горурланырлык әйбере бар. Ел саен уздырыла торган конференция материалларын туплап, 10 мәкаләләр җыентыгы басылды.

Инде берничә ел гимназия тулы көнле мәктәп режимында эшли. Көннең икенче яртысында түгәрәкләр һәм спорт секцияләре эшли, укучыларга татар, инглиз, һәм көнчыгыш (төрек, гарәп) телләрен камилләштерергә мөмкинлекләр тудырылган, балаларга өй эшен хәзерләгәндә методик ярдәм күрсәтелә. Бу инновацион мәгариф моделе берьюлы берничә проблеманы хәл итә: мәктәп балалары көн дәвамында, кичке сәгать 18.00 гә хәтле, тәҗрибәле тәрбиячеләр янында булалар, өй эше хәзерләгәндә ярдәм яки өстәмә аңлатулар сорап, педагогка мөрәҗәгать итә алалар. Балаларга тәкъдим ителгән берничә төрле түгәрәктән үзләренә ошаганын сайлап алалар. Тулы көнле мәктәптә шулай ук сәламәтлекне саклау программасы гамәлдә; балалар спорт белән шөгыльләнәләр, бассейнда йөзәләр, төрле спорт ярышларында катнашалар. 2008 елны гимназия «Тулы көнле мәктәп» региональ экспериментал мәйданчыгы статусын алды.

2008 елдан башлап, гимназиядә Идарә советы актив эшләп килә. 2011 елны Татар милли гимназиясе Идарә советы гомуми белем бирү учрежденияләре Идарә советларының өлкә конкурсында җиңү яулады. Гимназиянең сайты эшләп килә, 2010 елда шәһәр сайтлары конкурсында «Гомуми белем бирү учреждениесенең визиткасы» номинациясендә беренче урын яулады. Педагоглар гимназия эшчәнлеге турында сайтка даими рәвештә мәгълүмат урнаштырып торалар.

Саратовка ике регион арасында хезмәттәшлек итү буенча берничә килешүгә кул кую өчен килгән Татарстан Республикасының элекке Премьер-министры Фәрит Мөхәммәтшин сәфәре вакытында болай дип искәртте: «Татар милли гимназиясе Идел буе татарларының горурлыгы гына түгел, ә Саратов шәһәренең тарихи ядкәрләреннән берсе булып та санала. Мондый мәктәпләр белән халыкара дәрәҗәдә горурланырга мөмкин. Һәр республика шундый уку йортлары белән мактана алмый».

Алдынгы инновацион мәгариф учреждениясен булдыру җиңел түгел. Татар милли гимназиясе һәрдаим татар җәмәгатьчелеге ярдәмен һәм игътибарын тоеп тора. Татар милли гимназиясе үсешендә «Нарат-К» ЖЧЖнең роле бәяләп бетергесез. Автономия һәм «Нарат-К» ЖЧЖ 4 нче номерлы мәктәп бинасының авария хәлендәге буш блогына капиталь ремонт ясады.

«ГЭКСАР» электротехник заводы ЯАЖе генераль директоры Ганеев Эдуард Әнвәр улы гимназиянең өченче катын сипләү генә түгел, кабинетларны мәктәп җиһазы белән җиһазландырды.

Саратов Төбәк татар милли-мәдәни автономиясенең Башкарма комитеты рәисе Хәкимов Зөфәр Шәмсегали улы татар милли гимназиясенең Идарә советы белән җитәкчелек итә, талантлы укучыларга булыша, педагогик коллективны һөнәри бәйрәмнәре, Яңа ел, 8 март бәйрәмнәре белән котларга да онытмый.

Иганәчеләр, җәмәгать эшлеклеләре һәм башка милләт язмышына битараф булмаган шәхесләр ярдәме һәм укытучыларның, дирекциянең фидакарь хезмәте — Саратов татар гимназиясе уңышларының нигезен тәшкил итә. ■

А.Эшкинин фотосы

КЫРЫМЫМ – КАЗАНЫМ

ДИЛӘВӘР ОСМАНОВ

Кырымым — туган йортым!
Синдә халкым, бабаларым.
Синдә тамырым,
Чал тарихым, зиратларым.
Синнән еракта җырларым,
Тик сиңа илтә уйларым.

Сине сагынып, саргаеп,
Казан илендә җырладым
Тукай җырларын.
Шунда эчтем Идел суларын.
Шунда сөйдем Сәйдәш моңнарын,
Зәңгәр күзле татар кызларын.
Шунда таптым газиз дусларым,
Ләкин онытмадым
Кырым йолдызларын.

Кырымым, дисәм,
Көнләмә, Казаным!
Ике якта ике канатым сез,
Күктә, һавада.
Ике хәсрәтем, ике өметем
Бу дөньяда.
Берсе — газиз Ватаным,
Берсе — кардәш Казаным!

ТУКАЙ АВЫЛЫ МӘХӘЛЛӘСЕ ИҖТИМАГЫЙ КИҢӘШМӘСЕНЕҢ ЭШ ТӘҖРИБӘСЕННӘН

ӘГЪЗАМ ШАКИРОВ,
Чувашстан Республикасы Комсомол районы Җыены депутаты, Тукай авылы мәхәлләсе иҗтимагый киңәшмәсенең президиум әгъзасы, «ОРАН» ҖЧҖ директоры

Әссәламегаләйкем үә рәхмәтуллаһи үә бәрәкәтүһ. Чувашстан милли мәркәзебез Татарстанның күршесендә генә урнашкан. Республика җирлегендә 50дән артык татар мәхәлләсе, 46 мәчет эшләп килә. Чувашстан Диния нәзарәте 1994 елда барлыкка килде. Бездәге мәчет- мәхәлләләр Үзәк Диния нәзарәтенә карый.

Бүген татар җәмгыяте яңа бер чор кичерә. Мәчетләр төзү вакытлары узып бара, алар инде шактый аякка басты. Безнең фикеребезчә, бүгенге татар-мөселман тормышында ике мөһим мәсьәлә бар. Аның берсе — дини мәгарифне тулысынча аякка бастыру, көчле кадрлар әзерләү, икенчесе — мәхәллә системасын торгызу. Мәхәллә системасын торгызу юнәлешендә Чувашстанда башкарылган эшләр белән таныштырасым килә. Һәр авылның мәчете тирәсендә мәхәлләне торгы-

зу буенча эш алып барыла. Дөрес, төрле авылның уңышлары төрлечә. Әлеге эшкә күптән түгел генә алынган мәхәлләләребез дә, инде шактый алга киткән, уңышка ирешкән мәхәлләләр дә бар. Бу яктан Тукай авылы мәхәлләсе эшчәнлеге игътибарга лаек. Тукай авылы зурлыгы буенча Чувашстандагы Шыгырдан, Урмай салаларыннан кала, өченче урында тора. 500 хуҗалыкта ике меңгә якын кеше яши. Яшьләр авылда төпләнә, авыл үсә, зурая. Ел саен уртача 35-45 бала дөньяга килә (үлүчеләргә караганда, туучылар өч мәртәбә күбрәк). 300 балага белем бирә торган татар мәктәбе эшли.

Тукай авылында бер мәчет, бер мәдрәсә, ике хәләл ит эшкәртү цехы бар. Авылда рәсми рәвештә теркәлгән йөздән артык эшмәкәр яши, шуларның күпчелеге ит белән сәүдә итә.

Соңгы елларда татар матбугатында, телевидениедә Тукай авылы турында еш сөйләнә, үрнәк итеп куела. Моның сәбәбе — авылыбызның бүгенге яңарышы, күтәрелеше. Әлеге яңарыш сәбәпләре берничә. Билгеле булганча, татар милләтенең, татар авылының, татар гаиләсенең асылында иман һәм дин ята. Шушы хакыйкатьне бөтен тирәнлеге белән аңлау Тукайда яңарышка юл ачты. 2000 нче елларда милләттәшләребез дәүләттән генә көтеп ятып булмый, үзебезгә тырышырга кирәк дигән нәтиҗәгә килде һәм үз хисабына авылларны тәртипкә китерә башлады. Авылдашлар тырышлыгы белән авылга газ керде, тырышып эшли башладык. 2008 елда баш мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин мәчет каршында мәхәлләнең Иҗтимагый киңәшмәсен төзү турында карар чыгарды. Тукай авылы мәхәлләсе Иҗтимагый киңәшмәсе Россиядә беренчеләрдән булып оешты, аның составына актив шәхесләр — депутатлар, авылдагы оешма җитәкчеләре, эшмәкәрләр керде. Мәхәллә Иҗтимагый киңәшмәсенең фонды булдырылды. Аның эшенең төп юнәлеше итеп авыл яшьләрен тәрбияләү, аларга дин сабаклары укыту билгеләнде. Мәхәлләдә имам-мөгаллимнәргә, тәрбиячеләргә эш хакы түләү системасы оештырылды. Шулай итеп, уку-укыту системасы барлыкка килде. Соңгы дистә ел дәвамында Тукайда балалар өчен җәйге мөселман лагере эшли. Инде 6 ел мәчет каршында мәдрәсәбездә гыйлем бирелә. Бүген биредә 150 шәкерт белем ала. Быел өчкатлы, мең квадрат метр мәйданны биләгән мәдрәсә бинасын төзи башладык. Төзелешне халык көче белән, ягъни өмә итеп башкарабыз. Тәрбия өлкәсендә мәктәп белән бергә эшлибез. Аның ашханәсендә балаларны хәләл ризык белән тукландыруны оештырдык. Мәктәптә укучы һәр бала диярлек мәдрәсәдә белем ала, ислам нигезләрен өйрәнә. Яшьләребез дингә тартыла. Бу безнең иң зур һәм мөһим уңышыбыз. Яңа буын, туйларын хәмерсез үткәреп, үзләре гаилә кора башлады.

Моннан тыш мәхәллә күптөрле социаль проектлар белән дә шөгыльләнә. Тулы булмаган гаиләләргә, мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтүне үзебезнең бурыч дип саныйбыз. Авылыбызда хөрмәтле шәхесләрне олылау мәҗлесләре үткәрәбез. Бүгенге көндә мәхәлләбездә никахлашу, бала туу, үлем-китем таныклыклары бирелә, махсус эшләнгән китапларга теркәлеп бара. Чувашстан мөфтияте һәр мәхәлләдә мондый документларны гамәлгә кертте.

Тагын бер зур эшебез авыл халкына элеккеге колхоз җирләрен кайтарып бирү булды. Колхоз таралганнан бирле төрле кулларда булган күмәк хуҗалык җирләрен мәхәлләнең

Иҗтимагый киңәшмәсе мәчеткә бергетеп, авыл кешеләренә кайтарып бирде. Хәзер сөрүлек, көтүлек җирләре, хәтта күлләр дә мәхәллә милке булып теркәлде һәм эшләргә теләүче авылдашларга җир кишәрлекләре гадел итеп рәсми рәвештә бүлеп бирелде. Калган җирләр авылдагы фермерларга арендага тапшырылды. Аренддан кергән акча мәхәллә фондына күчерелә. Безнең хәзрәтләребез халыкка зәкят хакын да аңлата алды. Эшмәкәрләр социаль җаваплылык тоеп эш итәләр, зур ярдәм күрсәтәләр. Мәхәлләнең «Нурлы иман» газетасы чыга һәм интернетта үзенең сайты бар.

Кайберәүләр мәхәлләне мәчет һәм шул мәчет тирәсендә урнашкан йорт-авыллар дип уйлый. Чынлыкта, мәхәллә ул — мәчет кенә түгел, ә шушы җирлектәге халыкның мәдәни, социаль, рухи, мәгариф эшләре җайлап алып барыла торган һәм тулысынча дингә, милли мираска таянган яшәеш системасы. Мәхәллә ул — тулы бер җәмгыяви институт. Шуны әйтеп үтик, галим Илдус әфәнде Әмирханов — татар мөселман мәхәллә системасының идеологы, аның структурасын фәнни яктан төзегән шәхес. Без эшебезне аның хезмәтләре, киңәшләре нигезендә алып барабыз. Бүген бездә гореф-гадәтләребезгә, мәдәниятебезгә, дини кануннарга нигезләнгән чын демократик җәмгыять оешып килә. Барлык юнәлешләрдә дә эш җирле халык белән киңәш-табыш аша билгеләнә һәм тормышка ашырыла. Елына ике мәртәбә мәхәллә җыены үтә, ул карар чыгара. Шулай барлык авыл кешеләре җыелып, алдагы планнарны билгели. Әлеге җыелышта мәчет, мәхәллә Иҗтимагый киңәшмәсе, җирле үзидарә, депутатлар башкарган эшләренә хисап бирә. Җыенны авыл имамы алып бара. Гомумән, халык соңгы сайлауларда авыл һәм район депутатлары итеп дин юлындагы кешеләрне сайлады. Алар гамәлләре белән ихлас күңелдән халык өчен тырышлык күрсәттеләр. Мәхәллә эшчәнлеге муниципаль берлеккә альтернатива түгел, киресенчә, аның эшчәнлегенә зур ярдәм. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары» дип аталган Федераль канун нигезендә җирле халыкның үзе яшәгән җирдә җирле иҗтимагый үзидарә оештырырга хакы бар. Безнең мәхәллә Иҗтимагый киңәшмәсе дә шуның бер төре инде. Җирле үзидарә белән аңлашып, киңәшләшеп эшлибез. Без, мәхәлләнең активы, эшебезне хезмәт хакы өчен дә, өстән кушканга да түгел, ә ихлас күңелдән Аллаһ ризалыгы өчен башкарабыз. Моны халык та күрә, шунлыктан мәхәллә тирәсендә берләшеп, аның эшенә теләп кушылалар. Бу — ясалма, күз буяу өчен түгел, ә чын гражданнар җәмгыяте. Ассызыклап әйтәсем килә: мәхәллә ул — милләтнең нигезен тәшкил иткән милли йолаларга, дини кануннарга корылган халык үзидарәсе. Кеше турында кайгырту, бер-береңә тигез караш — бу ирекле җәмгыятьнең нигезе. Безнең өчен Чувашстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Милли-мәдәни мохтарият кошның ике канаты кебек. Алар бик зур ярдәм итәләр. Мөфти Әлбир хәзрәт Крганов белән эшләү бик җиңел. Ул безгә һәрдаим үзенең акыллы киңәшләре, яңа идеяләре белән көч биреп тора. Шулай ук Бөтендөнья татар конгрессының тырышлыгы чит өлкәләрдә яшәүче татарлар өчен әйтеп бетергесез зур әһәмияткә ия. Казан ул — һәр татарның мәркәзе. Ә Татарстан Президенты ул — бөтен татарның президенты. Бергә булыйк, бергә эшлик. Әссәламегаләйкем үә рәхмәтуллаһи үә бәрәкәтүһ. ■

«НИГЪМӘТЕҢ ШӨКРАНАСЫ ДӨНЬЯДА КЫЛМАК ИЗГЕЛЕК...»

(Хәйрияче Хөсәеневләр турында)

Хәйриячелек — кешелек җәмгыятенең рухи халәтен чагылдырган төп күрсәткечләрнең берсе. Аның нигезен мохтаҗларга, ярлыларга, ятим-толларга, авыру-зәгыйфьләргә матди яки рухи ярдәм күрсәтү гамәлләре тәшкил итә. Химая-хәйрия эше бик борынгы заманнарда ук барлыкка килгән һәм озак вакытлар дәвамында кешелек җәмгыятенең рухи кыйммәтләренә бәйләнешле гореф-гадәт буларак үсеш алган. Ә инде китаби диннәр оешып тарала башлагач, хәйриячелек дини тәгълиматта да аерым бер әхлакый норма итеп расланган, иман таләпләренә буйсынып, мохтаҗларга ярдәм йөзеннән изге эшләр кылу бигрәк тә хәлле кеше тарафыннан эшләнелергә тиеш бурыч итеп күзалланган.

Ислам дине дә хәйриячелекне үзенең зарур бер таләбе дәрәҗәсенә күтәргән. Шуңа күрә иганә кылу төрки-мөселман дөньясында да шактый киң таралган. Бигрәк тә XIX-XX йөз чикләрендә химая-хәйрия эше, татар үсешенә хезмәт итәчәк бердәнбер легаль иҗтимагый эшчәнлек буларак [1, Б.217], татар җәмгыятендә киң таралыш тапкан һәм җәмәгатьчелекнең даими игътибар үзәгендә торган.

Алдынгы карашлы татар зыялылары һәм буржуазиясе вәкилләре милләт прогрессын, иң беренче чиратта, халык мәгарифе системасын заман таләпләренә туры китереп үзгәртүдә күргән. Татар җәмгыятендә киң таралган мәгърифәтчелек идеяләре, аларның дәвамы буларак, җәдитчелек хәрәкәте әлеге үзгәрешләрне теоретик яктан нигезләсә, патша хакимияте тарафыннан үткәрелгән милли изү сәясәте шартларында нәкъ менә хәйрия эше татар тормышында урын алган реформаларның матди ягын тәэмин иткән.

Әхмәт Хөсәенов

Мәхмүт Хөсәенов

Бу дәвердә хәйрия капиталлары хисабыннан рус дәүләтенең төрле почмакларында яшәгән татарлар

өчен җәдиди мәктәп-мәдрәсәләре ачылган, әлеге уку йортлары өчен махсус мөгаллим һәм мөгаллимәләр әзерләү эше җайга салынган, сәләтле татар шәкертләренә белемнәрен камилләштерү өчен шартлар булдырылган. Әлеге үзгәрешләр татар тормышының бөтен өлкәләрендә диярлек барлыкка килгән җанлануның алшартларын тәшкил иткән. Мәсәлән, татар вакытлы матбугаты һәм матбагачылыгы эше җайга салынган, милли әдәбият һәм мәдәният үсеш алган, дәүләтнең сәяси тормышында да татарларның катнашу очраклары ешайган һ.б. Боларның бөтенесе — татар зыялылары һәм алдынгы карашлы татар буржуазиясенең ярдәм, максатчан эшчәнлекләренең уртак уңышы.

Татар буржуазиясенең аерым вәкилләренә тукталганда, чыгышлары белән Оренбург губернасының Каргалы (Сәгыйть) бистәсеннән булган бертуган Әхмәт (1837-1906), Габделгани [алга таба — Гани] (1839-1902) һәм Мәхмүт (1839-1910) Хөсәеневләр исемнәре бүгенге көндә шактый еш телгә алына. Аларның сәүдә эшчәнлекләре 1858 елда, әтиләренең вафатыннан соң, «кырык тартма» сату-алу операцияләреннән башланып киткән. Ә инде 1861 елда туганнарның уртак фирмалары, «Әхмәт Хөсәенев һәм борадәрләре» исеме белән билгеле булып, Россия империясе киңлегендә сәнәгый һәм авыл хуҗалыгы товарлары белән сәүдәсен җәелдергән [2, Б.12]. Хөсәеневләр 1873 елдан татар халкының икътисади, сәяси һәм иҗтимагый үзәге саналган Мәкәрҗә ярминкәсендә катнаша башлаган. Аларның сәүдә йорты бөтен Россия империясеннән җыелган төркимөселман сәүдәгәрләре арасында бик дәрәҗәле урын буларак билгеле. Нәкъ менә монда эре сату-алу операцияләре башкарыла, бертуганнарның таш кибетләре, ашханә һәм чәйханәләре, кунакханәләре һәм фатирлары ярминкә кунаклары өчен гөрләп эшли [2, Б.15; 3].

Тора-бара керемле сәүдә белән бергә Хөсәеневләр авыл хуҗалыгы чималын эшкәртү эшенә алынган. 1873 елда алар Оренбургта сарык тиресен эшкәртү, ә 1875 елда мал чалу һәм май эретү предприятиеләрен ача. Сәүдәгәрләрнең бу төр эшчәнлекләре елдан-ел зур үсеш ала: бөтен Россия империясе буенча аларның заводлары һәм предприятиеләре уңышлы эшләп килгән. Шулай, 1873 елга (15 еллык сәүдә эшчәнлекләренннән соң) Хөсәеневләрнең уртак мирасы 80 мең сум булса [2, Б.12], 1878 елга — 300 мең сум [2, Б.12], ә 1896 елга (18 ел сәүдә итү вакытыннан соң) — 3 миллион сумга [2, Б.16] җиткән. Бертуган Хөсәеневләр Россия империясе, Урта Азия һәм Европаның эре сәүдә үзәкләрен колачлаган киң сәүдә челтәрен булдыра. Сәүдә эшчәнлекләренең башлангыч этабында авыл хуҗалыгы һәм терлекчелек, сәнәгать товарларын берәмләп яки эре партияләр белән сату эшчәнлеге аларның төп кереме була. Ә инде XIX гасыр ахырына агай-эне авыл хуҗалыгы һәм терлекчелек чималын үзләре җитештерә башлый, сатып алынган һәм җитештерелгән чималны эшкәртү предприятиеләрен ачкан (мал чалу, май эретү, эчәк юу, ярма эшкәртү предприятиеләре һ.б.) [4, Б.21; 5, Б.557]. Шулай итеп, агай-эне Хөсәеневләр, сәүдә эшчәнлекләрен 5 сумнан башлап, берничә миллионлы капитал ияләре дәрәҗәсенә күтәрә. Аларның үсеше бу дәвердә күп кенә эре татар сәүдәгәрләре нәселләренә (Агафуровлар, Сәйдәшевләр, Акчуриннар һ.б.) хас шәкелдә бара. Тиз арада сәүдәгәр Хөсәеневләр XIX-XX йөзләр чиге татар буржуазиясенең лидерлары буларак билгеле була.

1896 елның июнендә бертуган Хөсәеневләр, уртак малларын бүлеп, һәрберсе үз сәүдә һәм җитештерү эшчәнлекләрен үстерә башлый. Әхмәт бай Хөсәенев Казанга күчә, беренче гильдияле сәүдәгәр таныклыгын алып, Казан, Оренбург һәм Оренбург губернасы, Түбән Новгород, Мәскәү һ.б. шәһәрләрдә үз кибетләрен ача һәм сату-алу эшләрен алып бара.

Сәүдә һәм җитештерү эшчәнлеге белән бергә Әхмәт бай иҗтимагый тормышта да актив катнаша, хәйриягә зур игътибар бирә. XIX гасыр ахырында ул Оренбургта һәм Казанда иң беренче хәйриячеләрдән санала. Әхмәт бай татар халкының киләчәген аның һөнәрле булуында күрә, аны сәнәгать-сәүдәгә тарту кирәклеген аңлый [4, Б.15-16]. Моның өчен рус һәм татар телләрен белү, дөньяви фәннәрне үзләштерү, заман таләпләреннән хәбәрдар булу зарурлыгы аңлашыла. Кадими мәдрәсә тәртипләрен Әхмәт бай бик яхшы белә. Шуңа аларның биналарын яңарту, шәкертләрне укыту шартларын яхшырту, гигиена һәм сәламәтлекне саклау кагыйдәләренә туры китерерлек итеп оештыру өчен матди ярдәм күрсәтергә омтыла. Казанда яшәү дәверендә аның акчасына һәрберсе 3 мең сумга төшкән 20 мәчет һәм мәдрәсә салына, 40 укытучыга хезмәт хакы түләнә, 200 уку йорты дәреслекләр белән тәэмин ителгән [4, Б.28-30]. Ә 1889 елда Оренбургта атаклы җәдиди «Хөсәения» мәдрәсәсе эшли башлый. Әлеге уку йортын шулай ук Әхмәт байның хәйрия эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак карарга кирәк. Мәдрәсәдә, нигездә, дөньяви фәннәргә өстенлек бирелә. Әхмәт бай «Хөсәения»не теория һәм практиканы уңышлы берләштерергә сәләтле белгечләр әзерли торган уку йорты итеп күзаллый.

Агай-эне Хөсәеневләрнең, шул исәптән Әхмәт байның да, кешелек сыйфатлары 1891-1892 еллардагы ачлык вакытында сынала. 1892 елда Әхмәт Хөсәенев акчасына мохтаҗларны бушлай тукландыру өчен ашханә ачыла. Анда көн саен 2000гә якын кешегә хезмәт күрсәтелгән. Мөселманнар белән беррәттән христианнарны да әлеге ашханәдә ачык йөз белән каршы алганнар. Төп җитәкчелекне анда Мәхмүт Хөсәенев башкарган. Ашханәнең өске катында яшәргә урыннары булмаган, фәкыйрь мөселман гаиләләре һәм гарипләре көн күргән [6, С.115-120].

Үзенең вафатыннан соң да Әхмәт Хөсәенев хәйрия эшен дәвам иттерүне варисларына васыять итә. Сәүдәгәрнең васыятьнамәсендә 500 мең сумнан артык капиталның иганәгә калдырылуы турында язылган. Бу акча мохтаҗларга сәдака өләшү, мөгаллим һәм мөгаллимәләргә хезмәт хакы түләү, сәләтле татар яшьләрен урта һәм югары белем бирә торган уку йортларында укыту, хаҗ кылдыру, фәнни әдәбият, дәреслек һәм методик кулланмалар, әдәби әсәрләр бастыру, «Хөсәения» мәдрәсәсен тоту кебек гамәлләргә тәгаенләнә [7, л.61]. Әлеге мирас белән эш итү һәм васыятьнамәдә күрсәтелгән эшләрне гамәлгә кую өчен махсус Химаячеләр советы төзелә [8]. Әхмәт бай Хөсәенев васыятьнамәсе төрки-мөселманнар тормышының төрле өлкәләрен үстерүгә юнәлтелә, җентекләп уйланылган һәм тормышка ашырылган программа буларак билгеле [9; 10]. Аның матди нигезен татар милләтенең иң бай һәм абруйлы вәкиле мирасы тәшкил итсә, алдынгы карашлы, гыйлемле татар элитасы әлеге программаны Россиянең төрки-мөселман халыклары алгарышы өчен файдалы һәм тиешле дәрәҗәдә гамәлгә куярга тырыша.

Гани Хөсәенев исә 1898 елдан беренче гильдияле Казалы сәүдәгәре буларак билгеле. Аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә бертуган Хөсәеневләр сәүдәсе, нигездә, Казалыда һәм аның

белән күрше-тирә шәһәрләрдә үсә. Аларның эшчәнлеге Урта Азиянең төрле төбәкләрендә җәелдерелә [2, Б.15, 293]. Туганнарның капиталлары бүленгәч тә, Гани бай нәкъ менә бу җирләрдә сату-алу эшләрен үстерүен дәвам итә.

Гани Хөсәенев агасы Әхмәт бай белән берлектә Сәгыйть бистәсе һәм Оренбургтагы барлык мәдрәсәләргә диярлек ысулы җәдитне кертүгә зур хезмәт куя. Ул — үзенең киң күңеллелеге һәм ысулы җәдитне тарату эшенә тугрылыгы белән мәшһүр шәхес. Гани бай татар-мөселманнарны башлангыч белемле итү идеясен алга сөрә. Шуңа күрә дә аның йорты ысулы җәдитнең штабына әверелә [11]. Сәүдәгәр И.Гаспралы, Р.Фәхретдин, Ф.Кәрими, Г.Баруди кебек татар дөньясының зыялы, мәгърифәтче шәхесләре белән фикердәш була.

1896 елда Гани бай халыкны агарту буенча аеруча тырыша. Ул яңа мәдрәсәләр ачу эшендә матди ярдәм күрсәтеп кенә калмаган, еш кына бу эштә үзе дә актив катнаша: мәктәп-мәдрәсәләр өчен мөгаллим һәм мөгаллимәләр сайлый, алар белән даими багланышларда тора, уку-укыту барышын һәм нәтиҗәлелеген күзәтә һ.б. 1896-1901 елларда Гани бай, мөгаллимнәр әзерләү, мәктәпләр ачу, укытучыларга хезмәт хакы түләү өчен, үз хисабыннан ел да 35-45 мең сум акча тота [12, Б.342]. Аның матди ярдәме һәм тырышлыгы белән 1897-1902 еллар дәвамында йөздән артык җәдиди уку йорты, 20 кызлар мәктәбе ачылуы мәгълүм. Сәүдәгәр 1898 елның җәендә Сәгыйть бистәсендә, җәдиди мәктәп-мәдрәсәләргә укытучылар әзерләү максатыннан, өч айлык курслар оештыра. Татар тормышында әлеге күренешнең яңа булуына карамастан, 1899-1901 елларда курслар гөрләп эшли һәм бөтен Россиядән мөгаллимнәрне җыя.

Гани бай булачак милләт аналарын — хатын-кызларны укытуга аеруча зур игътибар бирә. Аның тарафыннан 1897 елда мөгаллимәләр әзерләү курслары оештырыла. Хәйрияче курсларга килгән барлык мөгаллимәләрнең юл чыгымнарын түли, уку дәверендә үз акчасына ашата, китаплар һ.б. уку-язу әсбаплары белән тәэмин иткән.

Гани бай үзе оештырган курсларда, мәктәп-мәдрәсәләрендә әзерләнгән укытучылар белән хат языша, аларның укыту эшчәнлегенең барышы белән даими кызыксынып тора [12, Б.335]. Ул уку-укыту процессын тәртипле һәм нәтиҗәле итү өлкәсендә күп көч куя, мәктәп режимы, уку планы һәм программалары, дәреслекләр, педагогика һәм дидактика мәсьәләләрен үзе хәл иткән.

Гани байның да үзеннән соң, татар милләтенә хәйрия буларак мирасының бер өлешен калдыру теләге булуы билгеле [13; 2, Б.139-141]. Ләкин ул васыятьнамәсен тиешле рәвештә рәсмиләштерергә өлгермәгән. Шуңа да хәйрия эшләренә калдырырга теләгән капиталы аның варислары кулында тупланган.

Оренбургның беренче гильдияле сәүдәгәре Мәхмүт бай Хөсәенев исемен туганнары Әхмәт һәм Гани белән бергә искә алалар. Мәсәлән, 1910 елда дөнья күргән «Йолдыз» газетасында түбәндәге фикерләр әйтелә: «Дин вә милләт юлында иткән хезмәтләре һәм калдырган вакыфлары сәясендә [өлкәсендә] Әхмәт вә Гани байлар бөтен галәме исламга мәшһүр кешеләр иделәр. Мәхмүт бай да агалары шикелле үзенең хәйратләре илә зур шөһрәт тапты» [14].

Мәхмүт бай үзенең туганнары өчен иң беренче ярдәмче булып тора. Ул җәдиди мәктәп-мәдрәсәләр ачу, белем-мәгърифәт тарату, мөселман ятимнәре һәм гарипләренә ярдәм итү һ.б. шуның кебек изге эшләрдә

үзенең саллы өлешен кертә [14]. Тәфтиләү утарын Оренбург һәм Каргалы мәктәп-мәдрәсәләре файдасына васыять иткән [15], ләкин аның соңгы теләге дә тиешле дәрәҗәдә тормышка ашырылмаган.

Агай-эне Хөсәеневләрнең һәрберсе, төрлесе төрле дәрәҗәдә һәм төрле рәвештә, татар халкының үсешенә хезмәт иткән. Аларның бу юнәлештә үрнәк алырлык эш-гамәлләре хакында XIX-XX гасырлар чигендә дөнья күргән татар вакытлы матбугаты битләрендә даими язылса. Шул рәвешле, татарларда хәйрия эшенең торышы, эре татар хәйриячеләренең эшчәнлеге алдынгы карашлы татар зыялыларының мәкаләләрендә чагылыш таба, аларның матур гамәлләре киң җәмәгатьчелеккә җиткерелә. Бу эшкә татар милләтенең күренекле вәкиле — әдәбиятыбыз классигы, мәшһүр филолог һәм тарихчы, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов та үз өлешен кертә. Агай-энеле Хөсәеневләр һәм аларның «Хөсәения» мәдрәсәсе әдипкә яхшы таныш булуы билгеле, чөнки нәкъ менә 1898-1905 елларда ул үзе дә бу уку йортында белем ала, шәкертләр хәрәкәтендә актив катнаша, уку-укыту барышының сыйфаты һәм нәтиҗәлелеге өчен көрәшә. Шәкертлек чорында «Хөсәения»дән куылса да, әдип агай-энеле Хөсәеневләр эшчәнлегенең әһәмиятен яхшы аңлый һәм киң җәмәгатьчелек алдында аларга булган ихтирамын белдерә. Г.Ибраһимовның 1914 елда «Йолдыз» газетасы битләрендә дөнья күргән мәкаләсе моның ачык дәлиле булып тора. Анда Гани бай Хөсәенев һәм аның туганнары Әхмәт һәм Мәхмүтнең хәйрия эшләренә дан җырлау, үрнәк итеп кую һәм аларның тәҗрибәсен татар дөньясына таныту омтылышы чагылыш таба. Хәзерге заман укучысы өчен әлеге мәкалә татар хәйриячелек тарихын өйрәнүдә кыйммәтле тарихи чыганак булып тора. Бертуган Хөсәеневләрнең кылган изге гамәлләре хәзерге татар байлары һәм эшкуарлары өчен дә үрнәк булсын иде.

Чыганаклар һәм әдәбият исемлеге

1. Миннуллин З.С. Татарские благотворительные общества во второй половине XIX — начале XX вв. // Благотворительность в России: исторические и социально-экономические исследования. 2002 год. — СПб: Лики России, 2003. — С. 215-229.

2. Гани бай: тәрҗемәи хәле, хатлары, аның хакында хатирәләр / Төз. Б.Шәрәф. — Оренбург, 1913. — 307 б. — Б.12.

3. ГАОО. Ф.213. Оп.1. Д.58.

4. Фәхретдин Р. Әхмәт бай. — Оренбург, 1911. — 54 б.

5. Торгово-промышленная Россия. Справочная книга для купцов и фабрикантов / под ред. А.А.Блау. — СПб, 1899. — 2702 с.

6. Судорогина Т.В. У истоков мусульманского благотворительного общества (по материалам Оренбургской периодической печати конца XIX-начала XX вв.) // Христианство и ислам на рубеже веков: Материалы Всероссийской научно-практической конференции. — Оренбург: ДиМУР, 1998. — С.115-120.

7. ГАОО.Ф.10. Оп.4. Д.420.

8. Әхмәт Хөсәенев вакыфы мөтәвәллиләренең рәсми игъланы // Вакыт. — 1908. — 23 сентябрь. — №373; Әхмәт бай стипендияләре // Вакыт. — 1909. — 14 июль. — №493; Әхмәт Хөсәенев вакыфы мөтәвәллиләре игъланы // Вакыт. — 1911. — 14 август. — №827; Әхмәт Хөсәенев вакыфы мөтәвәллиләре идарәсеннән. Стипендияләр турында // Вакыт. — 1916. — 7 сентябрь. — №2092; Вакыф отчёты // Вакыт. — 1916. — 9 февраль һ.б.

9. ГАОО. Ф.213. Оп.1. Д.63.

10. Мәрхүм Әхмәт бай // Вакыт. — 1906. — 21 декабрь. — №113; Әхмәт бай васыятьнамәсе // Йолдыз. — 1906. — 17 декабрь.

11. Оренбург яңалыклары // Вакыт. — 1912. — 28 сентябрь. — №1044.

12. Гайнетдин М. Гани бай (яңа мәктәп өчен көрәш) // Гайнетдин М. Мәңге тонкланмас көзгебез. — Казан, 2006. — Б.327-349.

13. Ибраһимов Г. Гани бай вакыфы мәсьәләсе // Йолдыз. — 1915. — 1 октябрь. — №1523.

14. Мәрхүм Мәхмүт бай // Йолдыз. — 1910. — 17 август.

15. Мәрхүм Мәхмүт Хөсәенев васыятьнамәсе // Вакыт. — 1910. — 17 август. — №656.

ГАНИ БАЙ

(ТӘХРИР ИТҮЧЕСЕ БОРҺАН ШӘРӘФ)

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

I

Мөстәшарлар [киңәшчеләр, фикердәшләр] тәгъбиренчә, Волга җөзъәсендә [кыйтгасында (кыйтга — өлеш)] «яңа туып килә торган» бер милләт бар. Русия харитасында аның тоткан урыны, Русиянең [картасында] хәяты икътисадиясендә [икътисади тормышында] аның азмы-күпме күрсәткән тәэсире мәгълүм. Бу җәһәттән әүвәл үзен күрше, ватандаш хаким вә мәхкүм [изелгән] милләтләрнең һәммәсенә тәсдыйк иттергән [таныттырган]...

«Яңа туып килә торган» мәгънәсе белән булса да, ул милләтнең мәгънәвияте [рухи халәт] бар. Ул хәяты икътисади вә матдиясендә күрсәткән хәрәкәтне мәгънәви-гыйльми, рухи хәятында да күрсәтә: аның егерме биш яшендә булса да, ун яшендә булса да театры, матбугаты, әфкяре гаммә [иҗтимагый фикер, җәмәгать фикере] тудырган бик ныклап хезмәт итә торган матбугаты бар.

Ул туган җирендә үсеп чыккан мазыйсыз-нисез тәшәккөл итәргә [шәкелгә керү, оешу, формалашу] теләгән, көчләп «милләт» булырга, мәдәни милләтләр арасына катышырга, алар силсиләсенә [сафына] тезелергә маташкан бер милләт түгел; аның үткәне бар, тарихы бар. Тарихның башка күп милләтләре кебек ул да үзенең мувәкъкыйгъ [бер вакытка караган, вакыт белән чикләнгән] җәгърафиясе, мохите, тәшкиләте димагыясе [аңлы оешмасы] яртылаш тудырган тормыш белән коруне уляды [борынгы гасырлар] яшәде, коруне вустаны [урта гасырлар] кичерде.

Искәндәр Кәбир Александр Македонский гареб милләтләрен, гарби [көнбатыш] кәвемнәрне шәрекъ милләтләренә шәркый кәвемнәргә алып барып аралаштырган; аларны бер-беренә мәдәният ирештергән, фән аралаштырган кебек, бу милләтнең Атиллалары, Чыңгызлары, Батулары да шәркый кәвемнәрне гарби кавемнәргә аралаштырган, аларны бер-беренә кан аралаштырткан...

Атиллалар, Батулар, Рейн вә Двина елгаларын кичеп, кулларын күзләренә салып, җәнүб көньяк вә гареБашкарма комитетә таба еракларга карадылар; җәнүб вә гареб диңгезләренә килеп җиткәнлекләрен күрделәр; татарлыкның мувәкъкыйгъ җәгърафиясе вә истиляи әразый [басып алынган җир] ноктаи назыйрендән [идарә итү күзлегеннән] гая [соң, чик, ахыр] әмәленә ирешкәнлегенә канәгать хасил иттеләр.

Заманнар алмашынды. Гареб вә җәнүБашкарма комитетә килеп, башка кавемнәр белән уралып алынган, алар белән кода-кодагый булган төрек-татар балаларына аттан төшәргә, йорт кораштырырга, җирне сукалап тырмарга, авыл булып утырырга, алыш-биреш итәргә, каләм-кәгазь тотарга, «абыз»ның алдына тезләнеп сабак укырга, мәсҗедкә барып, бер Тәңрегә юнәлергә вакыт җитте...

Ат өстеннән төшеп, «абыз»ның алдына тезләнү!...

Ә! ...Менә бу — бер кавемнең бер милләтнең хәятында бик зур бер алмашыну!..

Бу алмашыну дәверен уйлаганда минем күз алдым караңгылана, төкләрем өрпәреп [кабару] китә!...

Хәзерлексез, мескен татар хәят [тормыш] мәйданында бу юлы инде бөтенләй икенче төрле ярышка чыга; ул бу юлы җир өстендә торырга теләп-теләмәве, аның моңа сәляхияте [сәләт, осталык] булып-булмау мәсьәләсендә сынала.

Кылыч тотып кәкрәйгән, каткан бармакларга каләм-кәгазь тотып язу бик үк җиңел булмаячагы кебек, табигатьнең киң болыннарында ат ашатып, катык ашап, киерелеп яткан татарга сука тотып җир актару да күңелле булмаячак. Иге-чиге булмаган сахраларда киң сулыш алып яшәргә өйрәнгән; Алтайның итәкләрендә хәйләсез гомер кичерергә алышкан [алынган] татарга шау-шулы шәһәрләрдә яшәп, хәйләле кәсеп белән маташу күңел тарландыручы, баш әйләндерүче бер хәят булачагы мәгълүм.

Хәзер инде күршеләрнең муенына корык салып, тартып аттан төшереп булмый; алар белән узышырга, гакыл вә аң белән эш йөртеп чиктән тыш фәгалиять [эшлеклелек, эшчәнлек] сарыф итәргә, күп кысынкылыкларга түзәргә туры килә...

Урманда ботактан ботакка очып-кунып, иркендә сайрап йөри торган бер кош читлеккә ябып куелганда, бичара кошның хәле ничек булса, бәдәви [күчмә тормыш белән яшәүче] хәленнән мәдәни хәлгә күчү дә, татар өчен шулай иде.

Бу — татар өчен мәдәни тормышта беренче баскыч.

Бу дәвердә, бик кечкенә бер мәхәллә мәсҗеде салып, аның янына шулай ук кечкенә мәктәп торгызган һиммәтле [тырыш], диниятле, хәмиятьле [яклаучы, ярдәмче] татар — ул дәвернең Гани бае [Габделгани Хөсәенев]; мәктәптә укытучы «абыз» — ул дәвернең Гаспринские [Исмәгыйль Гаспринский] иде...

Ул дәвернең безгә исеме мәгълүм булмаган Гани байлары, Гаспринскийлары — бу милләтнең бик олуг каһарманнарыдыр. Татарның саналу дәверендә алар җаннары-тәннәре белән күп хезмәт иттеләр; милләтнең бер хәленнән икенче хәлгә күчүендә күп кысынкылыклар чиктеләр, кыенлыклар күрделәр...

— Язмыш шулай икән, күрәсең!... — дип татар баласы, заманның үзгә рәвешләренә риза булды. Тәкямелнең [җитешү, тулылану, төгәлләнү] фәгалияте, сөкүнәт соңлау [тик тору, кузгалмау, соңару] кагыйдәсенә бинаән коруне улядыннан бирле сарыф ителгән фәгалиятне, сөкүнәт тәгакыб [торгынлык алмаштыру] итәчәк иде.

Татар баласы берничә гасырлар бер җирдә әйләнеп торды, ул истирахәт [ял итү, эштән бушап тору, рәхәтләнү] итте, куәт җыйды, хале мәдәнияттә [мәдәниятнең] тәгъзу дәверен [юану, торгынлык дәвере] кичерде, аны заман шуңа мәҗбүр итде.

Мулла мәсҗедтә Алланың берлегенә, пәйгамбәрнең хаклыгына иман китерергә өнди бирде, «абыз» да чыбыгын кулына тотып, ни җитте, шулай сабак укыта бирде, кәлимәи шәһадәте өйрәтте, әбҗәд [хәрефләр ярдәмендә тапкырлау җәдвале] белдерде, иҗеккә башлатты, аны бетертте, Коръән укытты, мөселман җитештерде...

Харита галәмендә булган үзгәрешләрдән, халыкларның мәдәниятkә таба булган юлны кыскартырга тырышулардан, аз вакыт сарыф итеп, күп файда алырга теләүләреннән, максатка тизрәк барып җитүнең юлларын эзләүләреннән, «абыз»ның хәбәре юк, ул кулына чыбыгын тоткан — укыта, дөньяга әһәмият бирми, мөселман җитештерергә тырыша...

II

Заманның алмашынуы, милләтләрнең алга атлау вә җәяүлеләре, күршеләрнең мәдәният баскычларын менүдә безгә үрнәк булулары, берне бер җирдә әйләнеп тормыйча, сызыкның бер җиреннән бозып чыгып, туры юл алырга мәҗбүр итүләре аркасында без икенче дәвергә күчәргә, ул дәверне башларга булдык.

Теге, беренче дәвер, безнең өчен никадәр кыен булса, бу дәвер дә шулай ук кыен булачак иде. Чөнки төрек-татар баласының теге җиһан гизгәндәге сафлыгы, космополитлыгы үзенең төсен югалта төшкән, аңа башка буяу сөрткәннәр иде:

— «Абыз»ның хәзер мәгълүматы (!) күбәйгән, башы чуалган иде. Ул: «Мин үзем алган юл белән бара бирәм, чөнки...» — диядер иде.

Менә татарның татарлыгын тазартырга, андый-мондый чүп-чардан әрчеп, татарлык басуына яңа орлыклар чәчәргә замана каһарманнары кирәк булды, заман моны телидер иде.

Заманның теләге булды:

Бакчасарайда чыккан «Кигәвен»нең [«Кигәвен» басмасы] безелдәве, Волга җөзъәсендә йокларга һич ирек бирмәде... Аның безелдәве арасында «мәктәп, мәктәп, мәктәп!...» дигән сүзләр ишетеләдер иде. Бу «мәктәп, мәктәп» дигән коры сүзне фәгалияткә [гамәл, эш эшләү] чыгару өчен Ходайның бер сөекле бәндәсе Казалыда сәрмая [капитал (белем байлыгы)] җыеп ята иде.

Инде мәсьәлә тәсадефнең [очрашу, туры килү] бу ике милләт хезмәтчесен бер-бере белән күрештерүдә, таныштыруда, аңлаштыруда туктап торадыр иде. Заман аңа да ярдәм итте: бу ике фидакарь Сәмәркандта очраштылар. Икесе дә гамәли кеше булганга, бер мәктәп тәэсис итеп [нигезләү, оештыру, кору], ысулы җәдидәне тәтбикан [килештереп] куйдылар.

III

«Гани бай» китабы, Борһан әфәнде Шәрәф каләме белән тәэлиф ителеп [төзелгән], Ширинбану ханым Хөсәенева һәм балалары тарафыннан нәшер ителгән. Әсәр — Гани байның тәрҗемәи хәленнән, аның мәктүпләреннән вә аның хакында булган хатирәләрдән гыйбарәт, зур форматта — өч йөз сәхифәлек — бер китап. «Вакыт» матбагасында мөмкин кадәр нәфис итеп бастырылган.

Ширинбану ханым һәм балаларына, тәҗдиде тарихыбызга [яңа тарих] каршы бурычларын үтәп, Гани байның рухын шатландырганлыклары өчен рәхмәт әйтергә мәҗбүрбез.

Мөәллиф [китап төзүче] китапның сүз башында шушы сүзләрне әйтә: «Шөбһә юктыр ки, ысулы җәдидә хәрәкәте, милләтебездә бик олуг фикри инкыйлабның башлангычы булып, тарихыбызда бөек урын тотачак. Киләчәк нәсел бу хәрәкәт дәверен тәдкыйк илә [дикъкатьләп тикшереп] үгрәнәчәк. Бүгенге кешеләрнең вазифалары исә аларга бу хосуста материал җыеп калдырмактыр».

Китап — башыннан аягына кадәр ысулы җәдидә тарихы өчен материал. Бу җәһәттән мөәллиф вазифасын бик яхшы үтәгән, бу яктан хәвеф юк.

Мәсьәлә менә мондый: мөәллиф: «Ысулы җәдидәнең ничек мәйданга чыкканлыгын тәгаен итүдә ихтиляфлар [каршылык, төрлелек] булырга мөмкин», — ди.

Менә шул ихтиляфлар булуның мөмкинлеге мине бу хакта бер-ике сүз әйтергә мәҗбүр итә: «Тарихи вакыйгалар вә аларның каһарманнары өстеннән заман таптап узган саен ул вакыйгалар мәҗһүлләнә [билгесезләнә, бозыла], күгәрә бара, күгәргән саен мөәррихләр [тарихчы] арасында ихтиляф өчен зәмин [нигез, җирлек] тәшкил итә баралар...»

Бинаэнгаләйһи [кыскасы], бездә ысулы җәдидә тарихы киләчәк нәселгә калдырылмыйча хәзердән язылсын иде. Эчке Русиядә ысулы җәдидәнең матди яктан ярдәмләшү, хәтта иң элек ысулы җәдидә мәктәбе ачу җәһәтеннән иң бөек каһарманы — Гани байның тәрҗемәи хәле дә һәм материал хәлендә калдырылмыйча бер мөкәммәл [тәмамланган, камилләшкән, тулы] ышанычлы тарих, ысулы җәдидә тарихының бер кисәге хәленә китерелгән булсын иде. Гани байның хат язышкан кешеләре, аның хакында хатирәләр язган кешеләр исән вакытта Гани байның тәрҗемәи хәле ныгытылырга, бер тарих хәленә китерелергә тырышылган булса иде!..

Мәсәлән, Гани байның тәрҗемәи хәленә мөкаддимә [кереш] вә хатимә [йомгак]

итеп кыска гына: «Ысулы җәдиденең нидән гыйбарәт икәнлеге, нинди сәбәпләр тәхте тәэсирендә туганлыгы, ни микъясда тәтбыйк [нинди үлчәү белән чагыштырып карау] ителгәнлеге, ничек тәкямел итүе [камилләшү, тулылану, төгәлләнү]; Гани байдан соң аның даирәи интишары [таралу, җәелү даирәсе] ничек киңәйгәнлеге; хәзерге хәле ... бәян ителгән булса, ысулы җәдидә тарихына бик нык бер нигез салынган булыр иде. Затән бездә ысулы җәдидә тарихын Гаспринский вә Гани бай кебек бер-ике затның тәрҗемәи хәле белән, бер-ике мәкъбүл [кабул ителгән] вә мөнтәшир [басылган] дәреслекнең тарихына ияртеп бик мөкамил рәвештә язарга була. Ысулы җәдидә тарихын вөҗүдкә китерү — киләчәк нәселдән бигрәк хәзерге нәселнең бурычы».

«Гани бай» китабының хакы бер сум куелган. Китап бер сумга кыйммәт түгел, ләкин аны бер сум биреп алу һәр укучының кулыннан килми. Бу — бер, икенче яктан — тарих өчен җыелган хам [чи, эшкәртелмәгән] материалны ялкауланмыйча укып чыгу да һәр укучының кулыннан килми. Мин бик җитди сурәттә хәзерге әдәбиятыбызны тәгъкыйб [кичегү, соңга калу] итүчеләр арасында, «Гани бай» китабындагы мәктүпләр вә хатирәләрне сайлап-сайлап укучыларны күрдем. Хәлбуки, Гани байның тәрҗемәи хәле бездә бик күп кеше тарафыннан укылырга тиеш. Аны ирләр дә, хатыннар да, картлар да, яшьләр дә, приказчиклар да, шәкертләр дә, байлар да, фәкыйрьләр дә... — хасыйле [нәтиҗәдә] һәр сыйныфтан, һәр яшьтәге, һәртөрле сәядагы кешеләр укысыннар, укып бик тәэсирле гыйбрәтләр алсыннар, ирләр белән хатыннар Гани бай кебек милләт атасы җитештерергә тырышсыннар, картлар Гани бай була алмаганлыкларына үкенсеннәр, яшьләр Гани булырга теләсеннәр, приказчиклар Гани бай кебек бай булырга, аның кебек мал җыярга керешсеннәр, шәкертләр Гани куәтләп юлга салып җибәргән ысулы җәдиденең зур, мәгънәви каһарманы булырга иҗтиһад итсеннәр, байлар Гани бай юлыннан барырга кызыксыннар, фәкыйрьләр Тәңредән Гани бай кебек һиммәтле бай сорасыннар иде!...

Менә шуның өчен дә, минемчә, Гани бай мәрхүмнең балаларына кечкенә бер вазифа тәрәттеб итә [рәткә салына, тәртипләнә, йөкләнә], улдыр кәм: хәзерге «Гани бай» китабы ысулы җәдидә тарихын язачак мөәррихләр [тарихчылар] өчен материал булып китапханәләрдә саклансын да Гани байның тәрҗемәи хәлен 300 сәхифәдән 30 сәхифәгә кыскартып, бер рисалә шәкелендә мәйданга куярга кирәк, хакы да очсыз куелсын. Аны һәркем алып, укып файдалансын.

Гани бай хакында теге югарыда саналган сыйныф кешеләре өмет ителгән файданы алсын өчен, аның рисалә шәкелендәге тәрҗемәи хәле Гани байны күңелләргә кертеп җирләштерә алачак тәэсирле, дәртле каләм тарафыннан яздырылырга кирәк!..

Галявә [кыскасы]: китапны укып чыккач, мәрхүм Гани байның һиммәтле, фидакарь, фәгъгал [бик эшчән], гамәли, хуш сөхбәтле [күңелле әңгәмәдәш], тәгълим вә тәгаллем [өйрәнү вә өйрәтү] юлында ничә йөз меңләр сарыф иткән бер ысулы җәдидә каһарманы булганлыгын аңлыйбыз. Йөзнең идеалын. Киң үлчәүдә тәтбыйкъ итәргә аңа, фәләк [бәхет, язмыш, тәкъдир] мөсагадә [мөмкинлек бирү, булышу, ярдәм итү, үзара ярдәм итешү] итмәгән.

Өмитдер ки [өмет итәбез ки]: Гани байны тудырган татар хатыны тагын да берничә Гани байлар җитештерә торгандыр, тагын да берничә Гани байларны тудырырга хәзерләнә торгандыр.

«Йолдыз» газетасы. — 1914 ел. — 11 май. — № 1185. — Б.2-3.

Кереш мәкаләне һәм текстны басмага тарих фәннәре кандидаты ***Римма Шәйдуллина*** *әзерләде.*

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ЭШМӘКӘРЛӘРЕНӘ ЯРДӘМ ИТҮ АССОЦИАЦИЯСЕНЕҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА

ФӘРИТ УРАЗАЕВ,
Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясенең башкарма директоры

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ЭШМӘКӘРЛӘРЕНӘ ЯРДӘМ ИТҮ АССОЦИАЦИЯСЕ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ҺӘМ СНГ ИЛЛӘРЕ ЭШМӘКӘРЛӘРЕНЕҢ ИНИЦИАТИВАСЫ БЕЛӘН ҺӘМ БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ КАРАРЫ НИГЕЗЕНДӘ 2009 ЕЛНЫҢ 11 ДЕКАБРЕНДӘ КАЗАН ШӘҺӘРЕНДӘ ОЕША.

Ассоциация — коммерцияле оешма түгел, ул Россия Федерациясе һәм БДБ илләрендәге, шулай ук чит илләрдәге татар эшмәкәрләренең эшчәнлеген координацияләүгә хезмәт итә. Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясенең төп юнәлешләренән берсе булып, Татарстан Республикасының дәүләт структуралары белән икътисад, фән һәм мәдәният өлкәсендә багланышлар урнаштыру тора.

Ассоциациянең төзелүе дә Россия Федерациясе һәм БДБ илләрендәге, шулай ук чит илләрдәге татар

җәмгыятьләрендәге эшлекле даирәләрнең вәкилләре арасында күпкырлы хезмәттәшлек алып баруга ихтыяҗ белән бәйле иде.

Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе үзенең төп максаты дип эшлекле даирәләрдәге татарлар арасында икътисад, фән һәм мәдәният өлкәсендә үзара тыгыз мөнәсәбәтләр булдыруны сайлады, бу исә түбәндәге юнәлешләрне күз алдында тота:

— татар эшмәкәрләрен берләштерү;

— алар арасында үзара файдалы хезмәттәшлек урнаштыру, икътисади һәм мәдәни бәйләнешләрне ныгыту;

— татар эшмәкәрләрен Татарстан базарына җәлеп итү өчен шартлар тудыру;

— ассоциация әгъзаларына бизнес алып баруда, төрле проектларны эшләү һәм тормышка ашыруда ярдәм итү;

— бизнес белән идарә итү өлкәсенә алдынгы технологияләр кертүгә юл ачу;

— Россия Федерациясе регионнарында һәм БДБ илләрендә, шулай ук чит илләрдә яшәүче татарларның икътисади һәм мәдәни бәйләнешләрен киңәйтү өчен уңайлы шартлар тудыру.

Ассоциациянең бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

— татар эшмәкәрләрен бердәм эшлекле һәм мәгълүмати кырда туплау;

— эшчәнлекнең яңа юнәлешләрен оештыруга һәм партнёрлыклар булдыруга ярдәм итү.

Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү логотибының рәсеме өч балдак рәвешендә, алар ассоциациянең төп эшчәнлек төрләре булган икътисади, милли-мәдәни һәм мәгълүмати якны символлаштыра. Логотипның төс гаммасы Татарстан Республикасы символикасында катнашкан өч — ак, яшел, кызыл төсләрне үз эченә ала, шулай традицион татар бизәгенә хас милли төсмерне ассызыклый.

Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе логотибындагы балдаклар кисешкәндә, кызыл төс ярдәмендә уратып алынган лотос чәчәген хасил итә. Кызыл лотос — беренчел табигатьне һәм йөрәк, уйомтылышлардагы чисталыкны символлаштыра. Ул өч өлештән (җир, су һәм һава) гыйбарәт, кеше дә өч: матди, гакълый һәм рухи — дөньяларда яши. Лотос капма-каршылыкларның берлеген һәм үзеңне үз асылыңнан кабат бар итүне гәүдәләндерә. Шәркый традицияләр буенча лотос кеше тормышын һәм галәмне символлаштыра, иҗат итү, дөньяның яратылуы символы буларак күзаллана, кешенең рухи камилләшүендәге өч этапны, алгарыш һәм үсешне белдерә. Лотос — уңышка ирешү символы да.

Ассоциациянең идарәсе:

1. Рәисе — Саттаров Нурулла Гарифулла улы (Төмән шәһәре);
2. Башкаручы директор — Уразаев Фәрит Язкәр улы (Казан шәһәре);
3. Идарә әгъзасы — Насыйров Ринат Хәмзә улы (Төмән шәһәре);
4. Идарә әгъзасы — Ганиев Эдуард Әнвәр улы (Саратов шәһәре).

Ассоциация әгъзалары:

1. Әбләзев Камил Алим улы (Саратов шәһәре, Саратов өлкәсе);
2. Алимбаев Тамир Алимбай улы (Омск шәһәре, Омск өлкәсе);
3. Акбулатов Шамил Измаил улы (Санкт-Петербург шәһәре, Ленинград өлкәсе);
4. Абдуллин Рөстәм Шәкүр улы (Комсомольск-на-Амуре шәһәре, Хабаровск крае);
5. Абдуллин Ринат Мидхәт улы (Казан шәһәре, Татарстан Республикасы);

6. Бикмаев Шамил Зәкәрия улы (Саранск шәһәре, Мордовия Республикасы);

7. Вәлиуллин Җәмил Рәхимҗан улы (Тольятти шәһәре, Самара өлкәсе);

8. Гафуров Радик Мансур улы (Ульяновск шәһәре, Ульяновск өлкәсе);

9. Кәримов Тәүфикъ Әкрам улы (Астана шәһәре, Казахстан);

10. Колесникова Лена Рафикъ кызы (Чиләбе шәһәре, Чиләбе өлкәсе);

11. Мөслимов Ильяз Булат улы (Мәскәү шәһәре, Мәскәү өлкәсе);

12. Садриев Ринат Риват улы (Екатеринбург шәһәре, Свердловск өлкәсе);

13. Тимергалиев Илмир Насих улы (Симферополь шәһәре, Украина);

14. Шәкүров Ильяс Гомәр улы (Самара шәһәре, Самара өлкәсе).

Уставтагы максатларга ирешү өчен Ассоциация түбәндәге эш төрләрен башкара:

— Ассоциациядә катнашучылар уңышлы эшмәкәрлек белән шөгыльләнсен өчен, базар конъюнктурасын, бәһаләр сәясәтен, мәгълүмати һәм технологик чыганакларны тикшерү;

— семинарлар, конференцияләр, симпозиумнар, бизнес-турлар оештыру һәм уздыру;

— Россия Федерациясендә һәм аннан читтә реклама, нәшер итү, полиграфик һәм башка мәгълүмати эшчәнлек белән шөгыльләнү;

— бизнес-проектларны тормышка ашыру максатында инвестицияләр җәлеп итү;

— бүленгән акчаларны нәтиҗәле файдалануга гарант вазифасын башкару;

— фәнни-техник һәм уку-укыту, башка чаралар һәм эшләнмәләрне оештыру һәм финанслау.

Бүгенге көнгә Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясенең мәгълүматый тупланмасы (сайт-портал) эшли: татар эшмәкәрләре турында мәгълүматлар банкы (2000 кеше) тупланды, ассоциация сайтында яңа кулланучылар теркәлде (100 кешедән артык), дилер хезмәтләре, электрон хезмәтләрдән «Татар базары» һәм «Татар кибете» (сувенир, китап һ.б. продукция) оешты, Татарстан хөкүмәтенең реклама хезмәте, электрон сәүдә хезмәте гамәлдә, татар виртуаль дөньясы булдырылды, татар эшмәкәрләре арасында иганәчелек пропагандасы алып барыла, татар дөньясындагы яңалыклар күзәтелә һ.б.

Хәзер ассоциация филиалларында һәм вәкиллекләрендә (татарлар тупланып яшәгән төбәкләрдә татар эшмәкәрләре өчен бизнес клублар, фондлар, мәдәни-эшлекле үзәкләр) эш җәелдерелде. Болар:

— Самара өлкәсендәге татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе (Самара өлкәсе);

— Оренбург төбәге татар эшмәкәрләренең берлеге (Оренбург өлкәсе);

— Төмән өлкәсендәге татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе (Төмән өлкәсе);

— Истамбул шәһәрендәге татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе (Төркия);

— Клайпеда шәһәрендәге татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе (Литва);

— Татар эшмәкәрләренең Ульяновск өлкәсендәге «Сембер» иҗтимагый оешмасы (Ульяновск өлкәсе);

— «Дуслык» коммерцияле булмаган партнёрлык (Свердловск өлкәсе);

— «Казан «Бизнес-Клубы» иҗтимагый фонды (Казахстан);

— Өремчедәге «Алтын чишмә» интернациональ компаниясе (Кытай);

— Өремчедәге «Агыйдел» экспорт-импорт компаниясе (Кытай);

— Идел буе татарларының «Идел» Кырым республика ассоциациясе (Украина).

Хәзерге этапта Чиләбе һәм Хабаровск шәһәрләрендә Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясенең филиалларын ачарга әзерлек эше алып барыла.

Россия Федерациясе һәм СНГ илләрендә Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясенең филиалларын ачу татарлар арасында икътисади һәм мәдәни бәйләнешләрне җәелдерүгә, бизнес белән идарә итү өлкәсенә алдынгы технологияләрне, шулай ук чит ил инвестицияләрен җәлеп итүгә юнәлдерелгән.

Россия регионнарында ассоциациянең филиалларын оештыруга сәбәп булып, соңгы елларда татарлар тупланып яшәгән җирләрдә алып барылган икътисади һәм социаль тормыш хәлен тикшерүләр тора. Регионнарда татарлар, бигрәк тә бизнес ачканда, урап үтеп булмаслык авырлыкларга очрый. Бу ситуацияне читтән күзәтеп тору мөмкин түгел, шуңа күрә Россия регионнарында татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе төзү хакында карар кабул ителде.

Оешмалар татар эшмәкәрләрен берләштерүгә, кече һәм олы бизнес өлкәсендә бизнес-проектларны һәм эшмәкәрлек идеяләрен тормышка ашырырга юл ача.

Ассоциация проектлары арасында:

1. Татар телендә Коръән тәфсирләрен бастырып чыгару (текстны таный һәм кабатлый ала торган аудио-электрон каләм белән Коръән).

Бу проектта Коръәнне татар телендә уку, өйрәнү һәм шәрехләү өчен өр-яңа, заманча технология тәкъдим ителә. Нигез итеп Ногмани тарафыннан татар телендә әзерләнгән Коръән сурәләрен шәрехләүләр алынды (Ногмани. Коръән Тәфсире). Җайланманың хәтеренә, хәтта, тәфсирләрнең рус, инглиз, шулай ук фарсы, үзбәк, казах телләрендәге вариантлары, һәм, әлбәттә, гарәп телендә укылган оригинал текст урнаштырылган.

Шулай ук өч вариантта: мөгаллимнәр һәм студентлар өчен файдаланырга уңайлы сумкада, бүләк тышлыкта һәм VIP-персоналар өчен югары зәвык белән бизәлгән — «электрон Коръән» бастырыла.

Изге Китапның электрон варианттагы беренче нөсхәләрен ассоциация KAZANSUMMIT 2012 уздырылган көннәрдә Татарстан Президенты Р.Н.Миңнехановка, Татарстан Республикасының Дәүләт киңәшчесе, Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне тергезү буенча Республика фондының Попечительләр Советы Рәисе Минтимер Шәймиевкә бүләк итте. Шулай ук 100 нөсхә татар телендәге Коръән тәфсирләре Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе исеменнән Идарә рәисе Нурулла Саттаров, башкарма директоры Фәрит Уразаев, ассоциация әгъзасы Әнвәр Әминов тарафыннан Казан Кремлендә Минтимер Шәймиев белән очрашу вакытында «Яңарыш» Фондына тапшырылды.

Аудиоверсия татар-мөселманнарга Коръәнне өйрәнү һәм төшенү эшен җиңеләйтә, электрон формат исә яшьләр аудиториясенә кирәк. «Татар телендә Коръәнне шәрехләү» — Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясенең мәгарифкә керткән өлеше ул.

2. «Туристик бизнес» проекты:

а) Идел буе татарларының «Идел»

Кырым республика ассоциациясе кул астында «Алтын тур» туристик фирмасы эшләп килә, ул Кырымдагы Евпатория ял йортында һәм башка урыннарда туристлар өчен ял һәм дәвалану оештыра. Темасы: «Татарлар иленә сәяхәт»;

б) Ассоциация «Хәләл-тур 21» компаниясе белән берлектә мөселман илләренә, аерым алганда Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә, сәяхәтләр оештыра;

в) Медицина туризмы (Төркия). Ассоциациянең Истамбул шәһәрендәге филиалы татарстанлыларны Төркия ял йортларына дәваланырга җибәрү белән шөгыльләнә.

3. Төркия эшмәкәрләре һәм җитештерүчеләренең TUSKON Конфедерациясе белән урман хуҗалыгында җитештерү һәм агач эшкәртү өлкәсендә хезмәттәшлек;

4. Ассоциация филиаллары һәм вәкиллекләре эшләгән төбәкләрдә (Самара, Оренбург, Ульяновск, Казахстан, Төркия, Украина, Кытай, Литва) җитештерүче продукциясен сатып алу өчен складлар ачу буенча эш.

5. Татарлар тупланып яшәгән төбәкләрдә кече һәм урта бизнесны оештыруга һәм юридик тәэмин итүгә булышу:

а) «Эшмәкәрлекне үстерү ачык институты» (фермер хуҗалыклары, яңа энергия саклаучы технологияләр, инвестицияләр оештыру, муниципаль берәмлекләрнең территорияләрен камилләштерү вакытында ярдәм итәрлек юридик һәм икътисади курслар) исемендә коммерцияле булмаган партнёрлыкны теркәү. Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе «Эшмәкәрлекне үстерү ачык институты», республиканың инвестицион үсеш Агентлыгы, Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән берлектә Татарстанның Актаныш районы территориясендә Милли парк оештыру буенча эш алып барыла;

б) «Агач йорт төзү буенча Идел буе Үзәге» исемендә, Идел буе регионында агач йорт җитештерү һәм төзү белән шөгыльләнүчеләрне берләштергән (төзелеш материаллары җитештерүчеләр һәм төзүчеләр белән турыдан-туры, арадашчысыз килешүләр төзү, төзелеш объектларын вакытында сафка бастыруга килешү йөкләмәләре буенча, төзелештә сыйфатлы, экологик чиста материаллар файдалану ягыннан гарантия) коммерцияле булмаган партнёрлыкны теркәү;

в) Фермер һәм шәхси хуҗалыкларда җитештерелгән хәләл продукция белән ачылачак Агропромышленность паркы мәйданнарында күмәртәләп яки ваклап сатуны оештыру;

г) Әлмәт шәһәрендә («Экопрод» Урта Әләзән авылы, Сарансктагы «Карпайский», Алкиндагы «Хәләл») хәләл продукция, урман тармагы продукцияләре (Удмуртия, Киров өлкәсе), энергия саклый торган технологияләр (Оренбург өлкәсе), авыл хуҗалыгы техникасы (Омск шәһәренең Татарстан территориясендәге «Енисей» корпорациясе) белән күмәртәләп яки ваклап сатуны оештыру;

д) М7 индустриаль паркын (парк Татарстан Республикасында инженерлык һәм мәгълүмати чаралар белән җиһазландырылган җитештерү, складлар, офислар һәм сату-күргәзмәләр мәйданнары системасын хасил итә) үстерү;

е) Яңа технологияләр: «Махсус җиһазлар» (Ижау шәһәре), «УралНефтьСервис» (Берёзовск шәһәре), «Җитештерү җиһазлары һәм инструмент» (Чиләбе шәһәре);

ж) Дилерлык хезмәте: Татарстанда «Татхимфармпрепаратлар»

ААЖ, «Хабаровск Шәркый-региональ КАМАЗ автоүзәге» ҖЧҖ;

з) Татарстан Республикасында инвестицион проектлар: Ульяновскта «Чиста буалар» ҖЧҖ, «Yapi Merkezi» төрек төзелеш фирмасы;

и) Йөк ташу — логистика (Ульяновск, Самара, Оренбург, Төмән, Чиләбе, Казахстан);

к) Себердән күчеп кайтучылар өчен программа буенча Казан шәһәрендә һәм Татарстан Республикасында шәхси төзелеш, торак өчен җир участоклары бүлеп бирү;

л) Татарлар тупланып яшәгән урыннарда яңа эш урыннары булдыру.

6. Мәдәни һәм мәгърифәт эшчәнлеген оештыру:

а) «Татар морзалары һәм кенәзләре: тарих һәм бүгенге» исемендә Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе (Татарстан Фәннәр академиясе, Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе, Татарстан һәм Башкортстанның Татар морзалары мәҗлесе), спонсор — Ассоциация рәисе Н.Г.Саттаров. Конференциядә төрле регионнардан: Төркия, Франция, Алма-Аты, Мәскәү, Уфа, Тубыл, Түбән Новгород, Яр Чаллы һ.б. чакырылган 62 кеше катнашты. Конференция материалларын — татар морзалары тарихы буенча китаплар тәкъдим итү кичәсе уздырылды;

б) Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе каршында татар морзалары һәм дворяннарының шәҗәрәләре тарихын өйрәнү өчен галимнәр Советы төзелде. Әлеге проект хәзерге тарихи этапта татар морзалары һәм Россия дворяннары дәвамчылары арасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр урнаштыруга юнәлдерелә.

в) Төмән өлкәсе Казанлы авылының 100 еллыгын билгеләп үтү (Татарстаннан бәйрәмдә катнашу өчен артистлар: З.Хәйруллин, Р.Ильясов, З.Сәхәбиева, Р.Курамшин — җибәрү), спонсор — Н.Г.Саттаров;

г) Бөтенроссия фольклор коллективларының «Түгәрәк уен» татар фестивален Ульяновск, Төмән, Екатеринбург, Пермь, Самара шәһәрләрендә уздыру, спонсорлар — ассоциация идарәсе әгъзалары һ.б.;

д) Регионнарда Россия Ислам университетының филиалларын ачуга ярдәм итү (Төмән — Н.Саттаров, Р.Насыйров; Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районында — Э.Ганиев);

е) «Изге Болгар Җыены» кысаларында «Чикләрне белмәүче хәләл» (Болгар шәһәре) фестивален уздыру, Россия регионнарындагы татар эшмәкәрләре әзерләгән хәләл продукцияне сату һәм күргәзмә оештыру (Татарстан мөселманнарының Диния нәзарате белән берлектә);

ж) Ассоциация идарәсе әгъзалары белән бергәләп мөселман дин эшлекләренең Кулаткы укуларын уздыру;

з) Инициатив төркемнең «Ачык галәм» проектын тормышка ашыру, «Безне җиһан дәшә, җиһангирлар» китабын бастырып чыгару.

Ассоциациянең гамәлдәге проектлары:

1. Татарстанның Актаныш районындагы Милли парк кысаларында «Сәламәт милләт» проекты;
2. «Татар атлары» проекты;
3. Татар иминият компаниясе төзү;
4. Татарстан Республикасы территориясендә (Актаныш муниципаль берәмлеге) махсуслаштырылган күпмәдәниятле үсеш мәйданчыгы булдыру. ■

БЕРДӘМ МӘГЪЛҮМАТ КЫРЫНДА

ГӨЛНАЗ ШӘЙХИ,
Бөтендөнья татар конгрессының матбугат үзәге җитәкчесе

ТАТАР ДӨНЬЯСЫНДАГЫ ЯҢАЛЫКЛАР БЕЛӘН, ИНТЕРНЕТ БЕЛӘН БЕРРӘТТӘН, «ТАТАРСТАН-ЯҢА ГАСЫР» СПУТНИК ТЕЛЕВИДЕНИЕСЕ АША ДА ҺӘР КӨННЕ ТАНЫШЫП ТОРАБЫЗ. «ТНВ-ПЛАНЕТА» КАНАЛЫ ОЕШУ АЛДЫБЫЗГА КУЙГАН МАКСАТЛАРНЫ ТОРМЫШКА АШЫРЫРГА ӨСТӘМӘ МӨМКИНЛЕКЛӘР БИРДЕ.

Хәзер Татарстанны, татар телендәге тапшыруларны Россиянең барлык төбәкләрендә, Казахстан, Үзбәкстан, Украина, Эстония, Литва, Латвиядә, Азәрбайҗанда, Скандинавия илләрендә, Көнчыгыш Европада ишетергә, радио тапшыруларын интернеттан тыңларга була. Гомумән, милләт тормышындагы һәр яңалыктан халкыбыз хәбәрдар.

Россия төбәкләрендә нәшер ителә торган милли газеталар да — татар тормышының көзгесе. Алар Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты белән һәрдаим элемтәдә.

Удмуртиянең «Яңарыш» газетасы, Төмән өлкәсенең «Яңарыш», Самарадагы «Бердәмлек», Ульяновск өлкәсенең «Өмет», Пермь крае Барда районының «Таң» газеталары нәкъ менә шундыйлар. Башкарма комитет тарафыннан кабул ителгән документларны әлеге матбагаларда урнаштыра барабыз. Тагын шуны әйтәсе килә: бу газеталар — татар милли хәрәкәтенең күтәрелеш чорында аваз салган матбугат чаралары. Күбесенең егерме еллык тарихы бар. Удмуртиянең «Яңарыш», Оренбургның «Яңа Вакыт», Төмәннең «Яңарыш», Самараның «Бердәмлек», Ульяновск «Өмет» газеталарының юбилей тантаналарында Бөтендөнья татар конгрессы вәкилләре дә катнашты. Үз кыйблаларын, үз юлларын тапкан матбагалар белән беррәттән, күптән түгел генә дөнья күргән, тиз арада үз укучысын тапкан газеталарыбыз да бар. Омск шәһәрендә 2003 елдан бирле чыгып килүче «Татар дөньясы» газетасы узган ел июль аенда Россия күләмендә теркәлде. Аның оештыручысы — милләттәшебез, эшмәкәр егет Тамир Алимбаев. Чиләбе өлкәсе татарлары тормышында да милли матбугат өлкәсендә матур яңалыклар бар. Кайчандыр гел тәнкыйть утына тотылган бу өлкә хәзер мактаулылар рәтендә. Чиләбе өлкәсе Татар конгрессы тырышлыгы, Конгресс рәисе Лена Колесникованың матди ярдәме белән «Хәзинә» дигән газета нәшер ителә башлады һәм шул исемдәге телевизион тапшыру да эфирга чыкты.

Бөтендөнья татар конгрессы Баш-

карма комитеты Татарстандагы массакүләм мәгълүмат чаралары белән дә тыгыз хезмәттәшлек итә. «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» газеталары, «Сөембикә» журналы, «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе, «Казан» телерадиокомпаниясе безнең тарафтан үткәрелгән һәр чараны яктыртып, укучыларга җиткереп бара. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы, «Интертат» электрон газетасында Конгресс тарафыннан башкарылган эшләр, яңалыклар һәрвакыт урын ала.

«Татарстан — Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе белән багланышларга аеруча басым ясыйсым килә. Телевидениедәге «Татарлар», иртәнге тапшырулар редакциясенең «Манзара», «Татарстан хәбәрләре», балалар һәм яшьләр редакцияләре, «Болгар» радиосындагы «Синдер татар кешесе», «Саумы, халкым» тапшырулары һәрвакыт һәм даими Бөтендөнья татар конгрессы эшчәнлеген яктыртып, милләттәшләребезгә җиткереп бара. «Кара-каршы», «Җырлыйк әле», «Башваткыч» тапшыруларының да берничәсе чит төбәктәге галимнәр, үзешчән сәнгать осталары катнашында үтте. «Татарстан — Яңа Гасыр» телевидениесе белән тагын бер уртак проектыбыз бар. Ул — «Халкым минем» тапшыруы. Быел бергә-бергә эшләгән тапшыруыбызга алты ел тулды. Әлеге тапшырулар аша милләтебезне тагын да берләштердек, якынайттык, аралаштырдык дип әйтсәм, һич кенә дә арттыру булмас. Шушы вакыт эчендә 90 тапшыру әзерләнеп тамашачыга тәкъдим ителде. Без, Россиянең утыз ике төбәгендә, биш чит илдә, Татарстанның биш районында булып, барлыгы ике йөз мең чакрымнан артык юл узганбыз. Шушы тапшыруларда 55 кала, 151 татар авылы күрсәтелгән. «Халкым минем» тапшыруы аша 47 ансамбль чыгыш ясаган, 66 тапшыруда милли ризык әзерләү серләрен төшендергәнбез...

Бу тапшыруның популярлыгы көннән-көн арта. Бу турыда безгә килгән хатлар, телефоннан шалтыратулар сөйли. Алай гына да түгел, аның авторы Ләйсәнә Садретдинова белән яңа тапшыру әзерләргә дип Россиянең кайсы почмагына гына барып чыксак та, безне күптән көткән, туганнарыдай каршы алалар, әлеге тапшыру аша Россиянең башка төбәкләрендәге милләттәшләребез тормышы, яшәеше белән танышабыз, диләр, рәхмәт әйтәләр.

2010 елда Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының үз матбугат органы — «Халкым минем» газетасы барлыкка килде. Ул республика «Татмедиа» мәгълүмат агентлыгы белән бергә нәшер ителә. Газета Татарстан һәм Россия күләмендә теркәлү узып, Федераль күләмдә тарала торган татар газетасы булыр дип өметләнәбез.

Бүгенге көндә иң тиз аралашу, хәбәрләшү чарасы — интернет. Газета, телевидение булмаган җирләрдә дә интернет-сайтлар эшли башлады. Халкыбыз тормышындагы вакыйгаларны яктыртып баручы сайтлар 550дән артык дип исәпләнә. Алар арасында шәхси сайтлар да бар. Милли тормышыбыздагы вакыйгалар белән һәркөнне танышып торасыгыз килсә, www.tatar-congress.org адресына кереп карый аласыз. Тиздән, Бөтендөнья татар конгрессының V съезды барган көннәрдә, тагын бер зур проект — «Татар иле» мәгълүмати-ресурслы татар социаль челтәрен тәкъдим итү булачак. Бу инде — халкыбызга кагылышлы барлык мәгълүматны бергә туплаган, сайтларны берләштергән, зур һәм кыйммәтле чыганак булачак.

Күргәнегезчә, башкарган эшләр дә бар, башкарасылары да җитәрлек. Авырлыклар да күп. Җиңел түгел, әмма чишү юллары бар! Бергәләп, җиң сызганып тотынганда, аларны, һичшиксез, җиңәрбез! ■

ТАТАР ИДЕЯСЕ

РАФАЭЛЬ МӨХӘММӘТДИНОВ,
тарих фәннәре кандидаты,
Ш.Мәрҗани исемендәге
Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре

ХӘЗЕРГЕ ГЛОБАЛЬЛӘШЕП БАРГАН ДӨНЬЯДА ҮЗ-ҮЗЕН САКЛАП КАЛЫРГА ТЫРЫШКАН ҺӘР МИЛЛӘТНЕҢ НИНДИДЕР ҮЗ МИЛЛИ ИДЕЯСЕ БУЛЫРГА ТИЕШ.

Мәсәлән, русларның, алар тарафыннан бөтен дөньяны рухи яктан коткарырга дәгъва итүче «Рус идеясе» бар. Ул идея Ф.Достоевский тарафыннан уйлап чыгарылган һәм менә шундый фикерләрдән гыйбарәт иде: материаль яктан ярлы Россия киләчәктә үз рухилыгы белән череп барган Европа цивилизациясен коткарып калырга тиеш иде. Рус халкы, үз йөрәгендә Раббыны саклаучы һәм христиан динен башкаларга таратучы буларак, башка халыклар белән берләшеп бөтендөнья күләмендә гадел бер җәмгыять төзергә тиеш иде.

Төрекләрнең төп идеясе — Төркияне бәйсез, көчле һәм көнчыгыш халыклары арасында тәэсирле бер дәүләт итеп төзү иде. Бу идеяне тормышка ашырыр өчен, кәмалчелек (кәмализм) идеологиясе кулланылган. Кәмалчелек исә Кәмал Ататөрек күзлегеннән аңлатылган төрек милләтчелегенең һәм теләктәшлегенең (солидаризмының) катнашмасыннан барлыкка килгән бер доктрина иде. Хәзер дә бу идеология Төркия Конституциясенең нигезе булып тора.

Яһүдләрнең идеясе — Израиль ярдәмендә бөтен еврейларны рухи яктан берләштерү һәм шуның аркасында дөньяга тәэсир итү (Библиядә яһүдләр бөтендөнья халыкларына укытучы булырга тиеш һәм алар Раббы (Бог) тарафыннан сайланган халык, дип язылган). Израильнең конституциясе булмаса да, бу эштә аларга Тәүратка һәм Талмудка нигезләнгән борынгы милли традицияләре ярдәм итә.

Англосаксларның (инглизләрнең һәм американлыларның) идеясе — үз илләрендә кеше хокукларын һәм демократияне саклау һәм ныгыту, шул

өлкәдә бөтендөнья өчен үрнәк булып, бу кыйммәтләрне башка халыкларга тәкъдим итү.

Англиянең дә Конституциясе юк, ләкин аларда тарихи демократия традицияләре бик борынгыдан килә һәм алар, шулар нигезендә тәрбияләнеп, яхшы гына яшәп киләләр. Шул уңайдан бөтен дөньяга мәшһүр «Инглиз холкын (характерын)» гына искә төшерергә мөмкин.

Минемчә, менә бу ике борынгы милли традициягә (яһүди һәм инглиз традицияләренә) нигезләнеп, хәзерге вакытта АКШ дөньяның иң көчле дәүләтенә әйләнде.

Русларның, инглизләрнеке кебек, тарихи демократия традицияләре юк. Шуңа күрә дә «совет халкы» һәм Советлар Союзы дигән нәрсәләр тиз арада юкка чыкты.

Ә татарның милли идеясе бармы? Уйлавымча, татарның төп идеясе ул — милли азатлык идеясе.

Милли азатлыкка һәр халык үз дәүләтен төземичә дә, чын федерация (Швейцария кебек) тәшкилендә (составында) да, ирешә ала. Ләкин унитар дәүләт яки ялган федерация тәшкилендә аңа ирешеп булмый.

Киләчәктә татар идеясен тормышка ашыруда милләтебез нык һәм бердәм булырга тиеш. Шуны башкарыр өчен милли идеологиябез кирәк.

Идеология нинди булырга тиеш соң? Әүвәл татарның тарихына күз салу мөһим.

Ш.Мәрҗанигә кадәр (XIX гасыр уртасы) татарның колониализмга каршы көрәше дини азатлык идеясе нигезендә алып барылган. Россия шартларында ул чордагы мөселманның лозунгы:

«1. Кадими (ортодоксаль) исламга таянып яшәү;

2. Хатын-кызларны укытмау;

3. Европа цивилизациясе казанышларын (төгәлрәк әйткәндә, рус культурасы казанышларын) үзләштермәү һәм рус телен өйрәнмәү» була.

Татарны көчләп чукындыру сәясәтенә каршы көрәштә мондый рухи юнәлеш шул заман шартларында уңай йогынты ясаган. Ә инде XIX гасырның икенче яртысында, Россиядә буржуаз мөнәсәбәтләр киңәйгән чорда, татар буржуазиясе рус капиталистлары белән ярыша алырлык хәлдә булыр өчен, яңа идеологиягә ихтыяҗ туа.

Нәкъ шушы вакытта Ш.Мәрҗани өч яңа идея тәкъдим итә:

1. Иске догмалардан арынган һәм яңача аңлатылган исламга таяну.

2. Татар телен һәм тарихын өйрәнү һәм үз-үзеңне татар итеп тану.

3. Европа казанышларын үзләштерү һәм рус телен өйрәнү.

Бу карашны бөек галимнең түбәндәге сүзләре дәлилли: «Дөньядагы төрле телләрне белергә, белем тупларга ислам дине каршы түгел… Фәкать иң элек исламны яхшы аңларга, иманны ныгытырга кирәк. Иман нык булса, русча уку гына зарар итмәс. Мөселманча (татарча) белмичә, русча укып калу ярый торган эш түгел».

Кыскача итеп әйткәндә, Ш.Мәрҗани исламлашу (исламчылык), татарлашу (татарчылык), заманчалашу (заманчалык, модернизация, ягъни дөнья цивилизациясе казанышларын үзләштерү) дигән өч элементтан (яки принциптан) торган яңа идеологик система тәкъдим итә. Аны кыскача идеологик өчлек дип тә атарга була.

Ш.Мәрҗанинең татарларны руслар белән ярыша алырлык, заманча бер халык итеп күрәсе килгән. Минемчә, заманча булу — ул, үз заманыңнан артта калмыйча, алга китү һәм берьюлы үз милли йөзеңне дә саклап калу дигән сүз. Моның ачык мисалы — япун милләте.

Соңрак Ш.Мәрҗани тәкъдим ит-

кән идеологик «өчлек»не башка төрки галимнәр һәм сәясәтчеләр дә күтәрә башлый.

Мәсәлән, шул ук өч элементтан торган идея турында 1905 елда «Хәят» гәзетасында азәрбайҗан галиме Хөсәен Али болай дип яза: «Без, төркиләр, исламга инанырга, төрки тойгылар белән рухланырга һәм Европа цивилизациясе җимешләрен үзләштерергә тиешбез».

Аның бу мәкаләсенең исеме дә «Төркиләшү, исламлашу һәм аурупалашу» дип атала.

1923 елда төрек социологы Зыя Гөкалп, шушы өч принципка таянып, «Төркичелекнең нигезләре» дигән китап яза.

Кәмал Ататөрек, шул китапның эчтәлеген үз фикерләре белән баетып, кәмализм идеологиясен иҗат итә. Ләкин ул әлеге идеологик өчлекнең исламчылык принцибына бик каты чикләр куя һәм өчлек икелеккә генә кайтып кала (төркичелек һәм заманчалык принциплары гына кала).

XXI гасыр башында Рәҗәп Әрдоган хөкүмәте исламчылык принцибы идеологиясенә яңадан мөрәҗәгать итә: «икелек» «өчлек»кә әйләнә.

Мин бу «өчлек» системасын бик дөрес дип табам, чөнки аның фәлсәфи бер нигезе бар. Барлыкның (бытие) бөтен матди һәм рухи әйберләре бу принципка нигезләнә. Мәсәлән, физикада — су «сыекча, боз һәм бу» рәвешендә була. Геометриядә һәр аралыкның (пространствоның) озынлыгы, киңлеге һәм биеклеге бар. Философиядә — тезис, антитезис, синтез. Җәмгыятьтә — хасса (затлылар, элита), урта сыйныф һәм гавам (халык массасы).

Хәзер инде яңадан татар мохитенә кайтыйк. 1917-1918 елларда татар идеясе халкыбызның милли-мәдәни автономия рәвешендә Россиядә төзелүе күздә тотылган чын Федерация структурасына керү иде. Ләкин большевиклар хакимиятне яулап алгач, бу планнар чәлпәрәмә килде.

Аннары, XX гасырның 20 нче елларында татар коммунистлары «милли коммунизм» байрагы астында большевистик режимның кысаларында ниндидер, чикләнгән булса да, милли азатлыкка ирешергә теләгәннәр иде. Ләкин Мәскәү 1930 елда бу юлны да япты.

Хәзерге заман татарлары белән чагыштырганда, Ш.Мәрҗани һәм Г.Тукай чорында яшәгән татарлар күпкә ныграк һәм бердәмрәк иде. Аларның бер теле (рус телле татарлар юк дәрәҗәсендә иде), бер дине (атеистлар бик аз иде) булган. Социаль планда да татарлар бердәмрәк иде, чөнки аларның байлары халыкның мәгариф, дин, хәйрия вакыфлары (фондлар) кебек институтларын тәэмин итәр өчен, үз акчаларын сарыф кылганнар.

Хәзерге чор татарына караганда, Совет илендә яшәгән татар да бердәмрәк иде. Телдә бердәмлек әле саклана иде. Мәсәлән, 1953 елда Татарстанда бөтен татар балаларының 95%ы татар мәктәпләрендә укыган. Ислам дине урынына халыкны коммунистик идеология укмаштырып тора, кешеләрнең эш хаклары берберсеннән нык аерылмый торган чор иде.

Шуңа күрә 1990 елда, коммунизм идеясен милли-азатлык идеясе алмаштыргач, социаль яктан бердәм татар халкы суверенитетка ирешә. Чөнки хасса һәм халык бердәм иде. Ул елларда идеологик «өчлек»нең фәкать ике принцибы («икелек») — татарчылык һәм заманчалык эшләде. Исламчылык читтә калды.

Шунысын да ассызыклап әйтү

мөһим: татар җәмгыятендә капитализм чоры башлануга милли рух белән сугарылмаган компрадор буржуазия, хасса барлыкка килә, һәм бу социаль катлам халыктан ерагая бара. Бер үк вакытта Мәскәүнең басымы көчәя. Шушы факторлар аркасында милләтнең бердәмлеге какшый һәм без суверенитетны югалтабыз.

Хәзерге татар иҗтимагый тормышында идеологик «өчлек»нең ике принцибына — заманчалык һәм исламчылыкка өстенлек бирелә. Татарчылыкка яки милләтчелеккә килгәндә, бу тармак Мәскәү тарафыннан бик нык чикләнә, чөнки ул, кагыйдә буларак, бәйсез дәүләт идеясе белән тыгыз бәйле.

Бүгенге милләтебез нык таркау хәлдә, чөнки, беренчедән, социаль планда ул череп баеганнарга һәм ярлыларга бүленә, икенчедән, аралашу өлкәсендә татар телле һәм рус телле татарлар барлыкка килде, өченчедән, дин өлкәсендә, бер яктан — мәчеткә йөрүче мөселманнар, икенче яктан, дөньяви зыялылар бар (мөселманнарның үз арасында да бүленеш бара), дүртенчедән, татар милләтен төрле этник төркемнәргә бүлергә тырышучылар да юк түгел.

Бу таркаулыкны бетерүдә, минемчә, әлеге «өчлек»кә, ягъни татарчылыкка, исламчылыкка һәм заманчалыкка нигезләнгән идеология төп роль уйнаячак. Бу өч принцип һәр татарның йөрәгендә бер-берсенә сыенып яшәргә тиеш. Бер принципка гына таянып, без бернәрсә дә эшли алмаячакбыз.

Мәсәлән, татарчылык принцибына нигезләнеп, татар мәктәпләре, булачак Татар университеты, мәдәният учреждениеләре һәм, гомумән, бөтен дәүләт аппараты эшләргә тиеш булачак. Шул ук принцип безгә тел өлкәсендә таркаулыкны һәм руслашуны туктатырга ярдәм итәр иде. Шуның белән без татар телен теориядә генә түгел, ә гамәлдә дә дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрер идек.

Хәзерге Россия шартларында тел мәсьәләсе — сәяси проблема. Россиягә татарның көчле һәм югары мәдәнияте кирәкми, дип раслыйм. Башкача булса, бердәм дәүләт имтиханын татарча бирүне тыймаслар иде.

Кайбер яшьләрнең радикаль исламга китү сәбәпләренең берсе, минемчә, җөмһүриятебездә татарчылык юнәлешен тиешле дәрәҗәдә үстермәүдән килә. Әйтик, бөтенләй татар телен, мәдәниятен белмәгән татар егете үзен чын татар итеп хис итә алмый. Ул үзен рус дип тә санамый, ләкин аңа үз-үзен барыбер ничек тә булса билгеләргә кирәк, нәтиҗәдә, яшь кеше үзен мөселман дип саный башлый. Мондый руслашкан татарларның шактые татар теленә, традицияләренә игътибар бирмәгән радикаль ислам төркемнәренә тартыла. Шуңа күрә Татарстанда татар телен, рухын һәм мохитен яңа баскычка күтәрергә кирәк. Сүз «югары татар культурасы»н булдыру турында бара.

Хәзерге заман яшьләренең күпчелеге мәгълүматны телевидение аша һәм интернеттагы электрон газеталардан ала. Алар татар тапшыруларын безнең телевидение рус телевидениесе белән ярыша алырлык дәрәҗәдә булган очракта гына караячак. Нишләп безгә телевидениедә җитди һәм аналитик тапшырулар оештырып, аларга тирән һәм оригиналь фикерләүче галимнәрне чакырмаска? Андый белгечләр Мәскәүдә генә түгел, бездә дә бар.

Татар телевидениесенең тематикасын һәм сыйфатын күтәрмичә, аңа яшьләрне җәлеп итү мөмкин түгел.

Бу аяныч хәл татар теленең кулланыш даирәсен тарайта. Бездә сәясәт, икътисад, хакимият кебек темалар телевидениедә юк, күбрәк «тамаша» күрсәтәләр. Чөнки түрәләребез «без сәясәт белән шөгыльләнмибез, өстенлекне икътисадка бирәбез», дигән фикерне халыкка сеңдерергә тырыша. Җитәкчеләребез сәясәтне инкарь итсәләр дә, ул үзе безнең ишеккә терактлар белән шакый, ә без һаман: «Без сәясәтчеләр түгел!» — дип сөйләнәбез.

Кайбер кешеләр: «Балабызга татар теле кирәкми, чөнки аның белән югары белем алып булмый, акча эшләп, карьера ясап та булмый», — дип әйтәләр. Минемчә, дуңгызның да ашарына бар, аны түбәсеннән су акмый торган җылы фермада тоталар. Ләкин ул үз табагына борыны белән төртелеп ашаганда, күктәге йолдызларны күрә алмый, чөнки ул — дуңгыз. Ләкин без бит кешеләр, «йолдызга мохтаҗ кешеләр»!..

Рус мәктәбендәге рус балаларына караганда, татарча укыган укучыларыбызга уку йөге зуррак һәм авыррак булыр, ләкин белемнәре дә киңрәк булыр, дигән фикер белән мин килешәм.

Безгә, татарларга, бер генә юл кала: татар мәктәпләрендә укып та, рус телен русларның үзләреннән ким белмәскә.

Бу уңайдан карьера турында шунысын әйтәсем килә: Беренче Президентыбыз М.Шәймиев һәм хәзерге Президентыбыз Р.Миңнеханов та татар урта мәктәбен бетергән кешеләр һәм алар менә дигән карьера ясаганнар. Хикмәт бәлки баланы фәкать рус мәктәбендә укытуда түгел, башка нәрсәдәдер?

Татар теле мәсьәләсен дәүләткә генә аударып калдыру ярый торган эш түгел. Бу эшкә һәрберебез катнашырга тиеш. Шундый кайбер чаралардан түбәндәгеләрне тәкъдим итәсем килә: гаиләдә татарча гына сөйләшү, руслар арасында да татар кешесе белән туган телдә сөйләшү, катнаш никахларга каршы булу, базарда-кибеттә татарча сөйләшкән сатучыга өстенлек бирү, татар эшмәкәренең фирмасына эшкә күбрәк татарны алу һәм эшне татарча алып бару, бай татарларга торакларны бер тирәдәрәк сатып алу һәм шул тирәне татар кварталына әйләндерү — бу татар бакчаларын, мәктәпләрен, мәчетләрен оештыру эшен җиңеләйтер.

Татар теле ешрак эштән соң, ял вакытларында уздырылган чараларда яңгырый, шуңа күрә татарга күбрәк аралашырга, иҗтимагый эшләрдә активрак булырга кирәк. Балаларны да андый чараларга алып бару мәслихәт, алар, рус мәктәбендә укып, рухлары белән ата-аналардан аерылмасыннар иде.

Исламчылык принцибына килсәк, аның нигезендә татар милләтен ныгытучы ислам юнәлешен тарату һәм мөселман интеллигенциясенең киң социаль катламын булдыру мөмкин.

Мөселман интеллигенциясе булмыйча, «югары» ислам да барлыкка килмәс. Хәзерге зыялыларның күпчелеге формаль мөселманнар гына. Алар бөтен нәрсәне рациональ фикерләү аша гына аңларга өйрәнгән, исламга да карашлары шундыйрак. Шуңа күрә аларны дингә тарту өчен, Ислам аша гыйбадәткә генә түгел, ә фән, логика һәм фәлсәфәгә дә бору кирәк.

Практик яктан бу мәсьәләне хәл итәр өчен, мәчетләр янында мөселман мәдәни үзәкләре эшләргә тиеш. Анда татар һәм чит телләре өйрәнү курслары, ислам фәлсәфәсе, мәдәнияте һәм сәнгате буенча лекторийлар, төрле

түгәрәкләр эшләргә тиеш. Биредә конференц-зал, спортзал, бассейн һәм кафе да артык булмас иде. Мондый мәдәни үзәккә намазга басмаган кешеләр йөри башлап, алар әкренләп намазга да басарлар. Шулай итеп, интеллигенциябезне мөселманнар белән бераз берләштерер идек.

Икенче мәсьәлә — ул традицион һәм радикаль исламның каршылыгы.

Әйтик, ваһһабилектә яшь мөселман Коръәнне һәм төп хәдисләрне өйрәнә дә алар нигезендә бөтен нәрсә турында үз хөкемен чыгара ала, хәтта Мөхәммәд пәйгамбәр турында да. Аның өчен беркем дә авторитет түгел, хәтта мөфти дә. Яшь кеше өчен нинди чиксез ирек һәм мөстәкыйльлек! Менә шул нәрсәләр яшьләрне радикаль исламга тарта да инде.

Исламны фәлсәфә аша аңларга тырышу омтылышым минем «Милли идеология һәм дин», «Почему нет мусульманской интеллигенции?» дигән мәкаләләремдә чагылыш тапкан. Аларны интернеттан укып була.

Ә традицион исламда хәлләр ничек тора? Анда яшь мөселман үз мөстәкыйль фикерен әйтер алдыннан, Коръәннән башка бер абруйлы мөселман фикерен, аннары — имамның, аннары — мөфтинең, аннары — ТР Президенты каршында эшләүче диннәр буенча киңәшчесенең — МВД һәм ФСБ фикерләрен өйрәнергә мәҗбүр. Традицион исламның «вертикале» менә шушындый яшь мөселманны ирекле фикерләүдән мәхрүм итә.

Мөфтиләребез чиновникларга әйләнеп баралар. Хәтта МВД белән хезмәттәшлекләрен газеталарда рекламалаштыралар. Ә бу күренеш аларга яшьләр арасында популярлык өстәми.

Әлбәттә, мин җәмгыятебездә иминлек һәм кануннарны үтәү тарафдарымын, ләкин һәрнәрсәнең чамасы булырга тиеш. Безнең илдә теоретик планда булса да дин дәүләттән аерылган. Ә гореф-гадәт белән бәйле булган ислам (традицион ислам) дәүләт басымы астына эләккән. Традицион ислам иреккә, мөстәкыйльлеккә сусап ята, ул ирекле булмаса, исламның башка агымнарына тәгаен оттырачак.

Радикаль ислам тарафдарлары, нигездә, ярлы, белеме аз булган социаль катлам вәкилләре. Радикаллар (фундаменталистлар) исламнан фәлсәфәне, фәнне, сәнгатьне һәм мистиканы, ягъни теологиядән тыш бөтен нәрсәне алып ташлыйлар. Шулай итеп, исламның бөтен төрлелеге, бөтен байлыгы һәм Коръәннең төп идеяләре (яшәеш кануннарын өйрәнү, игелекле эшләр башкару һәм гадел җәмгыять төзү) онытыла.

Ә бит урта гасырлардагы гарәп-мөселман цивилизациясенең рухы бу цивилизацияне тәшкил иткән культураларның, диннәрнең һәм этносларның төрлелегеннән гыйбарәт иде.

Минемчә, мөселман илләренең артта калуы да аларда культураның һәм фәннең түбән дәрәҗәдә булуы белән бәйле. Алар, бәйсезлек алып та, беренчел исламның рухилыгыннан, аның хөр фикереннән файдалана алмаганнар. Шуңа күрә аларның дәүләт структуралары я дөньяви милләтчелекнең тупас диктатурасы, яисә бик тар кысаларда аңлатылган теология (клерикализм) нигезендә төзелә иде. Хәзер инде диктатура да һәм тар теология дә үз потенциалларын тулысынча югалткан.

Хәзер гарәпләр алдында ике юл: беренчел ренессанс исламның рухына кайту яисә Европа юлыннан китү.

Күптән түгел булган гарәп

революцияләре гарәпләрнең шул бөек борылыш чатында торуын раслый.

Бездә, татарда, андый проблема бармы? Минемчә, юк, чөнки татар милләте ул борылышны инде Ш.Мәрҗани заманында ук (XIX гасырның урталарында) ясый башлаган. Милләтебез өч принципка таянган идеология буенча алга бара һәм гарәпләрдәге кебек чиктән-чиккә сикерергә ихтыяҗ юк.

Шулай итеп, татар исламында өч юнәлеш шәрехләнә: 1) рациональ фикер йөртүче зыялы мөселманнар; 2) традицион хәнәфи мөселманнар; 3) радикаль мөселманнар. Традицион мөселманнарга фикерләүдә мөстәкыйльлек, ә радикаль мөселманнарга исламның бай мирасын белү һәм исламга интеллект күзлегеннән бәя бирү җитми. Ләкин бу өч юнәлештә фикер йөрткән мөселманнар үзләрен бердәм татар милләте вәкилләре итеп тоеп, аларның фикер төрлелеге һәм бәхәсләре милләткә зыян китермәсә, менә шундый исламчылыкны һәм исламны татар исламы итеп атарга була, һәм шундый исламчылык безгә кирәк тә.

Заманчалык (модернизация) дигәндә, мин Д.Медведев кебек, алдынгы фән (Сколково), техника һәм технологияләрне генә күздә тотмыйм. Минемчә, заманчалык принцибының күпкә мөһимрәк ягы бар. Бу принцип нигезендә урта сыйныфны зур социаль катлам итеп үстерү һәм шуның нигезендә татар милләтенең социаль бердәмлеген булдыру мөмкин. Ә күпсанлы урта сыйныф вәкилләре барлыкка килү белән, хәзерге вәхши капитализм социаль капитализмга әйләнә башлаячак. Мәгълүм булганча, кешелек тарихында урта сыйныф бөтен илләрдә дә иң милләтче сыйныф булып саналган.

Бу өч принципны чынбарлыкта гамәлгә кертеп буламы дигән сорау туарга мөмкин. Минемчә, бу идеологик «өчлек» нигезендә «татар җыеннары» системасын төзеп була. Әлеге җыеннар татар халкының милли-мәдәни һәм кайбер социаль проблемаларын хәл итә алыр иде. Һәр җыенның башында өч инициатив һәм абруйлы кеше торырга тиеш. Алар халык тарафыннан сайлана. Татарчылык юнәлешен — укытучы яки галим, исламчылык юнәлешен — мулла яки исламны белгән кеше, заманчалык юнәлешен эшмәкәр алып барырга тиеш.

Бу иҗтимагый оешмалар БТК һәм дәүләт органнары белән дә элемтәдә торырга мөмкин, ләкин аның җитәкчеләре дәүләт органнарының курчакларына әйләнергә тиеш түгел, югыйсә, бу идеянең тамырына балта чабу булыр иде.

Менә шундый җыеннар татарның тормышында милли гражданлык җәмгыятен һәм демократияне үстерү өчен мөһим нигез булып тора ала.

Йомгак ясап, шуны әйтәсем килә: әлеге өч принциптан торган идеология хәзерге татар милләте өчен иң оптималь булыр дип уйлыйм. Татар халкын укмаштыра торган анык һәм җыйнак идеологик тәгълимат кирәк. Иманым камил, без бөтенебез дә шул туры һәм дөрес юлдан барсак кына, татар идеясен, һичшиксез, тормышка ашырачакбыз.

(Җыен турында тагын да җентекле мәгълүмат алу өчен, интернетта «Татарская община как выход из тупика» дигән мәкаләмне укыгыз). ■

КАЗАН

НАИЛӘ МИҢНЕХАНОВА

Бакыр хәрефләрен укып узам,
Күз алдымда хыялдагы Казан.
Аяк басам изге җиренә,
Милләтемнең Гыйлем иленә.
Айга тәүге баскан адәм кеби,
Күңелемне азан моңы били.
Саумы, Казан, ун гасырлы Галәм!
Җир йөзенә терәп башым иям.
Тукай җырлаңган көн, тыным кысан.
Күчәрендә зыр әйләнә дастан.
Милләтемнең кара болыт күге.
Гомумтатар корылтае бүген.
Җиде саны күккә күтәрелгән,
Корылтайның айлы әләменнән
Күкрәк горурлыктан киерелгән,
Җиде күк катына күтәрелгән.
Дисбе йомарлаган кайнар учым.
Сөембикә манарасын кочам.
Ил язмышын күтәрердәй гамьле,
Саумы, Казан, мөстәкыйльлек Иле!

ТӘБРИЗ ЯРУЛЛИН,
Бөтендөнья татар яшьләре җыены Башкарма бюросы рәисе

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ФОРУМЫ: ЯҢА БУЫН АВАЗ САЛА!

ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ГАСЫРЛАР БУЕ ТУПЛАНЫП КИЛГӘН РУХИ ҺӘМ МӘДӘНИ КЫЙММӘТЛӘРЕН ҮЗЕНӘ СЕҢДЕРЕП, МИЛЛӘТНЕҢ ҮСЕШЕНДӘ БУЫННАР ДӘВАМЧЫЛЫГЫН БУЛДЫРУЧЫ ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ БЕЛӘН МАКСАТЧАН ЭШЛӘҮ, БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ АЕРЫЛГЫСЫЗ БЕР ӨЛЕШЕ БУЛЫП ТОРА.

БТКның бу өлкәдә тормышка ашырылган төп проекты — 2004 елда нигез салынган «Бөтендөнья татар яшьләре форумы» иҗтимагый оешмасы (Россия Федерациясе юстиция министрлыгының Татарстан Республикасындагы Идарәсендә 2012 елның 5 маенда, 1121600002369 дәүләт номеры астында теркәлгән), һәм татар яшьләренең форумнарын (җыеннарын) уздыру булып тора.

БТЯФ Уставы буенча, бу халыкара оешманың форумы (җыены) ике елга бер мәртәбә уздырыла. Милли кыйммәтләрне саклап калу юлларын эзләү, яшь буынны туган телен, халкыбызның тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүенә этәрү, татар милләтенең алга таба үсеш юнәлешләрен билгеләү, форумның төп максатлары булып тора.

Форумнарны оештыручы — БТКы, Халыкара иҗтимагый оешмалар берлеге БК һәм Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы.

Форум делегатлары 14тән алып 35 яшькә кадәр була ала, алар Россия Федерациясе һәм чит илләрдәге татар милли-мәдәни оешмаларыннан яисә яшьләрнең мөстәкыйль оешмаларыннан (андыйлар булган очракта) сайлана. Россия төбәкләреннән һәм чит илләрдән килгән яшьләрнең күпчелеге туган телендә иң гади гыйбарәләр ярдәмендә генә аралаша ала, әдәби телне белүчеләр аз санда. Кагыйдә буларак, делегатлар төп эш урыннарында хезмәт куюдан тыш, иҗтимагый эшчәнлек белән татар оешмаларында шөгыльләнәләр.

Форум барган берничә көн эчендә аның җитәкче органы сайлана, ул БТЯФның Координацион Советыннан (IV форумга кадәр — Бюро) һәм рәисеннән тора. Форумда татар яшьләренең алдагы елларга максатлары һәм бурычларын билгеләгән резолюция кабул ителә. Координацион Советы — БТЯФның даими эшли торган җитәкче органы, ул 42 активисттан һәм яшьләр оешмалары лидерларыннан гыйбарәт.

Беренче форум 2004 елның 24-28 июнь көннәрендә узды, Татарстаннан, Россия Федерациясе төбәкләреннән һәм чит илләрдән делегатларны җыйды, барлыгы 16 илне колачлады. Татар яшьләренең II Бөтендөнья форумы 2006 елның 21-25 июнендә узды, анда 20 илдән 580 делегат катнашты. 2008 елның 26-31 августында узган III форум 22 илдән 461 делегатны җыйды. IV форум 2010 елның 27-31 август көннәрендә үтте һәм анда 24 илдән 550 делегат катнашты.

Узган форумнарның дүртесе дә татар яшьләренең берләшүенә һәм яшь буында милли үзаң формалашуга сизелерлек өлеш кертте. Форумнар югары интеллектуаль һәм оештыру дәрәҗәсендә уздылар, Россия Федерациясе һәм чит илләрдәге татар яшьләре милли оешмаларының эшчәнлеген җанландырып җибәрделәр.

Бу көндә форум бөтен дөньядагы татар яшьләренең йөздән артык иҗтимагый, дини һәм мәдәни оеш-

масын берләштерә һәм координацияли. БТЯФ ярдәме белән татар яшьләренең дистәләрчә яңа оешмасы барлыкка килде: Мәскәү шәһәре һәм Мәскәү өлкәсендә, Оренбург, Свердловск, Иваново, Иркутск, Новосибирск, Ульяновск, Чиләбе, Әстерхан өлкәләрендә, Чувашстан һәм Адыгея республикаларында, Украина һәм Казахстанда, Балтыйк буе илләрендә, Алмания, Бөекбритания һәм башка регионнарда, шул исәптән башка илләрдә яшь татарлар берләште.

БТЯФның игътибар үзәгендә – татар милләтенең яшь буынында милли үзаң тәрбияләү, татар телен, халкыбызның милли мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклап калу. Бу максатка ирешү өчен БТЯФ күпсанлы чаралар оештыра, алар арасында – «Мин татарча сөйләшәм!» халыкара акциясе, «Автохәрәкәт», «Татар-дозор», «Чәк-чәк party», «Интернет татарча сөйләшә», төрле фестивальләр, яшь татарларны борчыган актуаль темаларга конференция, түгәрәк өстәл, семинарлар. Бу чараларның күпчелеге халыкара статус алды, чөнки алар Казандагы һәм Татарстандагы яшьләрдә генә түгел, Россия төбәкләрендәге һәм чит илләрдәге татар оешмалары активында да кызыксыну уятты. Алай гына да түгел, бу иҗтимагый технологияләр Россиядә яшәүче башка халыклар (башкорт, мари) вәкилләре ягыннан да хуплау тапты.

Шунысы игътибарга лаек: татар яшьләре өлкән буын татарлар кебек үк бүгенге Татарстан Республикасын үзләренең тарихи һәм мәдәни мәркәзе дип саный һәм милли-мәдәни мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүдә чыганак итеп нәкъ менә Татарстанны атый, үз җирлекләрендә Татарстан абруен ныгыту өстендә эшли.

Бөтендөнья татар яшьләре форумнарында катнашучылар – милли хәрәкәткә 1900-2000 елларда килгән төрле илләрдәге һәм төбәкләрдәге татар милли лидерларының лаеклы алмашчылары булып тора. Бүгенге татар яшьләре, Татарстаннан читтә яшәп тә, милли идея һәм идеалларга тугрылык саклый, милли үзенчәлекләрне югалт-

маска омтыла. Делегатлар милләтнең бүгенге торышы һәм киләчәге өчен үзләрендә зур җаваплылык тоялар һәм бу процесста үз урыннарын, алларындагы бурычны яхшы аңлыйлар. Форум барган берничә көн эчендә алар яңа идеяләр белән рухланалар һәм үзләренә кайткач, ул идеяләрне яңа көч белән тормышка ашыралар.

Чираттагы, V форум Казанда, 2012 елның 27-31 август көннәрендә узды. Анда 30 илдән 800дән артык делегат катнашты.

V Бөтендөнья татар яшьләре форумы программасы кысаларында пленар утырыш узды, делегатлар 4 секциягә бүленеп эшләде («Татар яшьләре һәм Web 2.0», «Татар халкының тарихи мирасы: милләтне саклап калу юллары», «Бүгенге татар яшьләренең рухи кыйммәтләре» һәм «Милли мәгариф һәм татар телен өйрәтүдә һәм саклап калуда яңа технологияләр»). Моннан кала, форум кысаларында «Татар иле» интернет социаль челтәрен тәкъдим итү, «Милли татар бренды: формасы һәм эчтәлеге» темасына фикер алышу, Казан Кремле, Иске Татар бистәсе буйлап Универсиада-2013 объектларына сәяхәт, концертлар һәм башка күңел ачу программалары оештырылды.

2012 ел — Бөтендөнья татар яшьләре форумы эшчәнлегендә кызыклы һәм әһәмиятле вакыйгалар белән истә калачак. Аларның күпчелеге татар халкы тарихында беренче тапкыр узуы белән мөһим һәм кадерле. Европада беренче тапкыр Европа татар яшьләре форумы җыелу, Литва татар яшьләре лидерларының тәүге корылтае, Лондонда беренче мәртәбә узган Сабан туе — болар барысы да милләтебез елъязмасында үзенең лаеклы урынын алалачак.

Уйлап карасаң, татар яшьләре тормышының шулай җанлануы буш урында барлыкка килмәде. Бу вакыйгаларны сигез ел элек, 2004 елның җәендә Казанда Бөтендөнья татар яшьләре форумы оешуның күтеп алынган нәтиҗәләре, дияргә нигез бар. Беренче форумда ук оешманың төп бурычы билгеләнде: төрле илләрдә һәм Россиянең күп шәһәрләрендә эшләп килүче татар яшьләре оешмаларын берләштерү, аларның эшчәнлегенә, үзара аралашуларына, хезмәттәшлек итүләренә ярдәм күрсәтү. Башлангыч этапларда форум нәкъ менә шулар белән шөгыльләнде. Аннары форум татар яшьләр оешмаларына кызыклы проектларын тормышка ашырырга ярдәм итте. Соңгы елларда төбәкләрдә татар яшьләре торган саен мөстәкыйльрәк була бара, хәзер инде алар үз җирлекләрендә чаралар уздыру гына түгел, тәҗрибәләрен башкаларга да җиткерә алалар.

Тарихи вакыйгалар чылбыры ерак Байкалда башланып китте. Монда 17-19 февраль көннәрендә Себер төбәге татар яшьләр оешмалары активистлары очрашты. Чараны «TATZIMA-2012» проекты кысаларында, Иркутск төбәгенең «Байкал дулкыны» татар-башкорт яшьләр үзәге иҗтимагый оешмасы башкарып чыкты. Очрашуга Новосибирск, Кемерово, Улан-Удэ, Иркутск һәм Казаннан яшьләр җыелды.

«Үзара киңәшләшү, төбәкләрдә тупланган тәҗрибәне уртаклашу өчен бер мәйдан кирәк, шулвакытта гына татар оешмалары тагын да нәтиҗәлерәк эшли алачак, — дип саный «Байкал дулкыны» үзәге җитәкчесе Ринат Кәримов. — Безгә берләшү мөһим, уртак максатларны билгеләп, төбәкара проектларны тормышка ашырырга кирәк. Беренче этапта якын-тирә төбәкләрне бергә тупларга җыенабыз», — дип, алга куелган максатлары белән уртаклашты чараны оештыручылар.

Очрашуның беренче нәтиҗәләре күзгә күренә дә инде. Берничә кызыклы проектка нигез салынды, шулар арасында — Байкалда төбәкара татар балалар лагере проекты. Тулысынча

әзерләнеп беткәннән соң, аны Иркутскта һәм Новосибирскта балалар һәм яшьләр өчен җәйге аланнар уздыру буенча грант бәйгеләрендә катнашырга ниятлиләр.

Чаралар эстафетасын 2012 елның апрелендә Латвия һәм башкаласы — Рига шәһәре хуплап алды. Европа тарихында һәм татар халкы тарихында беренче тапкыр Европа татар яшьләренең зур Җыены узды. Очрашуда Швеция, Германия, Литва, Латвия, Эстония, Финляндия, Чехия, Польша, Бөекбританиядән яшьләр катнашты, Россиянең Самара, Пермь өлкәләреннән, Санкт-Петербург, Мари Иле, Татарстаннан кунаклар килде.

Беренче форумның программасы да киң колачлы иде. Делегатларны Латвия белән таныштырдылар, Рига һәм Юрмалага экскурсияләр оештырылды. Пленар утырыш, һәртөрле мастер-класслар узды. Моннан кала Европа илләрендәге татар яшьләре оешмалары лидерлары үзара аерым җыелып та сөйләштеләр. Форум барышында узган төрле конференцияләр, дискуссияләр Европада татар диаспоралары тормышының төрледән-төрле өлкәләренә кагылды. Делегатлар һәм кунаклар Европа яссылыгында татар телен һәм мәдәниятен саклап калу буенча актуаль сорауларга җавап эзләделәр, бу өлкәдә эшлекле киңәшләр яңгырады, нәтиҗәле алымнар һәм механизмнар барланды.

Европа татар яшьләренең беренче форумын уздыру тәкъдиме белән чыгучы һәм чараны уздыручы — Европа татар яшьләре берләшмәсе рәисе, Бөтендөнья татар яшьләре форумы советы әгъзасы Олег Шәрипов булды. Олег җитәкләгән берләшмә әле күптән түгел, узган елның октябрь аенда гына барлыкка килгән иде. Эшчәнлегенең беренче елында ук үзе янына Алмания, Литва, Латвия, Эстония һәм Чехиядән яшьләрне туплый алды. Европа яшьләренең беренче форумы бу берләшмәгә яңа әгъзалар китерде. Хәзер берләшмә сафларында Бөекбритания, Польша, Финляндия, Швеция кебек абруйлы илләрдән актив яшьләр дә бар. Икенче форумны киләсе 2013 елда Эстониядә уздырырга карар бирелде.

Җәй башында, 17 июнь көнне Җир шарының Европага каршы икенче бер ноктасында — Алма-Атыда Үзәк Азия татар-башкорт яшьләре уртак бәйрәмгә — Сабантуйга җыелды. Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Таҗикстаннан кыю һәм сәләтле татарларны бер мәйданга туплаган мондый чара — татар тарихында шулай ук беренче мәртәбә. Азия илләрендә эшләп килүче иң яхшы татар җыр һәм бию коллективлары милләттәшләренә үз иҗатларын бүләк итте. Чараны оештыручы — Казахстанның Татар-башкорт иҗтимагый-мәдәни үзәге. Сабантуйда катнашудан кала, яшьләр монда да үзара тәҗрибә уртаклаштылар, бәйрәмнәр һәм башка чаралар уздыруның нечкәлекләре белән бүлештеләр.

Яшьләр өчен һәм яшьләрнең үз көчләре белән оештырылган мондый чараларның туган телне өйрәнүгә этәргеч булуын, милли үзаңны үстерү, мәдәниятебезгә мәхәббәт уятуда әһәмиятен бөтен катнашучылар да аңлады. Шуңа да мондый очрашуларны хәзер ел саен уздырырга карар кылынды. Алай гына да түгел, киләсе елда Үзәк Азия татар яшьләре Сабан туена Азәрбайҗан һәм Кытайдан да кунаклар килер дип көтелә.

Татарлар гомергә «Әтнә Сабантуе», «Казан Сабан туе» дип сөйләргә күнеккән. Бу елдан башлап татар телендә «Лондон Сабан туе» дигән төшенчә дә булачак һәм аны Бөекбританиядә көн итүче татар яшьләре кертеп җибәрде. Җәйнең нәкъ уртасында — 14 июль шимбә көнне алар Европа тарихында һәм татар халкы тарихында беренче тапкыр Лондон Сабан туе уз-

дырдылар. Сабантуй мәйданы атаклы Wembley Park гольф кырында урнашты. Бәйрәмдә Томанлы Альбионда гомер итүче йөздән артык татар кешесе катнашты. Форсаттан файдаланып, очрашуга Германия, Бельгия һәм Балтыйк буе илләреннән дә актив яшьләр җыелды. Лондон Сабан туе Европа татар яшьләре форумының матур бер яңгырашы булды, чөнки бәйрәмне оештыруда башлап йөрүче егет Дамир Елизаров форум вакытында ук бу идеясе белән уртаклашкан иде.

«Лондонда татарлар шактый күп, укырга килгән яшьләр хисабына аларның саны арта бара. Без белгәннәре әлегә 100-150 кеше. Сабантуй узганнан соң монда яшәүче татарлар үзләре хакында белдерер, үзара аралашырга, элемтәләр булдырырга теләр дип ышанабыз», — ди Дамир Елизаров.

Татарлар Лондонда бәйрәм ясап ятканда, шулай ук 14-15 июль көннәрендә Литваның Тракай шәһәрендә Литва татар яшьләре үзләренең беренче инициатив корылтайларына җыелышты. Бу чара — шулай ук беренче карлыгач.

«Корылтай-киңәшмәнең төп максаты — активистларны туплау һәм Литвада эшләп килүче «Дуслык» татар яшьләре оешмасының алга таба эшчәнлек юнәлешләрен билгеләү», — дип билгеләп үтте оешманың рәисе Мәрьям Мейшутович.

Форумда Клайпеда, Висагинас, Каунас, Пренай, Алитус, Вильнюс һәм Акъярдан (Кырым) ике дистә делегат катнашты. Чараны уздыру урыны итеп нәкъ Тракай шәһәре сайлану очраклы түгел. Бу шәһәр тарихында татарларның алты гасырлык тирән тарихи эзе бар. Тарихтан билгеле булганча, XIV гасыр башларында Бөек кенәз Витаутас татарларны үз иленә чакырып, нәкъ менә Тракай шәһәренә китереп урнаштыра. Шул вакытлардан бирле бу җирлектә иң зур татар мәхәлләләреннән берсе яшәп килгән, аның үз мәчете булуы да билгеле. Шәһәрне уратып алган күлләр арасында иң матуры хәзер дә «Татар күле» дип атала.

Җыен эшчәнлеге барышында «Лидер мөмкинлекләре» темасына семинар һәм тренинглар үтте, милли фольклор буенча мастер-класслар узды, ислам нигезләре турында сөйләнгән, Литва татарлары тарихын яктырткан лекцияләр укылды.

Россия киңлекләрендә дә татар яшьләре тормышы күзгә күренеп җанланды. Күп кенә шәһәрләрдә кызыклы чаралар узды. Ульяновск өлкәсе татар яшьләре форумы, Урал федераль округының татар иҗтимагый оешмалары форумы, Себердә яшәүче татар яшьләренең фестивале, Мәскәү шәһәре һәм Мәскәү өлкәсе татар яшьләре форумы — шуларның берничәсе.

Әлбәттә, узып барган елның иң зур вакыйгасы — Бөтендөнья татар яшьләренең V форумы булды. Казанга Россиянең һәр төбәгеннән һәм өч дистәдән артык чит илләрдән сигез йөзгә якын иң актив татар яшьләре җыелды. Форумның берничә көнлек эшчәнлеге вакытында делегатлар яңа идеяләр белән рухланды һәм ул идеяләр киләчәктә кызыклы яңа зур проектларга әверелер дигән ышаныч бар.

Аеруча шуны ассызыклап әйтәсе килә: дөньяның кайсы гына төбәгендә уздырылмасын, бу чаралар уртак бер максатка хезмәт итә. Ул да булса татар халкының яшь буынын милли кыйммәтләр тирәсендә туплау, туган телләрен, халкыбызның тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә этәргеч бирү. ■

ТАТАРСТАН – МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗНЕҢ ТАРИХИ ВАТАНЫ

РӨСТӘМ ГАЙНЕТДИНОВ,
2003-2010 елларда Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының бүлек җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты

ТЫШКЫ ЭШЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ МӘГЪЛҮМАТЛАРЫНА КАРАГАНДА, 30-32 МЛН КЕШЕЛЕК РОССИЯ ДИАСПОРАСЫ САН ЯГЫННАН КЫТАЙЛЫЛАРДАН (80 МЛН) КАЛА ИКЕНЧЕ УРЫНДА ТОРА. РОССИЯ ДИАСПОРАСЫНЫҢ ДҮРТТӘН БЕР ӨЛЕШЕ – РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ ТӨП ҖИРЛЕ ХАЛЫК ВӘКИЛЛӘРЕ. ШУЛАР АРАСЫНДА ТАТАР ДИАСПОРАСЫ САН ЯГЫННАН РУСЛАРДАН СОҢ ИКЕНЧЕ УРЫНДА ТОРА. ТАТАРЛАР ДӨНЬЯНЫҢ БАРЛЫК ЗУР ДӘҮЛӘТЛӘРЕНДӘ ЯШИЛӘР.

Булган якынча мәгълүматларга караганда, Россия Федерациясеннән читтә яшәүче татарларның гомуми саны 707 меңнән артып китә. Шуларның 634,9 меңе якын, ә 72,5 меңе ерак чит илләрдә яши. Дөньяның 50дән артык дәүләтендә татар этник бердәмлеге һәм төркемнәре бар.

Татар диаспорасы — иң күп таралган Россия диаспораларының берсе. Дөньяның 44 илендә милли-мәдәни берләшмә, милли җәмгыятьләр теркәлгән, тотрыклы этник төркемнәр бар. Милли-мәдәни берләшмәләрдә татар милли үзаңын, эстетик кыйммәтләрен, идеал һәм максатларын, милләтнең мәдәни-әхлакый традицияләрен һәм тарихи хәтерен, тәрбия нормаларын саклау алып барыла. Татарлар — чит телле һәм чит мәдәниятле мохиттә башка халыклар белән күпгасырлык дустанә мөнәсәбәт корып яшәү тәҗрибәсенә ия булган Россия халыкларының берсе. Андыйлар күп түгел. Төрле тарихи сәбәпләр нәтиҗәсендә, дөньяның төрле илләренә таралып яшәүче татарлар югары халыкара хокукый аңга ия, алар үзләре яшәгән илләрдә иҗтимагый һәм дәүләт төзелешен хөрмәт итәләр, гражданлык вазифасын лаеклы үтиләр, җирле халыкларның мәдәниятенә һәм традицияләренә хөрмәт белән карыйлар. Алар кайда гына яшәсәләр дә, аңлашылмаучанлыкка һәм конфликтларга форсат бирмиләр. Үзләре яшәгән дәүләтләрнең гражданнары буларак, илнең икътисади һәм мәдәни үсешенә сизелерлек өлеш кертеп, кардәшләребез татар халкының лаеклы вәкилләре булып торалар. Алар үзләре яшәгән дәүләтләрдә тынычлык, үсеш, тотрыклылык булуын, аларның чәчәк атуын, шул ук вакытта тарихи ватаннары белән күптармаклы хезмәттәшлек үсеше булуы белән дә кызыксыналар. Кайда гына яшәмәсеннәр, нинди динне генә тотмасыннар, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез үзләрен уртак тарихы, мәдәнияте, теле һәм үзаңы булган бердәм һәм бүленмәс татар халкының бер өлеше итеп таныйлар.

Ике меңъеллык чигендә булган зур тарихи вакыйгалар татар халкының яшәешен нык үзгәртте. «Тимер чаршау»ның җимерелүе нәтиҗәсендә россиялеләргә чит илдәге ватандашларының киңкырлы дөньясы ачылды. Моңарчы бүлгәләнгән этносның кушылу мөмкинлеге барлыкка килде. Чит илләрдәге татар диаспорасы вәкилләре тарихи ватаннарына тартылдылар. Моңарчы күзәтелмәгән яңа күренеш — милләттәшләребез яңа татар дөньясы оешу шартларында геополитик мәйданда халыкара лаеклы урынын дәгъва итә башлады. Бөтен халыкны берләштерүче бердәм милли-мәдәни оешмасы төзелү зарурлыгы туды.

Милләтнең бу потенциалын күрмәмешкә салышу һич кенә дә республикабыз өчен дөрес булмас иде.

Татар җәмәгатьчелеге XX гасырның 90 нчы елларында милли идеологияне һәм татарларның үсеш стратегиясен эшләүгә җаваплы милләтнең координацион үзәген булдыру зарурлыгы турында әйтте. Бөтентатар иҗтимагый үзәге беренчеләрдән булып ватандашлар белән эшли башлады. Инде 1989 елдан Казахстан, Украина, Үзбәкстан, Кыргызстан һәм Балтыйк илләренең татар җәмгыятьләре вәкилләре Бөтентатар иҗтимагый үзәге съездына, ә 1992 елда ачыктан-ачык оппозициясендә булган һәм хакимиятне үз кулына алырга дәгъва итүче Милли Мәҗлесне оештырган татар халкы Корылтаена чакырылдылар.

Бу шартларда республиканың киләчәге өчен стратегик яктан әһәмиятле

булган инициативаны кулга төшерү кирәклеге ачык күренде.

Россия һәм чит ил ватандашларының күпсанлы теләкләрен исәпкә алып, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев үзенең указы белән 1992 елда Казанда БТКның беренче съездын җыйды. Анда катнашучылар БТК оешуы турында карар кабул итте, аның идеологик яктан ориентлашкан һәм составы ягыннан «урта» карашлы шәхесләрдән торган үзәкләшкән Башкарма комитетын оештырдылар. Һич арттырмыйча әйтәм, съезд бик югары рухи күтәренкелек белән үтте: татарларның, кайда гына яшәмәсеннәр, туганлык һәм Татарстан Республикасына уртак йорт кебек карау хисләре тулып ашкан иде.

Ул вакыттан соң 1997, 2002, 2007 елларда тагын өч съезд булды. Шушы вакыт эчендә халыкара масштабтагы иҗтимагый оешмалар берләшмәсе булып, БТК үзен дөнья җәмәгатьчелегенә СССРның элеккеге союздаш республикалары һәм башка чит илләрдәге татар иҗтимагый үзәкләрен, автономияләрен һәм җәмгыятьләрен берләштерүче «үзәк» позициядә торган дәүләти булмаган оешма буларак танытты.

БТК БКның беренче рәисе Казан университеты галиме һәм берничә чакырылышның Татарстан Парламент әгъзасы Индус Таһиров булды. Ул оешманы төзүдә, аның эшләү принципларын һәм идеологиясен булдыруда, БТКның Россиядә һәм халыкара мәйданда дәрәҗәсен ныгытуда күп эш башкарды. 2002 елдан аны ватандашлар белән хезмәттәшлекне практик яктан җәелдергән, танылган культуролог, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ринат Закиров алыштырды.

БТКның I съездыннан соң узган вакыт эчендә әлеге оешма йогынтысында татарларның иҗтимагый аңы шактый җитди үзгәрешләр кичерде. БТКның төп эш нәтиҗәсе булып, татарларның, кайда гына яшәсәләр дә, үзләрен бөек халыкның бер өлеше итеп кабул итә башлаулары тора. Дөньядагы барлык татарлар да үзләренең бердәнбер милли тарихи ватаннары итеп Татарстанны таныйлар. Үз чиратында, Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга милли мәдәниятне, телне үстерүдә, аларның үзенчәлекләрен саклап калуда ярдәм» күрсәтүне Конституциясенә беркетеп олы бурычны үз өстенә алды (14 маддә). Шулай ук Россия Федерациясе 2007 елның 26 июнендә Россия Федерациясе дәүләт хакимияте һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасындагы Вәкаләтләрне бүлешү һәм эш алып бару турындагы Шартнамә нигезендә чит илдәге ватандашлар белән эшләү буенча вәкаләтне Татарстанга тапшырды.

БТК Россия ватандашларының Халыкара Советының әгъзасы булып тора, Россия Федерациясенең Тышкы эшләр министрлыгы һәм чит ил оешмалары белән хезмәттәшлек итә. 2004 елдан башлап яшьләр, Бөек Ватан сугышы ветераннары белән эшләү, чит илләрдә Сабантуй милли бәйрәмен уздыру һ.б. чараларда БТКна Россия Федерациясенең чит илдәге ватандашларның эшләре буенча Хөкүмәт комиссиясе тарафыннан финанс ярдәм күрсәтелә.

Егерме ел эчендә күп эшләнгән. Гуманитар, мәдәни, белем, фәнни, мәгълүмат өлкәсендә проектлар, диаспоралар белән элемтәләрне ныгыту тормышка ашырылды. Татарстандагы югары уку йортларында күрше өлкә һәм чит илләрдәге ватандашларның балаларын укыту программасы эшли. Бу программага ерак илләрдәге татар

яшьләре дә актив кушыла башлады. 2003 елдан 2012 елга кадәр бу программа буенча югары уку йортларына 1200дән артык кеше кабул ителгән, шуларның 700гә якыны Үзбәкстан, Казахстан, Кыргызстан, Азәрбайҗан, Таҗикстан, Төрекмәнстан, Беларусь, Латвия, Литва, Украина, Эстония, Төркия һәм Кытайдан (69 татар Синьцзян-Уйгыр автоном районыннан) килгән.

«Татарстан — Яңа Гасыр» телекомпаниясенең «ТНВ-планета» татар спутник каналын гамәлгә кертү бөтен Җир шарында яшәүче татарлар өчен милли телевидение программаларын карау мөмкинлеге бирде. ТНВ каналында татар телендә эфирга чыга торган программалар арасында иң популярлары булып БТК тәкъдиме белән кертелгән «Халкым минем», «Татарлар» тапшырулары тора. Татар сегментлы интернет даими үсештә, аның иң югары нокталарының берсе булып, «Tatar ile» мәгълүмати-белем бирү порталының эшләве торырга тиеш. БТК БК составында даими һәм эзлекле рәвештә төрле юнәлешләрдә эшләүдә структуралар булдырылган. Алар: татар авыллары Бөтенроссия берләшмәсе (җитәкчесе — Рәшид Сәнҗәпов), «Татарча көрәш» Бөтенроссия федерация милли көрәше (җитәкчесе — Җәүдәт Миңнәхмәтов), «Татар гаиләсе» Бөтенроссия фонды (җитәкчесе — Миләүшә Гайфуллина), Татар яшьләре Бөтендөнья форумы (җитәкчесе — Тәбриз Яруллин), «Ак калфак» хатын-кызлар берләшмәсе (җитәкчесе — Резеда Мөхәммәтшина), Татар эшкуарлары берләшмәсе (җитәкчесе — Нурулла Саттаров), Татар якташлык җәмгыятьләре.

БТК тарафыннан милләттәшләр белән аралашу өчен гаҗәеп үзенчәлекле «мәйданнар» булдырылды. Сүз милләт үсешендә стратегик һәм принципиаль мәсьәләләрне хәл итә торган БТК съездлары; Татар яшьләренең Бөтендөнья форумнары, татар укытучылары съездлары, татар дин әһелләре Бөтенроссия форумнары, татар зыялыларның Бөтендөнья форумнары, татар журналистлары форумнары, Россия һәм чит ил татар эшмәкәрләре катнашындагы «Татарстанның эшлекле партнёрлары» форумнары. Тышкы эшләр министрлыгы фикере буенча, Россиянең бер генә милли диаспорасының да мондый масштаблы аралашу «мәйданнары» юк.

Бүгенге көндә татар милли яңарышы билгесе булып Россия Федерациясенең 70 өлкәсендә һәм 22 чит илдә уздырылучы Сабантуй бәйрәме тора. БТК илнең барлык өлкәләре делегацияләре катнашында ел саен гомумфедераль Сабантуй үткәрү инициативасы белән чыкты. 2002 елдан башлап Саратов, Тольятти, Димитровград, Йошкар-Ола, Түбән Новгород, Саранск, Чиләбе, Әстерхан, Ульяновск, Ижау, Екатеринбург, Валидивостокта Федераль Сабантуй бәйрәмнәре үтте. Шунысы да мөһим — аларның барысы да Татарстан һәм бәйрәм уза торган республика яки өлкә җитәкчеләре катнашында узды.

2010 елда БТКның Бөтенроссия авыл Сабан туен уздыру тәкъдиме тормышка ашты. Ул Самара өлкәсенең Гали (2010), Чувашстан Республикасының Шыгырдан (2011), Чиләбе төбәгенең күпмилләтле Дубровка авылында (2012) уздырылды.

Кайбер чит илдәге татар җәмгыятьләре дә гомуммилли Сабантуй бәйрәмен үткәрә. Әйтик, республика күләмендә Казахстан, Балтыйк буе, Бөтенукраина Сабан туе һ.б. Сабантуй үтәсе шәһәр ел саен алышынып тора,

һәр татар җәмгыяте милли бәйрәмне үзләрендә үткәрүне зур горурлык дип саный.

Соңгы дистә елда БТК яшьләр белән эшләүгә зур игътибар бирә башлады. Даими рәвештә ике елга бер тапкыр Татар яшьләренең Бөтендөнья форумы уздырыла. Бөтен дөньяның 30 иленнән 2600дән артык егет һәм кыз катнашкан биш форум булды. Әлеге форумнар чит илләрдә һәм өлкәләрдә яңа яшьләр оешмалары барлыкка килүгә, яшьләр хәрәкәте киңәюенә, милли-мәдәни оешмаларының өлкән буын активистларына алмаш әзерләүгә этәргеч булып тора. Бүгенге көндә инде йөздән артык татар яшьләре оешмасы эшли.

БТК теләге һәм Татарстан Республикасы ярдәме белән 2010 елдан башлап һәр ел саен Россия Федерациясенең 80 өлкәсеннән һәм чит илләрдән килгән 700дән артык имам катнашында «Милли үзенчәлек һәм дин» исемле татар дин әһелләре форумы үткәрелә. 2011 елдан бу форум «Изге Болгар» җыенына туры китереп уздырыла башлады.

2007 һәм 2011 елларда Татарстан Фәннәр академиясе белән берлектә Рәшит Сюняев, Камил Вәлиев, Роберт Нигъмәтуллин, Мәхмүт Гәрәев һ.б. бүгенге күренекле фән эшлеклеләре катнашында Бөтендөнья татар галимнәре форумы уздырылды. Форумнарда татар фәнни җәмәгатьчелеге вәкилләре татар халкына һәм Татарстан Республикасы файдасына бөтен көчләрен куярга әзер булуларын күрсәттеләр.

«Иске» (Финляндия, Төркия, АКШ, Кытай, Австралия) һәм «яңа» диаспораларда (Германия, Канада, Чехия, Бельгия, Англия һ.б.) җәмгыятьләр тормышы төрлеләнә, яңа эчтәлек белән тулылана бара. Бу барыш Татар этник җәмгыятьләре үзләре яшәгән торган илләрнең гражданлык җәмгыятендә үз урынын табуы турында сөйли.

Моңа, һичшиксез, Татарстан Республикасының алгарышы, тормышның барлык өлкәләрдә уңышлары, республика җитәкчелегенең читтә яшәүче ватандашлары белән тыгыз элемтәләр булдыру омтылышы ярдәм итә.

БТКның халыкара эшчәнлеге дә киңәя бара. Конгресс делегацияләре 2010-2012 елларда Украина, Эстония, Латвия, Литва, Үзбәкстан, Азәрбайҗан, Казахстан, Төркия, Польша, Германия, АКШ, Кытайда булдылар. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеткүпләп татарлар яшәгән илләрдә күчмә утырыш уздыруны гамәлгә куйды. Мондый күчмә утырышлар инде Финляндиядә, АКШта, Төркиядә, Украинада, Белоруссиядә, Казахстанда (Семипалатинск һәм Актүбә), Латвиядә, Литвада үткәрелде. Аларда Бөтендөнья татар конгресс Башкарма комитетәгъзаларыннан тыш, гадәттә, күренекле мәдәният, җәмәгать эшлеклеләре, эшмәкәрләр катнаша. Мондый югары дәрәҗәдә уздырыла торган чаралар җирле җәмәгатьчелек һәм хакимиятләр каршында татар җәмгыяте дәрәҗәсен күтәрә һәм татарлар тормышы активлашуына этәргеч бирә. 2010 елның 25 ноябрендә Польшаның Гданьск шәһәрендә, татар сугышчысына һәйкәл ачу хөрмәтенә багышланган тантана һәм анда яңгыраган Польша Президенты Бронислав Комаровскийның нотыгы татар җәмәгатьчелегендә зур яңгыраш тапты.

Шунысы куанычлы: чит илләрдә яшәүче татарлар төрле чараларны Россия илчелеге вәкилләре һәм җирле үзидарә органнары белән тыгыз бәйләнештә уздыралар. ■

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ «ЕЛЪЯЗМАСЫ»*

(1992-2012 ЕЛЛАР)

20 ЕЛ... ГАЛӘМ ТАРИХЫ ӨЧЕН БУ БЕР МИЗГЕЛ ГЕНӘ, Ә БЕР КЕШЕ ГОМЕРЕ ӨЧЕН БУ БЕР ДӘВЕР. ШУШЫ 20 ЕЛДА БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИР ШАРЫНЫҢ ТӨРЛЕ ПОЧМАКЛАРЫНДА ЯШӘҮЧЕ ТАТАРЛАРНЫ БЕРЛӘШТЕРҮ, МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ ТЕЛЕН, МӘДӘНИЯТЕН, ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕН САКЛАП КАЛУ ӨЧЕН ЗУР ЭШЛӘР БАШКАРДЫ. СЕЗНЕҢ ИГЪТИБАРГА ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ ТОРГАН «ЕЛЪЯЗМАДА» ШУШЫ КҮПКЫРЛЫ ЭШЧӘНЛЕКНЕҢ КАЙБЕР МИЗГЕЛЛӘРЕН ТЕРКӘДЕК.

Н.Гариф фотосы

19 июнь,1992 ел. Бөтендөнья татар конгрессының беренче съезды делегатлары Ирек мәйданында

*Вакыйгаларның булган урыны күрсәтелмәгән очракта, сүз Казан шәһәре турында бара.

1992

19-23 июнь. Бөтендөнья татар Конгрессының* беренче съезды. Конгресска дөньяның төрле почмагыннан меңнән артык делегат килә. Алар арасында Төркиядән Премьер-министрның баш киңәшчесе Кемал әфәнде Зейбәй, Төркиядә яшәүче татар эшкуары Фәрит Бичурин, галим Надир Дәүләт, Японияднән Темимдар Мохит, Австралия эшкуары Рөстәм Садри кебек мөхтәрәм шәхесләр, АКШ, Финляндия, Германия, Польша, Кытай, Швеция, Норвегия, Литва, Румыниядән абруйлы делегацияләр бар.

19 июнь. БТКның Башкарма Комитетын** сайлау турында карар кабул ителә.

БКка түбәндәге вазифалар йөкләнә:

— ТРның социаль-икътисади, милли-мәдәни һәм сәяси үсешенә һәрьяклап ярдәм итү;

— барлык татарларның этник-региональ мәсьәләләрен хәл итүдә, Татарстаннан читтә яшәүче татарларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә гомум демократик кагыйдәләргә таянып, гадел арадашчы булу;

— тел, фән, мәгариф һәм мәдәният өлкәләрендә максатчан комплекслы программалар төзүгә һәм аларны гамәлгә ашыруга ярдәм итү;

— кирәкле эксперт һәм аналитик тикшеренүләр, дәүләт учреждениеләре һәм иҗтимагый оешмалар өчен гамәли тәкъдимнәр әзерләү;

— гомумтатар халкының яшәү шартлары турында мәгълүматлар туплау һәм аларны тарату; газета-журналлар, башка басма әсәрләр чыгару, теле-радио программалар әзерләү, татарлар яши торган төбәкләрдә массакүләм мәгълүмат чаралары булдыру;

— татар диаспорасы белән даими бәйләныш булдыру.

Шулай ук утырышта Башкарма комитет каршында Фонд ачарга да карар бирелә.

20 июнь. Беренче съезд кысаларында «Татар халкы тарихы», «Милли мәгариф системасын үстерү мәсьәләләре», «Татар мәдәнияте үсеше мәсьәләләре», «Татарстанда фәнне үстерү мәсьәләләре», «Массакүләм мәгълүмат һәм нәшрият», «Татар телен үстерү мәсьәләләре», «Милли белгечләр әзерләү мәсьәләләре», «Мирас һәм заман», «Татар эшмәкәрләре», «Милләт, хатын-кыз һәм гаилә», «Иске татар бистәсе: үткәне һәм киләчәге», «Татар эмиграциясенең тарихы һәм бүгенге хәле», «Яшьләр мәсьәләсе», «Татарстан Республикасы дипломатиясе һәм халыкара элемтәләр», «Милли һөнәрчелекне тергезү» кебек секцияләр эшли.

21 июнь. «Ак калфак» бөтентатар хатын-кызлар берләшмәсе (ассоциациясе) раслана. Аның идарә рәисе итеп «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Р.Туфитулова, урынбасарлары итеп Т.Биктимерова һәм Л.Шакирҗанова сайлана.

23 июнь. ТР Президенты катнашында БТК оештыру утырышы. БК рәисе итеп Индус Таһиров, рәис урынбасарлары буларак Роза Туфитулова, Флүн Мусин, Римзил Вәлиев сайлана.

1993

12 февраль. ТР телерадиокомпаниясе җитәкчеләре, галимнәр һәм элемтәчеләр катнашында БТК БК бюросының киңәйтелгән утырышында төбәкләргә, якын һәм ерак чит илләрдә татарча тапшырулар алып барыла торган кыска дулкынлы радиостанция оештыру мәсьәләсе тикшерелә.

25-26 февраль. Пермь өлкәсенең Барда районында «Кама буе татарлары һәм башкортлары: милли яңарыш тарихы, проблема һәм перспективасы» дип аталган фәнни-гамәли конференция уза.

Март. БТК һәм «Ак калфак» хатын-кызлар ассоциациясе татар кызлары конкурсы — «Гыйффәт туташ» бәйге-тамашасы үткәрә.

---

*Алга таба «Бөтендөнья татар конгресс»

** Алга таба «Башкарма комитет»

28-30 май. БТК БКда Вәкаләтсез халыклар һәм милләтләр оешмаларының региональ киңәшмәсе. Анда әлеге оешманың генераль секретаре Линнарт Мелль катнаша. Киңәшмәдә катнашучылар Россия Федерациясендә кеше һәм халыкара хокуклар бозылу мәсьәләләрен тикшерәләр, карарлар кабул итәләр. Карарларда РФ Конституциясе төзегәндә 1966 елда кабул ителгән Кеше Хокуклары Пакты таләпләрен тулы чагылдырырга — халыкларның тигезлеген һәм үзбилгеләнү хокуклары принцибын кертү, азчылык халыкларның хокукларын яклау; Вәкаләтсез халыклар һәм милләтләр оешмасының Казан шәһәрендә Идел-Урал Координацион үзәген төзү — кирәклеге турында пунктлар та була.

22-23 июнь. БТК БКның «Беренче татар конгрессы карарларын тормышка ашыру һәм барлык интеллектуаль көчләрне рухи берләштерү буенча БК эшчәнлеге» дигән темага киңәйтелгән утырышы.

10-11 ноябрь. Яшел Үзән шәһәрендә РФнең Федерация һәм милли эшләр комитеты, ТР Министрлар Кабинеты, ТР Президент Аппаратының халыкара мөнәсәбәтләр һәм иҗтимагый-сәяси оешмалар белән элемтә бүлеге катнашында «РФ төрки халыкларын тергезү» дигән темага семинар-киңәшмә. Анда БМОның кеше хокуклары комиссиясенә хәзерләгән мөрәҗәгатьтә Россия халыкларын гражданнар сугышы куркынычыннан коткаруны сорасалар, АКШ конгрессы, «Азатлык», «Азат Европа» радиостанцияләренә җибәрелгән мөрәҗәгатьләрдә чуваш, якут, кумык, балкар, карачай телләрендә тапшырулар оештыру тәкъдимнәре әйтелә.

1994

20 гыйнвар. «Татар халкын тергезүне оештыруның актуаль проблемалары» дигән темага фәнни-гамәли конференция уза.

25-27 февраль. Чебоксар шәһәрендә Идел буе һәм Урал халыклары Ассамблеясын оештыру съездында БТК БК әгъзалары Р.Ягъфәров, Д.Исхаков, М.Шәмсетдинов катнаша.

23-26 июнь. Бөтендөнья татар галимнәренең «Фән» исемле берлеге оеша (1995 елда теркәлә). Аның Президенты итеп профессор Р.Г.Бохараев сайлана. Берлекнең яшьләр өчен «Әбүгалисина» дип аталган фәнни-популяр журналы чыга башлый.

26 август. «ТР суверенитеты турындагы Декларацияне кабул итүгә дүрт ел» дип аталган фәнни-гамәли конференция уза.

5 октябрь. «Казан ханлыгы трагедиясе: тарих һәм сабак» дигән темага фәнни конференция. Биредә Татарстанда тарихи гаделлеккә нигезләнгән дәүләт идеологиясен булдыру, милли үзаңны үстерүдә мәгариф, 15 октябрьне «Гомумхалык матәм көне» дип билгеләүне Татарстан Югары Советыннан сорау, 1552 елда башкаланы яклаучыларга һәйкәл салу, чит илләргә киткән мәдәни һәйкәлләрне кире кайтару турында сөйләшәләр, карарлар кабул итәләр.

20-24 октябрь. Екатеринбург шәһәрендә БТК БКның татар-башкорт мәдәнияте үзәге, Татар галимнәре һәм эшмәкәрләре ассоциациясе, «Камил» фирмасы, «Якташ» хәйрия фонды тарафыннан оештырылган күчмә утырышта Свердловск өлкәсендә яшәүче татарларның проблемалары тикшерелә һәм аларны чишү юлларын табу мәсьәләләре карала. Татарстанның Мәгариф министрлыгы һәм Свердловск өлкәсенең Халык мәгарифе департаменты арасында татар халкының мәгариф өлкәсендәге ихтыяҗларын канәгатьләндерү турындагы килешүгә кул куела.

Декабрь. «Ак калфак»ның хатынкызлар шурасы Россия гаскәрләренең

Чечня республикасына бәреп керүенә каршы оештырылган сәяси митингта катнаша һәм Россия Президентына мөрәҗәгать белән чыга. Шулай ук Конгрессның БКы Россия Президенты Б.Ельцинга һәм Чечня Республикасы Президенты Җ.Дудаевка Россия гаскәрләрен Чечняга басып керүләре уңае белән протест белдереп хат җибәрә.

1995

7 март. «Ак калфак» оешмасы «Шагыйрәләр кичәсе» үткәрә.

15 апрель. ТР Мәдәният Министрлыгы һәм Дәүләт филармониясе белән «Татар җыры — 95» фестивален үткәрүдә катнаша.

19-20 июнь. Россия крайлары һәм өлкәләренең, БДБ һәм Балтыйк буе илләренең татарча газета, журнал, телерадио редакторлары катнашында «Милли журналистика һәм татар халкының милли яңарышы» дигән семинар уза. Анда төбәкләрдә һәм Татарстанда татар милли журналистикасын, газета-журналларны, телерадио тапшыруларны үстерү, кадрлар әзерләү мәсьәләләре тикшерелә.

Июль. «Идел» туристлар лагеренда «Татар яшьләре көннәре» үткәрелә.

29 август. ТР Фәннәр академиясе, ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Архив идарәсе һәм тарихчы-архивчылар оешмасы белән ТР дәүләт суверенлыгы турындагы Декларацияне кабул итүгә багышланган «Суверен Татарстан: тарих, хәзерге көн, перспектива» дип аталган фәнни-гамәли конференция үтә.

Октябрь. Әлмәт шәһәрендә «Татар хатын-кызлары хәрәкәте» тарихына багышланган шәһәркүләм чара үткәрелә.

Ноябрь. Гаилә елы уңае белән Татарстан һәм БДБ илләре вәкилләре катнашында «Ак калфак» берләшмәсе «Киленбикә» конкурсы үткәрә.

Ел дәвамында татарлар яшәгән төбәкләрне — республика, өлкә, район, шәһәр, авылларны паспортлаштыру, татарлар хакында мәгълүмат җыю үткәрелә.

Декабрь. ТР Хатын-кызлары корылтае.

1996

25 гыйнвар. БТК БК бюросының Татарстан җәмәгатьчелеге, интеллигенциясе белән бергә үткәргән киңәйтелгән утырышы. Монда татар гаиләсе мәсьәләләре тикшерелә.

13 апрель. Ульяновск шәһәрендә Ульяновск өлкәсе татар иҗтимагый Координацион советы, Ульяновск өлкәсенең милли мәсьәләләр буенча комитеты белән бергә оештырылган күчмә утырышта өлкә татарларының проблемалары һәм аларны чишү юллары өйрәнелә. Шулай ук татар телендә телерадио тапшырулар оештыру, өлкәдә татарча басмалар һәм китаплар таратуны җайга салу, татар уку йортларын кадрлар белән тәэмин итү турында килешенәләр. ТР Мәдәният министрлыгы һәм Ульяновск өлкәсенең мәдәният идарәсе арасында аерым чараларны күздә тоткан икеяклы килешүгә кул куела. ТР Мәгариф, Мәгълүмат һәм матбугат министрлыклары һәм Ульяновск өлкәсенең аларга тиңдәш идарәләре арасында хезмәттәшлек турында сөйләшү була һәм килешү проектлары карала.

3-4 июнь. РФ субъектлары һәм төбәкләрендәге татар мәдәниятен, мәгарифен үстерү проблемалары буенча Россия Федерациясенең министрлыклары, мәдәният һәм халык мәгарифе идарәләре җитәкчеләре, татар иҗтимагый, мәдәни үзәкләре җитәкчеләре катнашында Координацион киңәшмә оештырыла. Киңәшмә федераль һәм региональ Башкарма органнарга татар телен, мәгарифен, мәдәниятен, массакүләм мәгълүмат

чараларын үстерү буенча төрле тәкъдимнәр белән чыга. Алар арасында Әстерхан, Екатеринбург, Омск, Новосибирск, Чиләбе, Башкортстан, Мордовия, Чувашия, Пенза, Саратов, Чиләбе калаларының иң эре уку йортларында татар бүлекләре ачу, РФ төбәкләрендә татар урта мәктәпләре һәм мәктәпкәчә учреждениеләр оештыру, тарихи объектларны татар милли-мәдәни һәм дини оешмаларына бирү, татарлар тупланып яшәгән җирләрдә татар китапханәләре яки татар телендә әдәбият бүлекләре ачу, төрле өлкәләрдә район газеталарын яңадан чыгара башлау, Россия күләмендә гомумтатар газетасын, Гомумроссия татар театрын оештыру, РФ субъектларында татар иҗат коллективларын торгызу кебек тәкъдимнәр бар.

1997

28 февраль. Самара өлкәсе Камышлы районы үзәгендә өлкә админстрациясе һәм татар иҗтимагый-мәдәни үзәкләре вәкилләре катнашында БТК БК бюросының күчмә утырышы. ТР Мәдәният министрлыгы һәм Самара өлкәсенең мәдәният идарәсе арасында килешүнең үтәлеше тикшерелә. Ул килешүнең нигезендә Самара өлкәсе хакимияте тарафыннан өлкә татар гражданнарына татарча белем алу өчен шартлар тудыру, ә Татарстан хакимиятенә уку программалары, дәреслекләр, методик кулланмалар белән тәэмин итү, семинар, конференцияләр үткәрү, төрле контактлар урнаштыру кебек бурычлар ята. Самара өлкәсендә татар милли мәгарифе мәсьәләләре тикшерелә.

7-9 апрель. БТК һәм Бөтендөнья башкорт корылтае БКлары очрашып, үзара хезмәттәшлек һәм Башкортстан Республикасында, Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясенең башка субъектларында яшәүче татарларны һәм башкортларны милләт буларак үстерү турында килешү төзиләр.

28-29 август. Икенче БТК съезды. Съездга җир шарының 24 дәүләтеннән, Россиянең 60ка якын төбәгеннән 459 делегат, чакырылган кунаклар белән барлыгы 800 кеше катнаша. Төрле мөрәҗәгатьләр кабул ителә. Съезд программасы кысаларында «Хәзерге дөньяда татарлар» дигән фәннигамәли конференция оештырыла. Конференциядә сөйләнгән докладлар һәм чыгышлар — федерализмның сәяси-хокукый аспектлары; ТР социальикътисади прогрессы программасының үтәлеше; татар халкы һәм Татарстан тарихы; милли мәгарифне үзгәртеп кору; милли мәдәниятнең үсеш юллары; татар теленең функциональ үсеше; беренче татар энциклопедиясен хәзерләү кебек проблемаларны яктырта.

19 ноябрь. Яр Чаллы шәһәрендә Бөтендөнья татар конгресс Башкарма комитетның һәм ТР Дәүләт Советының Мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясе катнашында узган киңәйтелгән утырышында татар телен, мәгарифен саклау, өйрәнү һәм үстерү мәсьәләләре, Россиянең яңа паспортларында милләтне күрсәтү хокукы, дини тамгаларны (тәрене) бетерү турында мәсьәләләр тикшерелә.

29 ноябрь. Минск шәһәрендә БТК БКның күчмә утырышы уза. Анда Белоруссия, Литва, Польша татарлары җыеннары эшчәнлеге һәм проблемалары өйрәнелә, татарларның миллимәдәни үсеше турында карарлар кабул ителә.

9 декабрь. Азнакайда БТК БКның күчмә утырышында Азнакай районы хакимиятенең татар авылларының милли йөзен саклау һәм үстерү буенча эшчәнлеге тикшерелә. БТК БК, Россия Гуманитар Фәннәр академиясенең Татарстан бүлеге һәм Азнакай хакимияте арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүгә кул куела.

20 декабрь. Волгоград Төбәк татар мили-мәдәни мохтариятен оештыру Корылтае уза.

1998

17 март. Краснодар краенда Төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте булдырыла.

10-11 апрель. 10 апрельдә Санкт-Петербург шәһәрендә БДБ илләренең Парламентара Ассамблеясы һәм БТК БК әгъзалары очраша. Очрашуда Ассамблея каршында БТКнан даими күзәтүче булдыру турында килешү төзелә. 11 апрельдә БТК БК һәм Санкт-Петербург шәһәренең Төбәк татар милли-мәдәни мохтариятенең берләштерелгән утырышы уза. Санкт-Петербургта Дәүләт татар мәдәни үзәге һәм «Нур» газетасын оештыру мәсьәләләре карала.

24 апрель. БТК Россия Федерациясенең Юстиция министрлыгында теркәлә. «Бөтендөнья татар конгрессы» — иҗтимагый берләшмәләрнең Халыкара Союзы дигән яңа статус ала.

15 май. Арчада БТК БКның яшьләр белән эшләү комиссиясе катнашында педагогик колледжлар арасында милли гореф-гадәтләргә таянып тәрбия эшен алып бару буенча республика күләмендә конкурс үткәрелә. Анда 11 шәһәрдән вәкилләр катнаша.

20 май. Санкт-Петербург шәһәре, Саратов, Ульяновск, Екатеринбург өлкәләре татар милли-мәдәни мохтариятләре катнашында Россиядәге татарларның Федераль милли-мәдәни мохтариятен оештыру съезды була. Съездда ТФМММнең (Татар Федераль милли-мәдәни мохтарияте) Уставы кабул ителә, Казан шәһәрендә 11 кешедән торган Мохтарият Советы раслана, Совет рәисе итеп И.Р.Таһиров сайлана.

22 май. Сыктывкарда Коми Республикасында яшәүче татар һәм башкортларның «Дуслык» исемле төбәк милли-мәдәни мохтариятен оештыру корылтае уза.

20 июнь. Семипалат шәһәрендә БТК БКның киңәйтелгән утырышы үткәрелә. Утырышта Казахстан татарларының рухи үсеше һәм проблемалары тикшерелә, Казахстан белән Татарстан арасында икътисади, сәяси, мәдәни элемтәләрне киңәйтү турында карарлар кабул ителә.

25 июнь. «Ак калфак» оешмасы вәкилләренең Австралиянең Аделаида шәһәрендә оештырылган «Ак калфак» җәмгыяте әгъзасы Сафия ханым Вәлиева белән очрашуы була. Алар Аделаида Үзәк музеенда оештырылачак «Без — татарлар!» дигән күргәзмә өчен этнографик предметлар җибәрү турында килешәләр.

16 июль. Мәскәү шәһәре Төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте төзелә. Мохтарият рәисе итеп Р.Акчурин сайлана.

29 сентябрь. БТК БКда «Фикердәш» клубының беренче утырышы үтә. Анда ТР Архив идарәсе җитәкчесе Д.Шәрәфетдинов һәм композитор М.Шәмсетдинова татар тарихына кагылышлы Швециядән алып кайтылган яңа документлар һәм чыганаклар белән таныштыралар.

12 октябрь. БТК БКның «Фикердәш» клубында Иван IV гаскәрләренең Казанны алуының 446 еллыгына багышланган «Хәтер көне» кичәсе уздырыла.

23 октябрь. БТК БК конференцияләр залында ТР Президенты Аппараты һәм хөкүмәт вәкилләре, БТК БК әгъзалары, милли оешма лидерлары катнашында «РФ һәм ТРда этникара һәм конфессияара ситуация» исемле «түгәрәк өстәл» үткәрелә.

6-7 ноябрь. Мәскәү шәһәрендә БТК БК һәм Мәскәү шәһәре Төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте советының берләштерелгән күчмә утырышында татар мәдәниятен, телен үстерү мәсьәләләре тикшерелә.

3 декабрь. БТК БК бюросы утырышында яшьләр белән эшләү сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары тикшерелә.

18-19 декабрь. Сургут шәһәрендә Төбәк татар милли-мәдәни мохтариятен төзү конференциясе уза. Аның рәисе итеп Ф.Гатауллин сайлана.

1999

4 февраль. БТК БК бюросы утырышында «Татар җыры, татар моңы — үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге» дигән темага «түгәрәк өстәл» оештырыла. Татар җырын, моңын таныту, үстерү, төрле конкурслар оештыру буенча карарлар кабул ителә.

9 апрель. Казан шәһәрендә БТК БК бюросы әгъзалары, ТР һәм Самара өлкәсенең дәүләт органнары вәкилләре, Самара өлкәсенең татар иҗтимагый-мәдәни үзәге җитәкчеләре катнашында өлкә татарларының мәдәни үсешен тикшерүгә һәм үстерүгә багышланган утырыш үтә.

4 июнь. «Татар халкының милли-мәдәни ихтыяҗларын гамәлгә ашыруда дәүләт органнары һәм татар иҗтимагый берләшмәләренең уртак эше» дигән темага Бөтенроссия киңәшмәсе була. Киңәшмәдә Россиянең төрле төбәкләреннән килгән татарлар туган телдә белем алу, гореф-гадәтләрне саклау һәм мәдәни ихтыяҗлар турында чыгыш ясыйлар.

28 июнь. Омск шәһәрендә БТК БКның Татар Федераль милли-мәдәни мохтарият советының берләштерелгән күчмә утырышы уздырыла. Омск өлкәсе дәүләт органнары һәм Төбәк татар милли-мәдәни мохтариятләренең хезмәттәшлеге мәсьәләләре карала.

6-8 июль. Әстерхан шәһәрендә өлкә дәүләт органнары вәкилләре, «Дуслык» милли җәмгыяте җитәкчеләре катнашында күчмә утырыш үткәрелә. Анда өлкәдә яшәүче татарларның милли-мәдәни мәсьәләләре карала.

7 октябрь. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Россия Федерациясе Дәүләт Думасына сайлаулар чорында татар халкының һәм Татарстанның мәнфәгатьләре» дигән темага «түгәрәк өстәл» үткәрелә.

11 октябрь. БТК БК утырышлар залында «Сөембикә-ханбикә тарих мөнбәрендә лаеклы урын алдымы?» дигән кичә булып уза. Ул Хәтер көненә багышлана. Кичәдә Казан ханлыгын саклап шәһит киткәннәрнең истәлеген мәңгеләштереп, һәйкәл кую мәсьәләсе, Казанның үзәк урамнарының берсенә Сөембикә исемен бирү, Сөембикә-ханбикәгә һәйкәл ачу, ханлык чорын чагылдырган табышлы сувенирлар ясау мәсьәләләре күтәрелә.

28-29 октябрь. Ижевск каласында «Удмуртия татарлары» дигән фәнни-гамәли конференция оештырыла. Удмуртиядәге татарларның милли-мәдәни үсеше, милләтара мөнәсәбәтләрне ныгытуга бәйле карарлар кабул ителә.

2000

10 февраль. Мәскәү каласында БТК БК бюросының һәм Татар Федераль милли-мәдәни мохтарияте советының күчмә утырышы оештырыла. Аның резолюциясендә түбәндәге җөмләләр бар: «...президентлыкка кандидат итеп В.В.Путинны тәкъдим иткән вакытта РФ татарлары Россия дәүләтенең эффектив милли сәясәтен булдырырга, бөтен милләтләрнең дә тигез хокуклы булу принцибын тормышка ашыру һәм милли-мәдәни үсеше өчен конкрет чаралар булдырырга тәкъдим итәләр. Җимерү урынына төзү, таркалу урынына берләшү, сәяси вә хокукый проблемаларны хәл итүдә конфронтация һәм көч кулланудан баш тарту — менә шуларга Россия татарлары өмет итәләр». Шулай ук резолюциядә федераль гомумтатар газетасы, Россия халыклары телләрендә телерадиотапшырулар ачу турында пунктлар да бар.

Февраль. «Ак калфак» оешмасының Санкт-Петербург шәһәре бүлекчәсе татар гаиләләре өчен «Буыннарның көмеш чылбырлары» дигән очрашу оештыра.

30 март. БТК БК инициативасы буенча оештырылган зыялы татар яшьләре клубының «Татар теле һәм

яшьләр» темасына багышланган беренче утырышы үтә. Татар зыялы яшьләре дәүләт органнарына татар һәм рус телләрендә үз проблемаларын яктырткан телерадиотапшыру булдырырга, дәүләт оешмаларында татар телен куллануны камилләштерергә, татар милли университетын ачуны тизләтергә, махсус уку йортларын киңәйтү юлы белән татар халык һөнәрчелеген яңадан торгызырга ярдәм итәргә дигән тәкъдимнәр белән чыгалар.

17-18 апрель. Иваново шәһәрендә БТК БК һәм Татар Федераль милли-мәдәни мохтарияте советының берләштерелгән утырышында өлкәдә татар мәдәниятен, мәгарифен, туган телне, милли гореф-гадәтләрне торгызу мәсьәләләре карала.

21 июнь. РФ татар массакүләм мәгълүмат чаралары җитәкчеләренең семинар-киңәшмәсе үткәрелә.

28 июнь. Төмән шәһәрендә БТК БК бюросының һәм Татар Федераль милли-мәдәни мохтарияте советының берләштерелгән күчмә утырышы уза. Утырышта Төмән, Новосибирск, Томск һәм Омск өлкәләрендә себер татарлары мәдәниятен, мәгарифен үстерү мәсьәләләрен тикшерәләр.

29 август. ТР суверенлыгының 10 еллык юбилеена багышланган «Татарстанның эшлекле партнёрлары» форумы булып үтә. Россия Федерациясе һәм БДБ илләреннән килгән вәкилләр төбәкара икътисади элемтәләрне формалаштыру һәм үстерү турында резолюция кабул итәләр.

28 ноябрь. «Россия Федерациясеннән читтә яшәүче татарларның милли мәдәнияте үсешенең мөһим мәсьәләләре» дигән темага халыкара семинар-киңәшмә уздырыла.

4 декабрь. Яшел Үзән шәһәрендә «ТР районнарында һәм шәһәрләрендә яшәүче татар халкының туган телен саклау, мәгарифен һәм мәдәниятен үстерү буенча БТК БК җирле оешмаларының һәм дәүләт органнарының уртак эшләре» дигән темага күчмә утырыш була.

2001

26 апрель. БТК БКның ТР Дәүләт Советы белән берлектә үткәрелгән киңәйтелгән утырышында латин графикасына кайту мәсьәләләре карала.

18 май. Теләче районы Алан авылында «Теләче районында татар халкының борынгы йолаларын, милли гореф-гадәтләрен көнкүрешкә кайтару буенча БТК БКның Теләче җирле оешмасының дәүләт хакимияте органнары белән уртак эше» темасына багышланган күчмә утырыш үткәрелә.

Июнь. Саратов шәһәрендә Федераль Сабан туе бәйрәме булып уза.

11 июль. Ялта шәһәрендә БТК БКның Украинадагы «Туган тел» татар мәдәнияте үзәге һәм Киевтагы «Илдәш» татар җәмгыятенең берләштерелгән утырышы уздырыла. Украинадагы татар мәдәниятен, мәгарифен үстерү турында карарлар кабул ителә.

24 октябрь. Пермь шәһәрендә БТК БКның һәм Татар Федераль милли-мәдәни мохтарияте советының берләштерелгән күчмә утырышы үтә. Утырышта Пермь өлкәсе җирле хакимияте белән татар һәм башкорт милли-мәдәни автономияләренең татар халкының этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өлкәсендә уртак эшчәнлекләре тикшерелә.

30 октябрь. Татар хатын-кызларының «Ак калфак» берләшмәсе белән берлектә «Асылыбызга кайту юлында» дип исемләнгән конференция оештырыла. Анда гаиләне саклау, төбәкләрдә мәдәният һәм мәгариф системасын булдыру өчен матбугат чараларыннан, интернеттан файдалану, таныштыру үзәкләре булдыру кебек тәкъдимнәр карала.

28 ноябрь. Татар яшьләре иҗтимагый оешмалары семинары уза. Семинарда татарча аралашу мохитен

булдыру, Татарстан яшьләре белән үзара хезмәттәшлекне арттыру, татар интернет челтәрен булдыру, «Татар яшьләренең икътисади активлыгы» дигән программа эшләү, Татар милли университеты ачуны тизләтү һәм анда читтә яшәүче татарларны укырга җәлеп итү кебек карарлар кабул итәләр.

8 декабрь. Истамбул шәһәрендәге күчмә утырышта Төркиядә яшәүче татарларның милли-мәдәни тормышлары, Татарстан белән элемтәләре, милли үсеш перспективалары мәсьәләләре тикшерелә.

2002

21-23 март. Саратов шәһәрендә «Үсеп килүче яшь буынга үз ана телендә белем алу мөмкинлеге турында» дип исемләнгән Россия татар мәктәпләре мәгариф хезмәткәрләренең төбәкара фәнни-гамәли конференциясе оештырыла.

5 май. Нью-Йорк шәһәрендә БТК БК әгъзалары, Вашингтон һәм Нью-Йорк татарлары, Джорджтаун университеты профессорлары, АКШ стратегик тикшеренүләр үзәге белгечләре белән очрашып, бу илдәге гомуми вазгыять, милләттәшләребез тормышы белән таныша.

Июнь. Самара өлкәсе Тольятти шәһәрендә Федераль Сабан туе бәйрәме үткәрелә.

28-29 август. БТКның өченче съезды була. Съездга 21 чит илдән, Россиянең 57 төбәгеннән, Татарстанның 43 районыннан һәм Казанда яшәүче татарларның вәкилләре җыйнала. Анда РФ Президенты В.В.Путин да катнаша. «Татар халкының фәне, мәгарифе һәм мәдәнияте», «Хәзерге заман татар яшьләре һәм аларның киләчәге», «Татарстанның эшлекле партнёрлары» дип исемләнгән секцияләр эшли. Резолюциядә яңа бурычлар куела. Алар арасында татар халкын үстерү буенча гомумфедераль программа эшләү, Россия Федерациясендә татар мәдәнияте челтәрен саклап калу, эшкуарлык традицияләрен кайтару, Татарстан һәм татарлар яши торган башка төбәкләрдә мәдәни бәйләнешләрне җайга салу максатында заманча мәгълүмат чараларыннан файдалану, Казан каласының 1000 еллыгына хәзерләнү, Сабантуй милли бәйрәмен ЮНЕСКОның Халык авыз иҗаты һәм кешелекнең рухи мирасы җәүһәрләре исемлегенә кертү кебек мәсьәләләр була.

29 августта «Бөтендөнья татар конгресс» иҗтимагый берләшмәләренең халыкара берлеге БК рәисе һәм БТК БК рәисе итеп Закиров Ринат Зиннур улы сайлана.

3 октябрь. БТК БКын оештыру утырышы үткәрелә. Монда рәис урынбасарлары, БКның бюро әгъзалары, комиссияләрнең рәисләре сайлана, аларның эш юнәлешләре билгеләнә һәм составлары раслана.

30 октябрь. ТР Министрлар Кабинетының Татарстан халыклары телләрен үстерү бүлеге белән берлектә РФ төбәкләрендә тел ситуациясе турында «түгәрәк өстәл» оештырыла.

9 ноябрь. БТК БК рәисе Донецк шәһәрендә (Украина) татар милли-мәдәни берләшмәләренең җитәкчеләре белән очраша.

20 ноябрь. ТРның татар телендәге массакүләм мәгълүмат чаралары журналистлары катнашында «Татар халкын үстерү мәсьәләләрен яктыртуда массакүләм мәгълүмат чараларының эшчәнлеге турында» дигән «түгәрәк өстәл» булып уза. БТК БК каршында татар журналистларының даими эшли торган клубы оештырыла.

16 декабрь. 2002 ел йомгаклары һәм 2003 елга эш планнарына багышланган җыелыш үтә. Биредә милли-мәдәни оешмалардан 130 вәкил, Россия Федерациясе, Украина, Казахстан

мәгариф, фән, мәдәният хезмәткәрләре, ТР районнары һәм шәһәрләреннән конгрессның 250 активисты, татар зыялылары катнаша. Татар милләтен борчыган актуаль мәсьәләләргә багышланган «түгәрәк өстәл» оештырыла.

2003

4-7 февраль. Татар җәмгыяте оешмалары, милли-мәдәни мохтарият эшчәнлеге белән танышу, татар теле, әдәбиятын өйрәнүнең торышы һәм татар мәгариф, мәдәният оешмаларына методик ярдәм күрсәтү максатыннан, БТК БК рәисенең беренче урынбасары И.Г.Һадиуллин җитәкчелегендәге делегация Свердловск өлкәсендә була. Анда татар телен саклау һәм үстерү, мәктәпләрне дәреслекләр, методик әсбаплар белән тәэмин итү, укытучыларны әзерләү, ТР югары уку йортларына укырга кергәндә ташламалар кертү, «Татарстан — Яңа Гасыр» телевидениесе әзерләгән тапшыруларны спутник аша кабул итү, милли оешмаларның эшчәнлеген координацияләү кебек мәсьәләләр карала.

14-16 апрель. Мәгариф министрлыгы, Бөгелмә шәһәре һәм район хакимияте белән берлектә «Бөгелмә районы мәгариф учаклары мисалында милли белем һәм тәрбия бирүне үстерү» дигән темага күчмә утырыш уза.

14 июнь. Ульяновск өлкәсе Димитровград шәһәрендә Федераль Сабантуй бәйрәме үткәрелә.

6 август. БТК БК каршында эшләп килүче юридик төркемнең адвокаты Р.А.Фәрдиева җитәкчелегендәге делегация, Чиләбе өлкәсенә барып, ватандашларыбызның хокукларын яклау, мәхкәмәләрдә катнашу нәтиҗәләре буенча матбугат конференциясе үткәрә.

6 октябрь. Ульяновск өлкәсе Иске Кулатка районында «Мәдәният, мәгариф, эшмәкәрлек өлкәсендә Ульяновск өлкәсе татар мәдәни оешмаларының хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлеге» турында БТК БКның күчмә утырышы уза.

13-14 ноябрь. «XXI гасырда татар халкы һәм массакүләм мәгълүмат чаралары» дигән форум үтә.

2004

20 февраль. БТК БК рәисе Р.З.Закиров Димитровград шәһәре милли-мәдәни мохтарияте оештырган юбилей чараларында катнаша һәм шәһәр мэры С.И.Морозов белән очраша. Очрашу вакытында татар гимназиясе ачу турында сөйләшү алып барыла.

15-18 март. Сабантуй бәйрәмен оештыручылар һәм режиссёрлар катнашында «Татар халкының милли бәйрәме Сабантуйларны оештыру һәм үткәрү методикасы һәм технологиясе» исемле семинар була.

27 апрель. Татар тарихчысы Газиз Гобәйдуллинның тормышы һәм гыйльми эшчәнлегенә багышланган «түгәрәк өстәл» үтә.

24-28 июнь. I Бөтендөнья Татар яшьләре форумы уздырыла.

26 июнь. Мари Эл Республикасы башкаласы Йошкар-Ола шәһәрендә Федераль Сабантуй бәйрәме уздырыла.

19 ноябрь. «Милли үзаң тәрбияләүдә татар хатын-кызларының роле һәм урыны: тәҗрибә һәм проблемалар» дип аталган конференция үткәрелә. Бу чарада РФнең 40 төбәгеннән 186 хатын-кыз катнаша.

2005

БТК ел дәвамында төрле фәнни конференцияләр оештыруда катнаша. Мәгарифне үстерү институты белән берлектә «Бөек Ватан сугышы. 1941-1945 еллар. Заман яшьләренә патриотик тәрбия бирү» (21-22 март), Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих инсти-

туты белән берлектә «Россиядә татар мөселман мәхәлләләре» (27-28 сентябрь), «Татар иҗтимагый хәрәкәте: тарихи тәҗрибә һәм бүгенге көн» (12 декабрь), Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән берлектә «Төрек-татар мәдәни хезмәттәшлеге» (9-11 сентябрь), ТДГПУ белән берлектә «Татарстанда һәм Идел-Урал регионында тарихи-архитектура тикшеренүләре һәм музей эшчәнлеге» (9 декабрь) дигән темага фәнни-гамәли конференцияләр оештырыла.

Июнь. Түбән Новгород шәһәрендә Федераль Сабантуй бәйрәме үткәрелә.

25 ноябрь. ТР Мәгариф министрлыгы белән берлектә Пенза өлкәсе мәктәпләрендә Татар мәгарифе көннәре уздырыла.

26 ноябрь. Алма-Аты шәһәрендә Казанның 1000 еллыгына багышланган «Дуслык күпере» дигән чара уза.

13 декабрь. «Татарларның заманча яшәү стратегиясе» дигән темага киңәйтелгән утырыш була.

24 декабрь. Татарстан Милли көрәш федерациясе белән берлектә Яр Чаллы шәһәрендә милли көрәш буенча Бөтенроссия чемпионаты уздырыла.

Бу елда «Татарча көрәш» милли спорт федерациясе оештырыла, 2006 елда ул РФнең Юстиция министрлыгында теркәлә.

2006

20 февраль. «Татар гаиләсе» Бөтенроссия иҗтимагый фонды РФ Юстиция министрлыгында теркәлә.

4-6 март. ТР Язучылар берлеге белән Пермь өлкәсендә «татар әдәбияты көннәре» үткәрелә.

27-30 март. ТР Мәгариф һәм фән минстрлыгы белән берлектә татар теле һәм әдәбияты укытучыларының IV Бөтенроссия съезды уза. Съездда РФнең 38 төбәгеннән, БДБнең 6 иленнән барлыгы 580 вәкил катнаша.

21-25 июнь. II Бөтендөнья яшьләр форумы үтә.

2 июль. Мордовия Республикасы башкаласы Саранск шәһәрендә Федераль Сабантуй бәйрәме уздырыла.

1 декабрь. Екатеринбург шәһәрендә БТК бүләгенә милли көрәш буенча «Урал кубогы» зональ турниры булып үтә.

2007

5-14 гыйнвар. Красноярск краенда татар теле һәм әдәбияты укытучыларының квалификацияләрен күтәрү курслары оештырыла.

24-25 февраль. Әстерханда «Татар моңнары» дип исемләнгән татар җырлары фестивале үткәрелә.

6-7 апрель. Новосибирск шәһәрендә Себер федераль округында татар сәнгатенә багышланган IV Төбәкара «Себер йолдызлары» фестиваль-конкурсы оештырыла.

9-10 апрель. I Бөтендөнья татар галимнәре форумы уза.

30 июнь. Чиләбе шәһәрендә Федераль Сабантуй бәйрәме үтә.

28-30 август. БТК БКда татар иҗтимагый оешмалары җитәкчеләренең РФ белән ТР арасындагы вәкаләтләрне бүлешү турындагы Шартнамәне гамәлгә ашыру юлларын билгеләү, Россия төбәгендәге милли мәгариф проблемаларына багышланган Бөтенроссия киңәшмәсе уза. Анда РФнең 60 төбәгеннән 120, ТРнан 100 кеше катнаша.

12-15 декабрь. БТКның IV съезды үтә. Съезд эшендә 30 илдән, Россиянең 63 төбәгеннән 775 делегат һәм 200ләп кунак катнаша. Форумга Әфганстан, Израиль, Словакия, Көньяк Африка Республикасы татар җәмгыяте вәкилләре беренче мәртәбә киләләр. Съезд кысаларында ТРның РФ төбәкләре һәм чит илләр белән сәүдә-икътисади хезмәттәшлеге турында «түгәрәк өстәл», татар халкы

мәдәниятен, мәгарифен саклау, хәйриячелек һәм яшьләр проблемаларына багышланган секцияләр эшли. Резолюция кабул ителә.

2008

18 май. Әстерхан шәһәрендә Федераль Сабантуй бәйрәме уза.

22-24 май. Актанышта зур татар авыллары ассоциациясен оештыруга багышланган конференция үткәрелә. («Бөтенроссия татар авыллары» иҗтимагый оешмасы 2010 елның 23 июнендә Россия Федерациясенең Юстиция министрлыгында теркәлә).

26-30 август. III Бөтендөнья татар яшьләре форумы була.

17 октябрь. Ульяновск шәһәрендә «Туган телне укыту һәм милли мәгариф системасын камилләштерү мәсьәләләре буенча Ульяновск өлкәсе татар иҗтимагый оешмаларының җирле дәүләт органнары белән эшләү тәҗрибәсе» темасына БТК БКның күчмә утырышы уздырыла.

20-24 октябрь. Ульяновск өлкәсе Иске Кулатка районында Татар фольклор дәүләт үзәге белән берлектә I Бөтенроссия татар фольклор коллективларының «Түгәрәк уен» фестивале үткәрелә.

4-5 ноябрь. Семипалатинск шәһәрендә «Иртыш моңнары» IX Халыкара татар сәнгате фестиваль-бәйгесе уза.

20-21 декабрь. «Татар моңы» Халыкара телевизион яшь башкаручылар бәйгесенең зона туры үтә.

2009

7 февраль. ТР Чүпрәле районы Мунчали һәм Иске Кәкерле авылларында Бөтендөнья татар яшьләре форумының күчмә утырышы була. «Яшьләрнең татар авылларын, милли тормыш рәвешен саклау һәм үстерүдәге урыны һәм роле» темасына «түгәрәк өстәл» уздырыла.

28 февраль. Төмән шәһәрендә «Таң йолдызы» балалар өлкә фестивале үтә.

20-21 март. Азнакай шәһәрендә спорт мастеры А.Шакиров истәлегенә багышланган милли көрәш буенча Республика турниры уза.

4 июль. Ульяновск шәһәрендә Федераль Сабантуй бәйрәме үткәрелә.

24-27 сентябрь. Төмәндә Татар фольклор дәүләт үзәге белән берлектә II Бөтенросссия татар фольклоры фестивале уза. Фестивальдә Татарстанның Казан, Түбән Кама шәһәрләреннән, Питрәч, Саба районнарыннан; Самара, Ульяновск, Чиләбе, Омск, Әстерхан, Екатеринбург өлкәләреннән, Мари Эл, Чувашстан, Удмуртия республикаларыннан, Төмән өлкәсенең Тубыл, Ялутор, Сургут шәһәрләреннән, Түбән Тәүде, Ялутор, Вагай, Тубыл районнарыннан барлыгы 500ләп кеше, 30дан артык коллектив катнаша.

Декабрь. Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе оеша.

2010

19-20 февраль. Чувашстанда «Урмай моңы» Халыкара татар эстрада фестивале уздырыла.

29 май. Самара өлкәсе Похвистнево районы Гали авылында I Бөтенроссия авыл Сабан туе уза. Анда Россиянең утызга якын төбәгеннән вәкилләр, Кытай Халык Республикасыннан килгән татар оешмалары делегацияләре катнаша.

3 июль. Урдмуртия Республикасы Ижевск шәһәрендә Федераль Сабантуй үткәрелә.

27-31 август. IV Бөтендөнья татар яшьләре форумы уза.

15-18 сентябрь. I «Милли тормыш һәм дин» Татар мөселман дин әһелләре форумы үтә.

28-30 сентябрь. Казанда ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә татар теле һәм әдәбияты укытучылары, этномәдәни (татар) компонентлы белем бирүче мәктәп җитәкчеләренең V Бөтенроссия корылтае уздырыла.

2011

22 февраль. БТК БКның конференцияләр залында Оренбург, Түбән Новгород өлкәләре, Пермь крае, Башкортстан, Чувашстан һәм Татарстаннан килгән татар теле укытучылары, мәктәп директорлары белән очрашу уза.

12 март. Самара өлкәсенең Гали авылында «Туган тел», «Бөтенроссия татар авыллары» оешмалары белән берлектә III «Халкым минем» иҗат фестивале үткәрелә.

23 апрель. Самара өлкәсе Камышлы районында беренче тапкыр «Әйләнбәйлән» төбәкара татар милли бию фестивале була.

15-18 июнь. II Бөтенроссия «Милли тормыш һәм дин» татар мөселман дин әһелләре форумы үтә. Анда Россиянең илледән артык төбәгеннән 843 дин әһеле катнаша.

2 июль. Свердловск өлкәсе Екатеринбург шәһәрендә Федераль Сабантуй бәйрәме үткәрелә.

30 сентябрь-1 октябрь. «Тарих һәм бүгенге заман» дип аталган татар галимнәре форумы уздырыла.

2012

13 март. БТК бинасының утырышлар залында «Татар атлары» ассоциациясе тәкъдиме буенча киңәшмә уза.

23-25 март. Беренче Бөтенроссия татар авыллары эшкуарлары җыены үтә. Җыенга РФнең 27 төбәгеннән 400ләп вәкил килә.

24 апрель. К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында Бөтенроссия «Туган тел» форумы була.

8-10 июнь. III Бөтенроссия «Милли тормыш һәм дин» татар мөселман дин әһелләре форумы уздырыла.

1 июль. Приморье крае Владивосток шәһәрендә Федераль Сабантуй үткәрелә.

27-31 август. V Бөтендөнья татар яшьләре форумы уза.

Чыганаклар:

1. Бәдретдинов Х. Татарстаннан читтәге татарларга нәрсә җитми: [Бөтендөнья татар конгрессы эшләре, читтә яшәүче татарлар.] // Шәһри Казан. — 2001. — 5 сентябрь.

2. Бәдриев Д. «Зур Татарстан» киңлеккә чыга // Шәһри Казан. — 2000. — 31 март.

3. Бөтендөнья татар конгрессы (беренче чакырылыш): стенографик хисап. — Казан: Татарстан Министрлар кабинеты басмасы, 1992.

4. Бөтендөнья татар конгрессы (икенче чакырылыш): стенографик хисап. — Казан: Бөтендөнья татар конгрессы басмасы, 1998.

5. Бөтендөнья татар конгрессының III корылтае материаллары. — Казан: Бөтендөнья татар конгрессы басмасы, 2003.

6. Биктимирова Т., Ягъфәров Р. Безгә сукмак бик такыр: Бөтендөнья татар конгрессының эшләре тур. // Татарстан хәбәрләре. — 1995. — 16 июнь.

7. Бөтендөнья татар конгрессы — Санкт-Петербургта // Шәһри Казан. — 1998. — 24 апрель.

8. Гайнуллин Х. Ватан кайдан башлана? [Кырымда үткән Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының киңәйтелгән бюро утырышы] // Ватаным Татарстан. — 2001. — 7 сентябрь.

9. Җиһаншина М. Оялмаслык булсын иде: [Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты бюросының киңәйтелгән күчмә утырышы Яшел Үзән шәһәрендә] // Мәдәни җомга. — 2001. — 26 гыйнвар.

10. Кашапова М. Ил анасы — «Ак калфак» // Сөембикә. — 1997. — №10. — Б.20-21.

11. Каюмов Р. Азнакайда академиклар гына яши // Мәдәни җомга. — 1998. — №2. — 9 гыйнвар.

12. Күчмә утырыш — Санкт-Петербургта. // Татар иле. — 1998. — Май (№17).

13. Күчмә утырыш — Санкт-Петербургта. // Ватаным Татарстан. — 1998. — 24 апрель.

14. «Мәдәнилек, әхлак өстенлек иткән милләтнең генә киләчәге бар» [Чаллы Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының күчмә утырышы] // Мәгърифәт нуры (Чаллы). — 1997. — 25 ноябрь.

15. Минһаҗ Р. Дәүләт ярдәме кирәк: [Бөтендөнья татар конгрессы бинасында Татар милли-мәдәни мохтариятләре федераль советы утырышы] // Ватаным Татарстан. — 2000. — 28 апрель.

16. Минһаҗ Р. Тамырлары тирәндә // Ватаным Татарстан — 1999. — 6 апрель.

17. Миңнуллина Ә. Сөйләшмәгәч, кирәген дә тоймыйлар // Ватаным Татарстан. —1998. — 11 апрель.

18. Низамиев М. Берләшү юлында: [татар диаспорасы. Бөтендөнья конгрессы башкарган эшләр] / М.Низамиев, Л.Мөхәррәмова // Мирас. — 1999. — №8. — Б.92-112.

19. Татар конгрессы Санкт-Петербургта // Мәдәни җомга. — 1998. — №17. — 24 апрель.

20. Таһиров И. Анда татарның тамыры тирән: [АКШта Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты утырышы. Шул тур. аның рәисе Индус Таһиров б-н әңгәмә] // Ватаным Татарстан. — 2002. — 18 май.

21. Таһиров И. Милләт язмышын кайгыртып: [1994 елның 24-25 июнендә Казанда Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының киңәйтелгән утырышы] // Татарстан. — 1994. — №9-10. — Б.3-10.

22. Таһиров И. Чәчелсәк тә, сибелсәк тә, бер булыр кыйблабыз: [Бөтендөнья татар конгрессы эше тур.] // Мәдәни җомга. — 2002. — №34. — 23 август.

23. Туфитулова Р. Санкт-Петербург татар моңын юксына // Сөембикә. — 1998. —№6. — Б.6-8.

24. Урал якларына эшлекле сәясәт: Екатеринбург шәһәрендә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының күчмә утырышы булды // Татарстан хәбәрләре. — 1994. — 29 октябрь.

25. Харрасова Л. Күчмә утырыш — АКШта // Ватаным Татарстан. — 2002. — 8 май.

ТР Үзәк дәүләт тарихи-сәяси документлар архивы ф.8260 Исполком Всемирного конгресса татар, г.Казань (хәбәрләр, көндәлекләр, протоколлар).

2002-2012 елгы мәгълүматлар Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетыннан алында.

*Басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.*

Бу текстны басмага хәзерләгәндә күрсәткән ярдәмнәре өчен «Чын мирас» журналы иҗат төркеме Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Тәәминә Әхмәт кызы Биктимеровага, ТР Үзәк дәүләт тарихи-сәяси документлар архивы директоры Венера Гарифулла кызы Хәмидуллинага, Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты аппараты җитәкчесе Миләүшә Әмин кызы Гомәровага олуг рәхмәтен белдерә. ■



СӘНГАТЬ

Шәхеснең көче —
күңел канатларында.

Шәүкәт Галиев

РАУЛЬ МИР-ХӘЙДӘРОВ,
прозаик

СТАЛИН ЛАУРЕАТЫ

(Әдәби портрет)

XX ГАСЫР АХЫРЫНДА ТАТАРСТАН СУВЕРЕНЛЫГЫНА ЗУР ӨМЕТЛӘР БАГЛАУ БЕЛӘН БЕРРӘТТӘН, ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ҮЗ ТАРИХЫ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕНӘ КЫЗЫКСЫНУ ДА КӨЧӘЙДЕ. ТАТАРЛАР ӨЧЕН ГЕНӘ ТҮГЕЛ, БӨТЕН ДӨНЬЯГА БИЛГЕСЕЗ, Ә ВАКЫТЫ БЕЛӘН УЗГАН ГАСЫРНЫҢ ОНЫТЫЛГАН КҮРЕНЕКЛЕ ВӘКИЛЛӘРЕНЕҢ ИСЕМНӘРЕН КАЙТАРГАН ЖУРНАЛИСТ ҺӘМ ЯЗУЧЫЛАРГА ЛАЕКЛЫ БӘЯЛӘРЕН БИРЕРГӘ КИРӘК.

Минем дә киң катлау укучыларга бөтен дөньяга күренекле Рудольф Нуриев, Чыңгыз Айтматов, Софья Гобәйдуллина, Ирек Мөхәммәтов исемнәре янәшәсендә торырлык шәхес турында сөйләп, үз өлешемне кертәсем килә. Каһарманым — дөнья сәнгатендә якты эз калдырган, тугандаш мөселман мәдәниятенә үзенең зур өлешен керткән талантлы шәхес. Аның язмышы турында уйланып утырганда, Ялтада танышып, гомер буе дустанә мөнәсәбәттә булган күренекле фронтовик-язучы Нәби Дәүлинең моңсу гына сөйләгәне искә төште: «Татар язучыларыннан кемне генә алма, Тукайдан башлап барысы да диярлек авыр балачак юлы үткән, ятимлек, атасызлыкны үз җилкәсендә татыган шәхесләр. Хәерчелек, авыр хезмәттә үткән балачак, ФЗУ, ПТУ, җидееллык мәктәп, техникум, читтән торып уку бүлеге… Иң авыр чор — инкыйлаб, чит-ят җирләргә сөрелү, ачлык, сугыш, үзгәртеп кору, чуалыш елларында халкыбызның 80 %ы бөтен дөньяга чәчелә. Үземдә дә шул ук язмыш».

Аңа кушылып: «Миндә дә шул ук язмыш», — дип өсти генә алам. Нәби Дәүлигә мин татар әдәбиятына һәм язучыларына өр-яңа күзлектән карарга өйрәтүе белән рәхмәтле. Миңа инде хәзер ни өчен прозабызның кырыс, коры, романтик хисләрдән ерак торганы аңлашыла.

Ни өчен шулай әйтәмме? Бары тик 11 балалы гаиләдә бәхетле балачак кичергән каһарманымның тормышын күләгәдә калдыру өчен генә. Якты истәлекләргә бай үсмер еллары, укымышлы, мәдәният белән бәйле булган зыялылар арасында узган яшьлек,

Пермь, Мәскәү, Сәмәрканд кебек эре шәһәрләрдә алган киңкырлы белем, 50 нче еллардан башлап бөтен дөньяны иңләгән сәяхәт, хезмәттә үткән гомер — болар барысы да сокландыргыч тормыш юлы турында сөйли.

Сүз күренекле рәссам-монументалист, рәссам-портретчы, рәссам-миниатюрачы, профессор, йөзләгән укучыларны тәрбияләгән педагог, гомере буе Феофан Грек, Давид Сикейрос, Диего Ривера, Ороско фрескалары белән тиңләштерелгән фрескалар остасы, Үзбәкстан һәм Татарстанның халык рәссамы, академик Алексей Щусев проекты буенча төзелгән Нәвои исемендәге Үзбәкстан опера һәм балет академия театрының интерьерын булдырганы өчен 1948 елда бирелгән беренче дәрәҗәле Сталин премиясе лауреаты, сәнгать белемендә бөек рәссамнарның бик сирәге генә булдыра алган, «Әхмәров мәктәбе»нә нигез салучы шәхес турында.

Аңлагансыздыр, сүзем Чыңгыз Габдерахман улы Әхмәров турында. Мин аның белән яхшы таныш идем.

Чыңгыз Әхмәров 1912 елның 12 маенда Троицк шәһәрендә дөньяга килә. Ул елларда шәһәр халкының күп өлешен казах, татар, башкорт, үзбәкләр тәшкил итә. Шәһәрнең мөселманнар яши торган өлкәләрендә имам исемен йөрткән 8 мәхәллә, аларның һәрберсендә мәчет була.

Чыңгыз абый туган мәхәллә Габдерахман Рахманколов исемен йөртә. Әхмәровлар гаиләсендә 11 бала булу өстенә ике як әбиләре һәм бабалары да алар белән бергә яши. Гаилә архивларында бик күп фоторәсемнәр сакланган. Гаиләләрендә Чыңгыз абый кебек күренекле шәхес тумаган булса да, киләчәк буын тарихчылары, укымышлылары, язучылары өчен әлеге нәсел зур кызыксыну уятыр иде. Чөнки Беренче революциягә кадәрге бу зыялы татар гаиләсе мәктәп, мәдрәсәләр ачкан, мәчетләр салган, китапханәләр булдырган, типография төзегән, газета чыгарган, гомумән, халыкка аң-белем тараткан.

Бу буш сүзләр генә түгел, моны раслый торган язма документлар, фотолар, гаилә әгъзаларының мемуарлары бар.

Әхмәровлар гаиләсенә югары мәдәни зәвык XIX гасырдан ук килә. Мифтахетдин бабаларыннан, кулъязма, литографик китаплар һәм күптөрле журналларны туплаган бай китапханә кала. Чыңгыз балачактан ук «Мулла Насретдин» журналыннан рәсемнәрнең күчермәсен ала, апасына ияреп, шигырьләр белән мавыга, пианинода уйный, кунаклар чакырып, өйдә спектакльләр куялар, әдәби кичәләр оештыралар. Чыңгыз абый үзе моны Троицк шәһәрендә укымышлы татар гаиләләрендә традицион күренеш дип искәртә.

Чыңгыз абыйның әтисе — Габдерахман хаҗи бай сәүдәгәр Гали Уразаевта вәкил булып хезмәт иткән. Эшләре буенча аңа Мәскәү, Казан, Оренбург, Түбән Новгород, Якын Көнчыгыш илләрен, Согуд Гарәбстанын, Балтыйк буйларын, Көнчыгыш Европа илләрен гизәргә туры килә. Сәяхәте вакытында Гали Уразаев, сәүдә йортының эшләрен үтәп кенә калмыйча, җирле зыялылар, мәдәният эшлеклеләре белән аралаша, илдә алдынгы идеяләр, вакыйгалар белән кызыксына. Габдерахман хаҗи алган тәэсирләрен «Гаилә тарихы» дигән кулъязма китабына теркәгән. Бәхетебезгә, ул китап бүгенгә кадәр сакланган.

Чыңгыз абыйның әнисе Сөхибә апа Алтын Урда ханнарына патша сарайларында хезмәт иткән күренекле шәхесләр нәселеннән.

4 яшендә Чыңгыз балалар бакчасына, ә җиде яшеннән абыйлары укыган мәктәпкә йөри башлый. Хаҗи Габдерахман абый кызларына да белем бирергә омтыла — алар Өчбиби авылы мәктәбендә, аннан Троицк гимназиясендә укыйлар, өйләрендә тирән белемле рус ханымнарыннан музыка дәресләре алалар.

Габдерахман абыйның кульъязма китабында үзенең яшьлек елларында дөньяга карашы формалашуы турында язылган юллар бар. Патша армиясенең Казан фельдшерлар мәктәбендә укыганда, ул яшь еврей Мейр Швеер белән таныша. Швеер киңәшен тыңлап, «Вестник Европы», «Русская мысль», «Русское богатство» журналларын карап бара, Лев Толстойның «Война и мир», «Анна Каренина» романнарын укый. Шул елларда Бакуда чыга торган «Каспий» газетасы беренче тапкыр Казанга китерелә башлый. 1902 елда Троицкида фикердәшләре белән «Хезмәт» китабын бастыру өчен җәмгыять оештыра, ә 1909 елда беренче мөселман кызлары өчен мәктәп ача.

Чыңгызның 6 яшенә Гауфның Дмитрий Митрохин иллюстрациясе белән бизәлгән «Маленький Мук» китабын бүләк итәләр. Нәкъ 60 елдан Чыңгыз абый Мәскәүдә узган рәссамнар җыелышында әлеге иллюстратор белән очраша. Митрохин рәсемнәре анда рәссам булу теләген уяткан. Утырыш вакытында Чыңгыз үзенең балачак кумирына мөрәҗәгать итәргә теле, ләкин батырлыгы җитми. Бу аңлашыла да — Чыңгыз абый артык тыйнак, әдәпле, йомшак күңелле була.

Чыңгызның әтисе Габдерахман хаҗинең Троицкидагы узган гасыр башы тормышы турындагы язмалары кызыклы. Габдерахман абый фикеренчә, шәһәрнең мөселман җәмгыяте кискен ике төркемгә бүленә: «иске карашлы» һәм «җәдитчеләр». Җәдитчеләр төркеме «Җәмгыяте хәйрия» (хәйриячелек җәмгыяте) һәм «Нәҗят» (ярдәм) китапханәләре тирәсендә оеша. Габдерахман хаҗи эре җирбиләүчеләр, бай сәүдәгәрләрне, нигездә, җәдитчеләр ягында булалар, дип ассызыклый. Троицк җәдитчеләренең күпчелеге Европа халыклары мәдәниятен өйрәнә, хәзерге термин белән әйткәндә, көнбатышчылар рәтенә керәләр.

1925 елда, Чыңгыз 5 сыйныфта укыганда, Троицкига Мәскәүдән инкыйлаБашкарма комитета кадәр Истанбул университетын тәмамлаган, Мәгърифәтчелек комиссариатының Көнчыгыш халыклары мөдире Хәбибзәйни ага Хәлилев килә. Чыңгыз аны күрүгә, портретын ясый һәм бу Хәбибзәйни агага бик ошый, кечкенә егетне үзе белән Мәскәүгә алып китәргә тели. Ләкин яшь малайның әти-әнисе ялгызын чит җиргә чыгарып җибәрергә җөрьәт итмиләр.

1927 елда 15 яшьлек Чыңгызны Пермь сәнгать училищесына чакыралар. Халык мәктәпләре инспекторлары күптән инде Троицкиның талантлы укучысына игътибар иткән булалар. Әле генә гражданнар сугышын кичкән яшь совет иле халыкка белем алу зарурлыгын аңлый. Пермь

училищесына кабул итү имтиханнарында Чыңгыз И.А.Крыловның «Ворона и лисица» мәсәленә иллюстрация ясый. Егет уңышлы гына җавап тота һәм укырга керә.

Шулвакытта әтисенә, сәламәтлеге начараю сәбәпле, табиблар климатны үзгәртергә киңәш итәләр, һәм Әхмәровлар гаиләсе Үзбәкстандагы Карши, аннан элекке җәдитче татар сәүдәгәрләре арасында күп кенә танышлары булган Сәмәрканд шәһәренә күчәләр.

Пермьдә укыганда, яшь рәссам Россиядә күренекле саналган опера һәм балет театрына еш йөри. Анда 70 нче елларда зур талант иясе Надежда Павлова чыгыш ясый, бөтен дөньяны гизгән күренекле балет төркеме оеша.

Менә сиңа Пермь! Чыңгызның иң яраткан операсы — Направникның «Дубровский»е була. Бервакыт Пермьдә узган әдәбият кичәсенә Владимир Маяковский килә. Шәһәрдә ни булганын күз алдыгызга китерәсездер!.. Безнең каһарман ничек итсә итә, ләкин бу кичәгә эләгә, озак еллардан соң да кичәнең нечкәлекләренә кадәр хәтерли.

Каникул вакытларында ул һәрвакыт Үзбәкстанга әти-әнисе янына кайта. Беренче тапкыр Каршига басмачылар белән көрәш барган елларда кайта. Үзбәкстанда аңа заман рәссамнарының күпләп рәсемнәрен бастырган «Янги юль» («Яңа юл») журналы ошый. Әтисе сайлаган өлкә яшь рәссамга башка төс, башка горизонт ача һәм ул, гадәттәгечә, бик күп ясый. Бервакыт үзенә иң ошаган өч хезмәтен ул журналга җибәрә. Редакциядән аңа күчереп ясалган рәсемнәрне бастырырга урын юк, бары оригиналларны гына кабул итәбез, дип хат килә. Хатка рәсем сәнгатендә якты эз калдырган шәхесләр — күренекле рәссам Усто Мумин, Александр Волковлар кул

куйган була. Бүгенге көндә аларның хезмәтләрен дөньяның иң зур музейларында, мәшһүр коллекцияләрдә, абруйлы аукционнарда очратырга була.

Күп еллардан соң Чыңгыз Әхмәров Усто Мумин белән бергә «Кызыл Үзбекистон» газетасында эшләгәндә, аннан үзенең рәсемнәрен ни өчен күчермә дип уйлавы турында сорый. Усто Мумин Кашкадәрья кебек ерак провинциядә шундый сәләтле рәссам булуга ышана алмый, әлбәттә. Ул вакытта әле Чыңгызга бары 16 яшь кенә була. Чыңгыз 1931 елда Пермь сәнгать училищесын тәмамлый. Диплом эше шәһәр драма театрында Ф.Шиллерның «Коварство и любовь» трагедиясенә декорацияләр ясау була. Бу хезмәтләреннән соң аны күп җирләргә эшкә чакыралар. Ләкин 19 яшьлек Чыңгыз әти-әнисе янына ашкына, Сәмәркандка кайтып китә. Сәмәрканд аның өчен туган шәһәре кебек якын, кадерле изге җиргә әверелә. Салкын Пермьдә Сәмәрканд аның төшләренә керә.

1931 елда диплом алгач, Чыңгыз Гүр Әмирендәге Тимур Мавзолее белән үзенә җәлеп иткән Сәмәркандына кайта. Узган гасырның 30 нчы елларында Александр Неверовның күп

кенә шау-шу уяткан «Ташкент — город хлебный» романы дөнья күрә. Бу роман аркылы миллионлаган халык Үзбәкстанның Бохара, Сәмәрканд, Хивә, Коканд кебек искиткеч гүзәл шәһәрләре белән таныша, үзбәк халкының юмартлыгы һәм кешелеклелеге турында белә. Әлеге хезмәт 50 тапкыр басылып чыга һәм озак еллар иң яхшы китаплар исемлегендә йөри. Генерал Скобелев вакытыннан рус рәссамнарын Көнчыгыш, Урта Азия кызыксындыра. В.Верещагин да Россиягә зур танылу алып килә. Ул елларда Сәмәркандта күп кенә Россия рәссамнары яши. Төрле юллар белән Сәмәркандка килеп эләккән рәссамнарның күбесе ябык мәдрәсәләрдә көн күрәләр. Революциягә кадәр мөселман дөньясының рухи үзәге булган Сәмәркандта мәдрәсәләр күп була.

Кырыс чор, ләкин шунысы кызыклы: хакимият язучы, шагыйрь, артист, музыкант, рәссам кебек сәнгать һәм мәдәният кешесенә хөрмәт белән карый. Борынгыдан ук Сәмәркандта күпләп әрмәннәр дә яши. Алар арасында Варшан Еремян, Оганес Татевосян, Рубен Акбольян, Микаэл Калантаров кебек рәссамнар була. Алар фарсы һәм үзбәк телләрен яхшы беләләр. Чыңгыз үзе дә бу телләрне тиз өйрәнә.

Әхмәровның Сәмәркандка кайткан елында Павел Беньков һәм Зинаида Ковалевская җитәкчелегендә сәнгать техникумы ачыла. Анда Петербург һәм Мәскәүдән килгән академик белемле рәссамнар укыта. Чыңгыз мәктәптә сызым һәм рәсем дәресләрен укыта башлый. Тиздән Сәмәрканд рәссамнары Оганес Татевосян җитәкчелегендә «Изофабрика» (сәнгать фабрикасы) дигән артель оештыра. О.Татевосян Чыңгызга гел заказлар биреп тора, алар арасында гомерлек дуслык җебе сузыла.

Сәмәрканд рәссамнары арасында иң яше Әхмәров була. Ул «Изофабрика»чылар белән дә, сәнгать техникумында укытучы иректә рәссамнар белән дә аралашып тора, алардан сәнгать тарихы буенча лекцияләр ала. Сәмәркандта Париждан Лувр, Италиядән Прадо, Уффици музейларын үз күзләре белән күргән рәссамнар да була. Чыңгыз күбрәк укыган саен, зур музейлар тарихы, мәдәният сулышы белән кызыксына. Тиздән ул Сәмәркандта алган аң-белем белән генә канәгатьләнми башлый.

1934 елның маенда, мәктәптә дәресләр беткәч, Чыңгыз Ташкентка башкала рәссамнарына үзенең иҗат эшләрен күрсәтергә бара. Аны бик шатланып каршы алалар, берьюлы «Колхозный путь» һәм «Юный ленинец» газеталарына эшкә чакыралар.

Газета, журналда эшләү Чыңгызны Усто Мумин, Борис Жуков, Урал Тансыкбаев, Александр Волков кебек рәссамнар белән якынайта. 22 яшьлек Чыңгызга шундый күренекле шәхесләр белән аралашу дөньяга, мәдәниятә карашын формалаштырырга ярдәм итә. Язучы, шагыйрь, рәссам, театр хезмәткәрләре, артистлар, кинорежиссёрлар арасында йөреп, белеменең тиешле дәрәҗәдә булмавын аңлый, күренекле шәхесләр белән бер дәрәҗәгә күтәрелү теләге артканнан-арта. Әхмәров сәнгатьтә үз урынын табырга омтыла.

Ул актриса һәм җырчы, СССРның халык артисткасы Хәлимә Закирова, Кәрим Закиров, Совет сәхнәсенең Отеллосы — яшьтәше Шөкер Борһанов, Абдулхак Абдуллаев белән аралаша. Манон Уйгур, Камил Яшен, Сара Ишантураеваларның өйләрендә еш була. Әлеге елларда Мәкъсуд Шәйхзадә белән озак елларга дуслыгы ныгый.

1935 елда Ленинградның сәнгать





институтына укырга керү теләге белән документларын һәм хезмәтләрен җибәрә. Конкурс бик зур була, һәр абитуриент артында күренекле рәссам тора. Ләкин Чыңгыз бирешергә уйламый. Ул үзенең хезмәтләрен алып Мәскәүгә Сәмарканд һәм Ташкентта исемнәре еш ишетелгән рәссамнар Лев Бруни һәм Владимир Фаворский янына киңәш сорап бара. Совет китапларын төзүгә нигез салучы В.Фаворский Изоинститутның үзе җитәкләгән графика факультетына керергә тәкъдим итә. Аның югары белем алу теләге чынга аша. Институт, аспирантура — җиде ел эчендә Чыңгыз Мәскәү кешесенә әйләнә.

1938 елда Чыңгыз өченче курста укыганда, Суриков исемендәге Изоинститутны рәссам, галим, академик Игорь Грабарь җитәкли. Озакламый рәсем сәнгате һәм скульптура факультеты ачыла. Сынлы һәм монументаль сәнгать белән мавыккан Әхмәров рәсем сәнгате факультетына — Пётр Покаржевский остаханәсенә күчә. Аңа бары икенче курска күчәргә рөхсәт ителә. Ләкин ул моның өчен бер дә үкенми. Бишенче курста ул академик И.Грабарь һәм профессор Николай Чернышов җитәкләгән монументаль сәнгать остаханәсенә күчә. Чыңгыз Игорь Грабарьның яраткан укучысына әйләнә.

1941 елның җәендә институт студентлары Новгородка, рус монументаль сәнгатенең иң гүзәл әсәрләрен, София соборы һәм Ферапонтов монастыре фрескаларын күрергә баралар. Мәскәүгә кире кайтканда, поездда сугыш башлануы турында хәбәр итәләр. Июльдә студентларны Смоленск янындагы Вязьма шәһәренә оборона корылмаларын төзү эшенә җибәрәләр.

Сентябрьдә институтны Сәмаркандка күчерәләр. Һәм Чыңгыз туган якларына әйләнеп кайтырга тиеш була.

1942 елда Әхмәров Сәмаркандта үзенең диплом эшен — монументаль киндер тукымада күпфигуралы «Меч Үзбекистана» триптихын ясый. Аспирантурада уку елларында фәнни хезмәтен Ташкентта төзеләчәк Алишер Нәвои музеена багышлый.

Көтмәгәндә И.Грабарь һәм Н.Чернышовны институт җитәкчелегеннән азат итәләр, берничә күренекле профессорны эштән куалар. Институттан читләштерелгән академик И.Грабарь талантлы аспирантының фәнни эшен җитәкләвен дәвам итә. Грабарь Үзбәкстан башкаласында төзеләчәк Алишер Нәвои исемендәге опера һәм балет театрының проектын төзүче архитектор Алексей Щусев белән аралашып тора. Ул Щусевка аспирантының эшләрен тәкъдим итә. Үзбәкстан җитәкчелеге белән килешү төзелгәннән соң, Әхмәров театрның беренче һәм икенче катындагы фойесы өчен Алишер Нәвои әсәрләренә композиция төзү заказын шатланып

кабул итә. Әхмәров аспирантурада укуын туктатып, 1944 елда Ташкентка кайта.

Сугыш вакыты. Үзбәкстан башкаласында зурлыгы һәм матурлыгы белән бернинди бинаны да чагыштырып булмаслык театр төзелеше гөрли. Алга китеп шуны әйтәсе килә: академик А.Щусев төзегән театр дөнья архитектурасында бер шедевр була. Көн-төн төзелеш бара, плен төшкән японнар да монда үз өлешләрен кертәләр. 1944 елның августында башланган төзелеш өч елдан — 1947 елның ноябрендә төгәлләнә.

Шундый зур һәм күренекле хезмәте өчен 35 яшьлек Ч.Әхмәровка 1948 елда беренче дәрәҗәдәге Сталин премиясе бирелә. Ул 1949 елда, аспирантурадан академик ял алып, Ташкентка кайта.

Планнар, проектлар, уйлар, тәкъдимнәр — алда билгесезлек. Сталин лауреатына бөтен ишекләр дә ачык кебек тоела. Чынлыкта исә бу аңа кыенлыклар гына тудыра. Премия аркасында Әхмәровның көндәшләре барлыкка килә, бигрәк тә Сталин премиясеннән ерак торган, азмыкүпме уңышка ирешкән олы буын кешеләре арасында көнләшү туа. Алар идеологик күзлектән Әхмәровның планнарына киртә куялар. Әхмәров беркайчан да көнчыгыш мәдәнияте, әдәбияты, поэзиясе, сәнгатенең эстетик принципларын югары бәяләве турында яшерми. Ул шәрык легендаларын, Хәйям, Әмир Хөсрәү Дәһләви, Рудакый, Хафиз поэмаларын яттан сөйли. Дистәләгән әкият, дастаннарны белә, гашыйк образлар поэтикасы, шагыйрь, акыл иясе, хан образлары күңеленә якын була. Әлеге образларны рәссам сәнгатьлелек һәм рухи матурлык ягыннан баета. Кайбер хезмәттәшләре көнчыгыш тарихына бәйләнешне антипартияле буржуаз күренеш буларак бәяли. Ә кайберәүләр Әхмәров иҗатына чит дошманнар эстетикасын пропагандалау, феодал калдыкларының абруй казануы кебек карыйлар.

1937 елда мондый гаепләүләр бик күп язмышларны сындыра. Бигрәк тә өлкән хезмәттәшләре В.Кайдалов һәм И.Уфимцев бу эштә актив катнаша. Алар җыелышларда да, вакытлы матбугатта да яшь рәссамның иҗаты ялгыш юлда булуы турында гел искәртеп торалар. Мәскәүгә шикаятьләр языла. Ул вакытта Үзбәкстанның Рәссамнар берлегендә җирле вәкилләр аз була, нигездә, монда россиялеләр эшли. Берлектә дә Әхмәровны аңлаучы табылмый. Хатыны Шәмси Хәсәнова белән дә мөнәсәбәтләре начар була.

Бу авыр чорда ул кинода эшли. Камил Ярматовның «Поэма двух сердец» фильмы өчен костюмнарга илледән артык эскиз ясый. Әлеге хезмәт яңа киностудия өчен үрнәк эш була.

Рәссамнар берлеге белән мөнәсәбәтне киеренкеләмәс өчен, Әхмәров Мәскәүгә кайта. Аны СССР Рәссамнары берлеге Мәскәү метросы станцияләрен бизәргә чакырып ала. Ул 1953 елдан сигез ел буе башкалада яши.

Мәскәүдә аны берничә югары уку йортына укытырга чакыралар. Әхмәров бик теләп үзенең тәҗрибә һәм белемен яшьләр белән уртаклаша. Монда Әхмәров тирәсендә иҗади коллектив оеша. М.Вайман, В.Гаврилов, В.Иорданский, В.Коновалов, А.Мизин, И.Шиловалар Мәскәү метросы, танылган кунакханә, курорт, мәдәният йортлары, театр интерьерлары өчен мозаик панно һәм фреска ясыйлар.

1955 елда Әхмәровка Казанда опера һәм балет театры бинасы интерьерын булдыру эше тапшырыла. Бу

күләмле эшне ул ике елда башкарып чыга.

Бирелгән заказ Чыңгыз Әхмәровны бик шатландыра. Ни өчен, дисезме? Чөнки беркайчан да ул эшсез утырмады, аның талантына һәркайда ихтыяҗ зур иде. Ташкенттан ул идеологик караш төрлелеге, Ташкент Рәссамнар берлеге җитәкчелегендә көндәшләре булу кебек җитди сәбәпләр аркасында китә. Кирегә юл мәңгегә ябык дип саный. Хатыны белән аерыла. Уңышлары булуга карамастан, Мәскәүдә аңа яшәргә урын бирелми. Масловка тулай торагында бер тәрәзәле кечкенә генә бүлмәдә көн күрә: коры тимер карават, кулдан ясалган тумбочка һәм ике урындык. Хәтта эскизларын да ул беренче катта чит кеше чоланында тота. Ул вакытта инде аңа 43 яшь була. Һәм аңа Казаннан еллар буена җитәрлек күләмле заказ килеп төшә. Ялгыз, йортсыз рәссам моны Аллаһтан җибәрелгән бүләк кебек кабул итә. Казанда ул, үз урынын табарга өметләнеп, игътибар, тәкъдимнәр көтеп, бөтен көчен куеп, талантын биреп, Казан театры бизәлешен ясарга керешә.

1961 елда Әхмәровның язмышы кискен борылыш ала. Җиде ел булмаган Ташкентта Әхмәров зур үзгәрешләргә тап була. Мәдәният министрлыгы, Язучылар берлегенең роле үсә, көчле милли-мәдәни тирәлек барлыкка килә. Рәссамнар берлегендә үз халкының сәнгатен аңлаган кешеләр эшли. Рәссамнар берлеге җитәкчесе Искәндәр Икрамов Әхмәров иҗатының дәүләт өчен мөһим булуын аңлый. Ул, Мәскәүгә барып, Әхмәровны алып кайта. Бу вакытта Әхмәровка инде 50 яшь була. Ташкентка кайткач, бөтен көнкүреш проблемалары хәл ителә, остаханә дә бирелә, Әхмәров иҗаты зур югарылыкка күтәрелә.

Ул Олугбәк музеенда монументаль-декоратив эш сериясен башкара, Бируни исемендәге Көнчыгыш институтының вестибюленә дивар бизәге әзерли, Ташкенттагы Нәвои музее бинасын, Сәмәркандта «Йолдыз» ресторанының банкет залын бизи. Сочидагы «Үзбәкстан» ял йортын, Ташкент метросының Алишер Нәвои станциясе интерьерын эшли. Красноярск шәһәрендәге бер кафе өчен «Себерләргә Үзбәкстан даны» диелгән дивар бизәген ясарга да җитешә. Ташкент сәнгать институтларында укыта. 1964 елда яңадан китап графикасы өлкәсенә әйләнеп кайта, Шәрәф Рәшидовның «Кашмирская легенда»сын бизи. Әхмәровка дан, хөрмәт, мактау килә. 1964 елда Хәмзә исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Үзбәкстанның яңа идарәсе аны «Ватан алдындагы казанышлары» ордены белән бүләкли.

Ташкентка кайткач, Әхмәров дөнья буйлап сәяхәт кыла, бөтен Европа, Мисыр, Төркия, Индонезия, Цейлонга бара. Һәм, ниһаять, Пар музеенда яраткан рәссамы Вермеерның картиналары белән таныша. 70 нче елларда чит илләрдә күргәзмәләре була, дөньяның кайбер күренекле рәссамнары белән якыннан таныша.

Мин Чыңгыз Әхмәров белән 70 нче еллар ахырында «Гафур Голәм» нәшриятында таныштым. Анда чираттагы бер китабым, ә аның сәнгать альбомы чыгарга тиеш иде. Шуның өстенә ул әле үз укучылары белән бергә иллюстрация ясаган Көнчыгыш поэзиясе сериясе басмасын да җитәкли иде. Нәшриятка килеп керү белән аны яшьләр чолгап ала. Аңа инде алтмыштан артык... Ул һәрвакыт ап-ак киемнән йөри, чал чәчле, төз, купшы, шат йөзле. Игътибар, яшьләрнең соклануы аның күңеленә хуш килә. Күрәсең, яшьлегендә үзенең картлыгын шулай күзаллагандыр. Бервакыт

яшь язучы дустым Хәйретдин Солтанов мине: «Таныш булыгыз, бик сәләтле егет, тумышы белән сезнең яклардан», — дип аның белән таныштырды. Чыңгыз абый миңа елмаеп кулын сузды һәм: «Сезнең турыда ишеткән бар», — диде.

Аның үзбәк әдәбияты классиклары, татарлар Әсхәд Мөхтәр, Зиннәт Фәтхуллин белән элемтәдә торуын мин белә идем. Алар минем турыда сөйләгәннәрдер, күрәсең.

Сүз Чыңгыз Әхмәров турында барганда, дусты һәм хезмәттәше Рафаэль Такташ турында әйтми калу мөмкин түгел. Һади Такташның улы Рафаэль Такташ — Әхмәровның гадәти булмаган язмышында мөһим роль уйнаган шәхес. Рафаэль Такташ аның белән 1949 елда Мәскәүдә таныша. Ул вакытта Такташ Әхмәров тәмамлаган Суриков исемендәге институтның беренче курсында укый. Әхмәров кебек үк ул да аспирантураны шунда тәмамлый. Ташкентта да, Мәскәүдә дә аларның юллары еш кисешә. Такташ үзенең хезмәтләрен Әхмәровка күрсәтеп бара. Әхмәров Һади Такташ поэзиясен югары бәяли һәм аның шигырьләреннән еш өземтә китерә. Һади Такташның улы тиз арада Ташкентта сәнгать фәннәре докторы, иҗат эше белән бәйле югары уку йортларында күренекле педагог, сәнгать эшлеклесе булып танылa. Иң мөһимен әйтмичә калырга ярамый: Рәшидов белән Такташ дуслыгы турында сирәк кеше генә белә. Рәшидов аның иҗатын югары бәяли һәм һәрьяклап ярдәм итеп тора.

Мәскәүдә яшәгән авыр елларында Әхмәровның бүлмәсенә Такташ еш килә, аның иҗат итәргә бернинди шартлар да тудырылмаган кечкенә бүлмәдә яшәвенә бик борчыла. Такташ моның турында гел Рәшидовка искәртеп тора. Рәшидовның Әхмәровны Ташкентка кайтаруы да Такташ белән бәйле. Рафаэль абый үзе бик тыйнак кеше булганга, моның турында кычкырып сөйләп йөрми, ләкин Әхмәров хатирәләрендә шул фикерне укыйм. Мин, һич икеләнмичә, Такташны Әхмәровны Ташкентка кайтаруда һәм үзбәк халкының мәдәниятендә үз урынын табуда ярдәм иткән шәхес дип әйтәм. Такташның тагын бер эше — соңарып булса да ул, Әхмәровның иҗатын аның тарихи ватаны — Татарстан белән бәйли алды. Ул, М.Ш.Шәймиевкә барып, Әхмәров иҗатының дөнья сәнгатендә тоткан әһәмиятен җиткерде. М.Ш.Шәймиевнең зирәклеге ярдәмендә Әхмәров, үлеменә бер ел кала, «Татарстанның халык рәссамы» исемен ала. Инде начар күрә һәм ишетә торган 80 яшьлек Әхмәровны Беренче Бөтендөнья татар конгрессына чакыралар. Конгресс кунаклары өчен Татарстанда аның күргәзмәсе була. Чыңгыз Әхмәров Казанга рәхмәтен белдерә һәм музейларга үзенең күп эшләрен тапшыра.

2007 елда Чыңгыз Әхмәровның тууына 95 ел тулуны дәүләт идарәсе дәрәҗәсендә үткәрү һәм Гөлнара Кәримованың бу көнгә рәссам истәлекләре турында китап бастырып чыгаруы — болар барысы да Президентның рәссам иҗатына булган хөрмәте һәм мәхәббәте турында сөйли.

Бу мәкаләмдә мин Әхмәровның Сәмәркандны туган шәһәре итеп кабул итүе һәм аның өчен гасырларга сузылган зур эшләр башкаруы турында искәртеп үттем. Икеләнүсез әйтергә кирәк: илаһиятнең гамәлләрен аңлап бетерерлек түгел. Чыңгыз Әхмәровны соңгы юлга үзбәк халкының бөек улы буларак зурлап озаталар. Аның иҗаты үзбәк сәнгате белән тыгыз бәйләнештә.

Чыңгыз Әхмәров 83 яшендә 1995 елның 13 мартында вафат була. ■

ӘДӘБИЯТ

Күкрәгемдә шигъриятнең,
Тынгысыз йөрәге бар.

Шәүкәт Галиев

«МАЯК»



Совет чорында хакимлек иткән идеология 1917-1918 елларда һәм аннан соң нәшер ителгән төрле эчтәлекле татар газета-журналларны берниндичикләүләрсез, җентекле, комплекслы рәвештә өйрәнергә мөмкинлек бирмәде. Гражданнар сугышы чорында, ягъни 1918-1919 елларда Урта Идел, Урал һәм Себернең ак гаскәрләр кулына төшкән төбәкләрендә большевикларга каршы юнәлештә нәшер ителгән дистәләгән газета һәм меңнәрчә өндәмәләргә, листовкаларга «кара фикерле» дигән мөһер сугылып, читтә калдырылдылар. Шундый аяныч язмышка Себердә Кызылъяр (Петропавловск) шәһәрендә нәшер ителгән «Маяк» газетасы да дучар ителгән иде.

«Сәяси, әдәби вә милли төрек-татар газетасы» «Маяк» 1918 елның 7 декабрендә басыла башлап, 30 саны чыкканнан соң, төрле сәяси сәбәпләр аркасында, 1919 елның 2 апрелендә нәшер ителүеннән туктый. Бүгенге көндә Россия Федерациясенең дәүләт китапханәсе (Мәскәү) фондында «Маяк» газетасының 25 саны саклана. Ә калган 5 саны хакында бездә, кызганычка каршы, әлегә берниндимәгълүмат юк. Гаяз Исхакыйның унбиш томлы «Әсәрләр»ен төзеп бастырыр өчен исә Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әлеге газетаның микрофильмы ясатып алдырылды. Хәзерге вакытта әлеге микрофильмнар институтның мирасханәсендә саклана.

Газетаның актив язучысы һәм оештыручыларыннан берсе булган Гаяз Исхакый «Гәзитчелек эшендә егерме биш ел» исемле мәкаләсендә («Яңа милли юл», 1931, №8, 9 бит) үзенең баш мөхәррир булуы хакында яза. Әмма газетаның беренче саннарында мөхәррир итеп Каюм Мустакаев, егерменче саннан башлап — Габделбари Баттал, ә нашире исә Мостафа Төмәнев булуы күрсәтелә.

«Маяк» газетасының тиражы һәм форматы турында төгәл фикер йөртү кыен. Ул бу якларның сәяси-иҗтимагый вазгыятенә һәм редакциянең матди, икътисади мөмкинлекләренә нисбәтән үзгәреп торган шикелле. Газета башта атнага бер тапкыр 4 биттә, аннан соң атнаның теләсә кайсы бер көнендә 2 биттә сары кәгазьдә генә басыла торган булып китә.

Кайбер мәгълүматларга караганда, Кызылъяр шәһәрендә ул чорларда бер-ике рус матбагасы гына эшләгән. Ә себер мөселманнарының исә берниндиматбагасы булмаган, мәгариф эшенә дә әллә ни әһәмият бирелмәгән булса кирәк. Мондый аянычлы хәлгә гаять тә борчылып, Г.Исхакый үзенең «Милли хәрәкәт вә Себер мөселманнары» дигән мәкаләсен яза. Ул: «Петропаул кебек тугыз мәсҗедле бер мөселман шәһәрендә, «Кәҗә бәете» алырга теләсәң дә, китап кибете таба алмыйсың. «Маяк» газетасы рус матбагасында идарәнең читтән китерелгән хәрефләре белән басыла, ул гына да түгел, әле шул тугыз мәхәлләле мөселман шәһәрендә егерме-утыз имамлы, мәдрәсәле Петропаулда «адәм рәтле телле» дини мәдрәсә дә юк. Бу нигә болай? Әллә Себер төрек-татарларына болар кирәкмиме?» — дип тәнкыйтьли. Чөнки Сибириягә килгәннән соң, Кызылъярда матбагачылык эшен юлга салып җибәрер өчен әллә никадәр вакыт һәм көч сарыф ителә. Ләкин шундый кыенлыкларга карамастан, 1918 елның 7 декабрендә «Маяк»ның беренче саны дөнья күрә. Аны «җанлы сүзгә сусаган төрек-татар

дөньясы» зур шатлык белән каршы ала, һәм ул бик тиз вакыт эчендә Себернең иң күп укыла торган милли газетасына әверелә.

«Маяк» газетасының барлыгы 30 саны гына басыла. Әмма ул үзенең идея юнәлешен нык тотып, инкыйлабтан соңгы төрки-татар, гомумән, мөселман дөньясын борчыган мәсьәләләрне билгеләргә, чишәргә тырыша һәм бу юлда зур уңышларга ирешә дә, дип әйтергә була.

Газетаның эчтәлегенә килгәндә, ул үзенең төп иҗтимагый, сәяси юнәлешенә — милләт һәм мәгърифәт мәсьәләләрен яктыртуга шактый киң урын бирә. Газета битләрендә илнең инкыйлабтан соңгы сәяси хәле, башка илләр белән мөнәсәбәте, идарә итү системасы, сәяси оешмалар турында тирән эчтәлекле язмаларны да, әдәбият, сәнгать өлкәсендә булган яңалыкларга багышланган мәкаләләрне дә күрергә мөмкин.

Газетаның авторлар составы да шактый киң. Монда Гаяз Исхакый, Габделбари Баттал, Закир Кадыйри, Габдулла Кариев, Фуад Туктаров һәм башкаларның имзалы язмалары басылып килә. Инде үз заманнарында ук классик язучылар, сәясәтчеләр, гомумән, киң җәмәгатьчелеккә билгеле шәхесләрнең газетаны эшләүдә катнашуы — «Маяк»ның үз чорында абруйлы орган булуын дәлилләүче бер сыйфат.

«Маяк» газетасы берничә айга сузылган гомерендә татар халкы, гомумән, шул чорда Россия территориясендә һәм аннан читтә яшәүче төрки халыклар өчен актуаль булып килгән проблемаларны күтәрә, һәм һәр милләт үзенә-үзе хуҗа булып, хөр, мөстәкыйль һәм бәйсез булып яшәргә тиеш дигән фикерне алга сөрә.

Газета белән якыннан таныштыру ниятеннән, сезнең игътибарга ялкынлы публицист, сәясәтче, төрки-татар халкының язмышы өчен үзенең гомерен фида кылган Гаяз Исхакыйның «Маяк» битләрендә басылган бер мәкаләсен тәкъдим итәбез.

МИЛЛИ ХӘРӘКӘТ ВӘ СЕБЕР МӨСЕЛМАННАРЫ

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ

Безнең милли хәрәкәтемезнең тарихы башланганга инде утыз еллар булып килә. Шул утыз еллар эчендә милли хәрәкәтемезнең төрле тармакларында төрек-татарның төрле ыруглары, кабиләләре үзләренчә роль уйнадылар. Төрек-татар яшәгән зуррак шәһәрләр һәммәсе дә диярлек берәр милли вазифаны үтәделәр. Идел буеның зуррак авыллары да милли йөкне үстерешүдә зур батырлык күрсәттеләр. Казан шәһәре, иң әүвәл милли матбага тәэсис итеп (оештырып), милли әдәбиятның баш күтәрүенә беренче сәбәп булды. Уфа, беренче мәртәбә милли сәхнәгә әһәмият биреп, театр вә музыкамызның юлга салынуына беренче адымны атлады. Оренбург фәнни мәдрәсә тәэсис итү, фәнни журнал мәйданга китерүдә беренчелекне алды. Мөселман никадәр аз булса да, Петербург җәмгыятьләр

төзеп эш итүдә үрнәк була белде. Мәскәү халкының иң зур кыйсеме (өлеше) килмешәкләр булса да, олуг милли вазифалар алдында бер җан, бер тән кебек хәрәкәт итеп, һәр сәяси адымда беренче булып килде.

Беренче матбага Казанда ачылды. Беренче китап кибете Казанда ачылды. Яңа әдәбият нәшере («Мәгариф» көтебханәсе) беренче уларак Казанда башланды. Беренче театр (5 нче елда) Уфада булды. Әдәбият кичәләрен башлап Уфа эшләде. Милли җырларымызга, милли музыкага әһәмият бирү башлап Уфадан чыкты. Беренче Җәмгыяте хәйрия, «Нәшере мәгариф» җәмгыяте, укучылар оешмасы Петербургта туды, шунда үсте. Беренче уларак Петербург җәмгыяте үзенең шәрекъ кичәләре белән безнең әдәбиятымыз, музыкамыз, сәхнәмезне рус дөньясына күрсәтте. Балкан сугышы вакытында рус матбугатының төрек галәйһенә кыяменә (төрекләр өчен зарарлы чыгышына) каршы беренче протесты Мәскәүдә эшләнде. Балкан сугышы вакытында рәсми иттереп төрек һиляле әхмәр җәмгыятенә (кызыл ярымай оешмасына) иганә җыюны Мәскәү башлады. Төрек-татар матбугатының унъеллык юбилейсын фәкать Мәскәү бәйрәм итте. Революция вакыты башлангач та, Русия мөселманы һәммәсе бер байрак янында берләшеп хәрәкәт итәргә, дигән берлек байрагын башлап Мәскәү күтәрде. Әстерханы, Пермәсе, Чистае, Бөгелмәсе — һәммәсе дә үзенә күрә милли хәрәкәттә роль уйнады, хәтта Буби кебек кечкенә бер авыл да әллә ничә йөз мөгаллим, мөгаллимә, имам, мөәзин хәзерләде. Революциядән соң Эчке Русия, бөтен көчен сәфәрберлек (мобилизация) хәленә китереп, сәяси милли тартышуга кереште. Мәркәз милли шура бөтен Русия мөселманына гаид гам (караган гомум) хезмәтләрен дә фәкать Эчке Русия көче белән генә эшләп барды. Эчке Русия зыялы куәтләр бирде, Эчке Русия мадди көч, акча бирде. Гаскәрләремезне миллиләштерү, милли полклар төзеп, хәрби шуралар мәйданга китерү, урдулар (гаскәри берәмлекләр) төзүнең 99 проценты Эчке Русиянең матди, мәгънәви көче белән генә эшләнде. Хәрби шураларга Казан үзе генә бер миллион чамасы акча бирде. Милли мохтарият игълан ителеп, Милли фонд тәэсис ителгәндә, Эчке Русия бер кузгалуда ике миллионнан артык акча туплады. Эчке Русия мөселманы мәгънәви көчен туплап бер вакытта Учер. Собраниягә сайлау өстенә, Милләт Мәҗлесенә сайлауны да башкарды. Болар өчен 100 мең сумнар акчага башка әллә никадәр дәрт вә гайрәт сарыф итте. Буңа башка олуг, кечек шәһәрләрендә чиксез күп гәзитәләр, журналлар, рисаләләр нәшер итте. Большевик золымына кадәр Эчке Русиядә мөселманлы шәһәрнең һичберсендә үзенең матбагасы, китапханәсе, үзенең китап магазины булмый калмый иде. Большевик золымына кадәр Эчке Русиядәге зуррак авылларның һәммәсендә мәктәбеннән башка, кыйраәтханәсе (уку йорты) бар иде. Соңгы утыз ел эчендә Эчке Русиянең төрле шәһәрендә кырыктан артык милли матбага мәйданга килгән иде. Илле-алтмыш китап магазины ачылган иде. Ике-өч кызлар гимназиясе (Казанда, Уфада, Троицкида), 4 дәрелмөгаллимат (хатын-кызлардан укытучылар хәзерли торган уку йорты, Уфада Гыйбадулла Госманов, земстводан мөгаллим-мөгаллимәләр курсы, Бөгелмә, Троицки мөгаллиматлары), әллә никадәр мәдрәсә, берничә төрле гыйльми, әдәби җәмгыятьләр нигезләнгән иде вә эш күрәләр иде. Большевик золымы булмаса, хәзер дә күрәчәк иде. Большевик бетү белән тагы зур куәт белән, әлбәттә, эшкә керешәчәктер. Искән шул утыз

ел эчендә бөтен төрек-татарның милли, мәдәни вә дини бурычын үтәүдә Себер төрек-татарлары нишләде? Нишләгән? Гомуммилли эшкә нинди хезмәтчеләр, нинди голяма, нинди мөдәррисләр, нинди мөгаллимнәр, нинди мөхәррирләр, нинди әдипләр, нинди хәмиятле байлар биргән? Мәрхүм Нигъмәтулла хаҗины читкә куйганда, Семида бу ел гына оешкан мәдәният җәмгыятен, Томда бу ел гына ачылган дәрелмөгаллиминны (ирләрдән укытучылар хәзерли торган уку йортын) читкә куйганда, Себердә кемнәр бар? Нинди милли хезмәт ителгән? Моңа җавап кемгә мәгълүм?

Петропаул кебек тугыз мәсҗедле бер мөселман шәһәрендә карынча догасы, «Кәҗә бәете» алырга гына теләсәң дә, китап кибете таба алмыймыз («Маяк» газетасы рус матбагасында идарәнең читтән китердеге хәрефләр белән басыла). Ул гына да түгел әле, шул тугыз мәхәлләле мөселман шәһәрендә — егерме-утыз имамлы, мөдәррисле Петропаулда адәм рәтле дини бер мәдрәсә дә юк.

Семидә дә, мәдәният җәмгыяте янына җыелган берничә данә фидакяр яшьләрне читкә куйганда, шул ук манзара (күренеш). Анда да нә дәрелмөгаллимин бар, нә дәрелмөгаллимат, нә мөселман гимназиясе, нә бер дини мәдрәсә... Томск, Омск, Красноярск, Тары, Тобол вә һакәза (шулай ук) Себернең бөтен татары, Себернең казагы мулла, имам, мөдәррис, мөәзин, мөгаллим вә мөгаллимәгә сусап ятканда, шул ихтыяҗга карый бер эш тә эшләнмәгән, эшләнми, эшләргә уйланмый. ...Себернең бөтен татары, бөтен казагының китапка сусавы сахраи кәбирдәге (Сахрадагы) гарәбнең бер тамчы суга сусавыннан артык булганы хәлдә, Себер утыз битле бер китабын, бер рисалә, бер догалык бастырып бирә алмый. Бирергә уйламый. Бирерлек көче юк. Себернең милли мәсьүлиятьне аңламый торган берничә купчигы (ирония белән әйтелгән (купецы, сәүдәгәре)) тарафыннан газапланып алынып, амбарга бикләнеп куелган 14 пот хәрефтән башка Себердә 20-30 битлек китап бастырырлык хәреф тә юк.

Бу нигә болай?

Нигә Себер төрек-татары үзенең милли, мәдәни, дини ихтыяҗын үтәр өчен бер тәшәббестә дә булынмаган (инициатива да күрсәтмәгән)? Нигә Себернең голямасе үзенә имам, мөәзин, мөгаллим чыгара торган мәктәп-мәдрәсәләр тәэсис итмәгән? Нигә Себернең яшь сәүдәгәре, зыялысы бөтен Себергә бер генә булса да матбага мәйданга китермәгән? Нигә бер генә булса да, дәвамлы гәзитә тудыра алмаган? Себернең сәүдәгәре, бае ник шул милли, дини ихтыяҗларны үтәүдә кечкенә генә дә кулын сузмаган? Гомер буе мулласын, мөәзинен, мөгаллимен, мөгаллимәсен, китабын, гәзитәсе, журналын Эчке Русиядән хәер сорашып үтәячәкме? Әллә Себер төрек-татары боларны кирәкми дип, фәкать хайвани хәят белән генә яшәргә телиме?

Бу сөальләр җавап телиләр?

Майлы куй койрыгын суырып яткан чагыңызда, сезне бимаза итеп, бу сөальләр җавап телиләр.

Ишеткән кеше булса, Себердә ишетү куәсен (көчен, куәтен) май басмаган кеше булса, хәят сездән җавап тели.

Милләт сездән җавап тели.

Рәхим итеңез.

Кереш мәкаләне һәм текстны басмага филология фәннәре кандидаты ***Гөлназ Хөснетдинова*** *әзерләде.*

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ,
ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ,
Х.К.АНДЕРСЕН ИСЕМЕНДӘГЕ ХАЛЫКАРА БҮЛӘК ИЯСЕ

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ

(20.11.1928 – 07.05.2011)

***

Гаҗәпләнмә,
Шигырь язам әле,
Туры килер сезгә укырга.
Кемнәр анда, әй сез, ашыкмагыз
Исемемне сызып атырга!

Илһам көчем кагып канатларын,
Йөрәк тамырларын киерә,
Рәхәт тә соң ул көрәшеп яшәү
Үз йөрәгең җыры көенә.

Чирәм үскән тар сукмаклы итеп,
Күрмимен мин барыр юлларны,
Җырларымда
Үз йөрәгем белән
Күп йөрәкләр җырын җырлармын!

Яздым менә,
Шушы юлларны да
Туры килде сезгә укырга.
Әйттем бит мин,
Әле иртә, диеп,
Исемемне сызып атырга!

*Шагыйрь Шәүкәт Галиевнең кайбер сүз энҗеләрен журнал битләреннән чүпли аласыз.

РЕЗЕДА ГАНИЕВАГА 80 ЯШЬ

ТЫНГЫСЫЗ ГАЛИМӘ

13 НОЯБРЬДӘ КҮРЕНЕКЛЕ ӘДӘБИЯТ ГАЛИМЕ РЕЗЕДА КАДЫЙР КЫЗЫ ГАНИЕВАГА 80 ЯШЬ ТУЛДЫ.

Казан педагогия училищесын, читтән торып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач та, Мәскәү дәүләт университетының филология факультетында СССР халыклары әдәбияты кафедрасында аспирантура үтеп, педагог һәм галимә үзенең алтмыш ел гомерен (1951-2011) татар халкының мәгърифәтен һәм мәгарифен үстерүгә багышлый, авыл һәм шәһәр мәктәпләрендә, гимназия, көллият-лицейларда, югары уку йортларында укытучы булып эшли, ярты гасыр диярлек (1962-2011) Казан дәүләт университетының журналистика, татар һәм рус филологиясе бүлекләрендә татар әдәбияты тарихы, Совет Көнчыгышындагы төрки халыклар, гарәп-фарсы әдәбиятлары, Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый иҗатлары һәм көлү (сатира) теориясе буенча лекцияләр укый. Аның тирән эчтәлекле, ялкынлы лекцияләре, чыгышлары — йөзләгән-меңләгән шәкертләренең, тыңлаучыларның хәтерендә уелып калган якты мизгелләр. Укыту-педагогик эшчәнлек белән бергә ул әдәбият белеме өлкәсендә дә актив эшли: «Габдулла Тукайның сатирик иҗаты» (1964), «Шәрекъ Ренессансы һәм аның төрки әдәбиятлардагы традицияләре» (1992) дигән

темаларга кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклый; татар әдәбиятының Шәрекъ һәм Гареб әдәбиятлары белән (гарәп, фарсы, төрек, кыргыз, үзбәк, төрекмән, башкорт, чуваш, каракалпак, кумык, француз, немец, рус, украин һ.б.) бәйләнешләрен өйрәнүгә йөзләгән мәкаләләрен багышлый. Резеда Ганиева — татар әдәбияты белемендә үз фәнни мәктәбен тудырган галимә. Аның җитәкчелегендә 15 кандидатлык һәм бер докторлык диссертациясе әзерләнгән. Бүгенге көндә университеттагы эшчәнлеген туктатса

да, галимә татар халкының әдәби мирасын милләтебез аңына җиткерү, аны бөтендөнья әдәбият белеме мәйданына алып чыгу, аеруча төрки халыкларның әдәби җәмәгатьчелеген мәдәни казанышларыбыз белән таныштыру өлкәсендә җигелеп эшләвен дәвам итә. 2011-2012 еллар дәвамында ул онлайн режимда төрки дәүләтләр һәм республикалар галимнәре өчен (Астана, Алма-Аты, Җаек-Уральск, Уфа, Казан) Ислам Ренессансына мөнәсәбәттә «Тукайның татар һәм бөтендөнья әдәбияты тарихында тоткан урыны», «Шагыйрьнең дини-фәлсәфи лирикасы» турында видеолекция укыды; «Тукай һәм төрек әдәбияты», «Тукай һәм азәрбайҗан әдәбияты», «Нәзыйрәчелектән — интертекстуальлеккә — әңгәмәдәшлеккә таба (Шекспирның Гамлет традицияләреннән Г.Тукай, С.Рәмиев, Ф.Әмирхан, Ф.Туйкиннар кабул иткән интертекстлар турында)», «Галимджан Ибрагимов — татарский Буревестник (творчество Г.Ибрагимова в контексте мировой литературы)», «Галимҗан Ибраһимовның романтик эстетикасы», «Галимджан Ибрагимов: Тукай поэт ли, или же нет?» дигән темаларга Истанбулда, Бакуда, Уральскида, Казандагы конференцияләрдә һәм телевидениедән чыгышлар ясады, интервьюлар бирде, газета-журналларда мәкаләләр бастырды. Шул ук вакытта ул Татар һәм Тукай энциклопедияләре өчен мәкаләләр язуда актив катнашып килә, татар һәм азәрбайҗан галимнәренең монографияләренә рецензияләр яза. Гомумән алганда, галимә дөнья әдәбияты белән багланышларын, фәлсәфи-эстетик карашларын өйрәнүгә дә өлеш кертте; аспирантларының (Зөһрә Сәлахова, Рәзилә Минһаҗева) хезмәтләрен редакцияләп, китап итеп бастырып чыгаруда да булышлык күрсәтте.

Галимәнең әдәбият фәне өлкәсендәге эшчәнлеге, гомумиләштереп әйткәндә, түбәндәге юнәлешләрдә барды: 1) Урта гасыр һәм Яңа заман татар әдәбиятының күренекле вәкилләре турында монографик тикшеренүләр; 2) әдәби традицияләр һәм багланышларны фәлсәфи-эстетик планда яктырту; 3) иҗат ысуллары: реализм, романтизм, модернистик һәм постмодернистик юнәлешләрне өйрәнү; 4) Шәрекъ Ренессанс әдәбиятының фәлсәфи үзенчәлекләрен билгеләү; 5) украин, рус, төрек, татар телендә чыккан энциклопедияләрдә мәкаләләр белән катнашу («Украинская литературная энциклопедия», рус һәм украин телләрендә; «Украинская советская энциклопедия», рус телендә; «Шевченковская энциклопедия», украин телендә; «Әдәбият белеме сүзлеге»; Татарский энциклопедический словарь; «Татарская энциклопедия»; «Татар энциклопедиясе»; «Төрек дөньясы әдәбиятчыларының энциклопедиясе», төрек телендә; «Ислам на Европейском Востоке. Энциклопедический словарь»; «Габдулла Тукай. Энциклопедик сүзлек-белешмә»сенә әзерләнгән материаллар («Шагыйрьнең рухи дөньясы» китабында)); 6) Россия, Төркия, Татарстан, Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Азәрбайҗан һәм дә каракалпак, кумык, чуваш, мордва, удмурт, коми-пермяк әдәбиятчылары хезмәтләренә язылган бәяләмәләр, рецензияләр язу.

Әт-Тәүхид фәлсәфәсенә нигезләнгән Шәрекъ Ренессансы — профессор Резеда Ганиеваның аеруча яратып эшләгән юнәлеше. Шуны истә тотып, «Чын мирас» журналы үзенең укучыларына галимәнең Урта гасыр шәркый мөселман әдәбиятларындагы Яңарыш хәрәкәте турындагы хезмәтләреннән бер өзек тәкъдим итәргә булды.

ШӘРЕКЪ РЕНЕССАНСЫ

РЕЗЕДА ГАНИЕВА,
филология фәннәре докторы

Ренессанс (француз сүзе; русча — возрождение, татарча — яңарыш) — бөтендөнья халыкларының иҗтимагый һәм рухи яшәеше, мәдәни һәм әдәби хәрәкәте тарихында югары үсешкә ирешкән чорларның берсе. Ренессанс күренешен билгеле бер тарихи дәвергә генә беркетеп кую да, аны бары тик аерым бер халыклар, мәдәниятләр, әдәбиятлар өчен генә хас күренеш дип раслау да мөмкин түгел. Ул — җир шарының төрле кыйтгаларында яшәгән халыклар мәдәниятендә төрле дәверләрдә — әле борынгы чорда, әле урта гасырларда, әле Яңа заманда калкып чыгып, яңадан-яңа фикерләр, сәнгати төсмерләр белән баеп, әле үсеп, әле торгынлык кичереп, сүнеп, даими әйләнеп кайтучы һәм кабатланып торучы мәңгелек бер универсаль күренеш. Кызганычка каршы, соңгы ике гасыр дәвамында фәндә Яңарыш турында ауропачыл (европоцентристик) карашлар хөкем сөрде, ул бары тик Европа җирлегендә XIV-XVI гасырлардагы Италиядә генә чәчәк ату чорын кичерде, дип тәкърарлап киленде.

XX гасырның 40 нчы еллары азагыннан Шәрекъ халыклары әдәбиятларында да Ренессанс булу турында сүз алып барыла башлады. 1960 елда синолог — кытай тарихы, мәдәнияте, фәлсәфәсе, әдәбияты, теле буенча зур галим Н.И.Конрад мәкаләләре, ә 60 нчы елларда фарсы-таҗик әдәбиятлары белгече И.С.Брагинскийның хезмәтләре басылып чыгу бу мәсьәләгә игътибарны арттырды. 70-80 нче елларда Шәрекъ әдәбиятларында Ренессанс булу-булмау хакында «түгәрәк өстәл»ләр, дискуссияләр, конференцияләр булып үтте. Берәүләр Шәрекъ халыкларында да Яңарыш булуны таныдылар, икенче берәүләр ярсый-ярсый кире кактылар. Шәрекъ Ренессансы турындагы кискен бәхәсләр, аңа бирелгән тискәре бәяләмәләр академик Н.И.Конрад тырышлыгы белән гамәлгә куелган «Бөтендөнья әдәбияты тарихы»ның сигез томлыгы өчен материалларны матбугатка әзерләү һәм бастырып чыгару барышында зур кыенлыклар тудырды. Шәрекъ Ренессансына катгый каршы чыгучылар әле борынгы заманнарда ук үз антик дәверләре булган, фәнни-техник ачышлары, рухи кыйммәтләре белән

кешелек дөньясын баеткан кытайлылар, һиндлылар, гарәп-фарсыларны, төркиләрне караңгылыкта, наданлыкта яшәүчеләр итеп күзалладылар. Аларча, Ренессанс бары тик Ауропада гына туа һәм үсә алган, гасырлар дәвамында феодаль торгынлыкта яшәгән шәркый халыклар мәдәниятләрендә, әдәбиятларында Яңарыш булган дип сүз куерту — гайре табигый фәлсәфә. Бу уңай белән Н.И.Конрадның «Яңарыш — Аурупа өчен генә хас күренеш түгел, ул дөнья халыклары, бөек цивилизацияләр тарихының мәгълүм бер чорында кануни рәвештә мәйданга чыга торган гомумзаруриятләр чагылышы» [1] дигән фикеренәябырылдылар. Шәрекътә дә Ренессанс булган дип раслаучы ике академик — синолог В.М.Алексеев белән Н.И.Конрад арасында низаг чыгарырга тырыштылар; фарсы-таҗик әдәбиятындагы Ренессанс хәрәкәтен, аның даһи шагыйрьләрен өйрәнүгә зур өлеш керткән И.С.Брагинскийны төрлечә әзәрлекләделәр, фарсы Яңарышы турындагы карашларыннан баш тартуны таләп иттеләр, Бөтендөнья әдәбияты тарихы томнарына язган хезмәтләрен бозып редакцияләделәр, йә булмаса, бастырмадылар.

Совет чоры галимнәренең зур бер төркеме Шәрекътә дә, Ауропадагы кебек, Ренессанс хәрәкәте тусын, үсеп китсен өчен ике алшарт, ике зарурият булу мәҗбүри, диделәр: 1) борынгы тарихта грек мәдәнияте кебек таяныч нигез — антик байлык булу; 2) капитализм кебек иҗтимагый формация баскычы аша үтү. Аларча, мөселман дөньясында боларның берсе дә булмаган, шулай булгач, Шәрекъ Ренессансы турында сүз алып бару һич тә мөмкин түгел. Россия галимнәренең байтагы бүген дә шушы фикерне ураклашуын дәвам итә.

Чынбарлыкта исә Көнбатыш һәм рус галимнәренең «Кешелек мәдәниятенең бишеге — Борынгы Греция» дигән аксиома рәвешен алган фикерләре дә хакыйкатьтән шактый ерак тора. Тарихи барышта антик дәвер аша бер греклар гына үтмәгән, башка халыкларның да мәдәниятләре антик вазифаны үтәгән чорлар булган. Мәсәлән, антик Кытай мәдәниятеннән Вьетнам, Корея, Япония культуралары тармакланган. Борынгы санскрит телендәге фольклор, тарихи, фәлсәфи, гыйльми чыганаклар Цейлон, Бирма, Индонезия мәдәниятләре һәм дә Һиндстанның үз җирлегендә яңа әдәбиятларның тууы, үсүе өчен җирлек әзерләгән. Ә инде Урта һәм Якын Көнчыгыштагы яңарыш рухлы гарәп мәдәниятенең нигез ташларын салуда грек-йунан антикасының өлеше гаять тә зур булган. Бу — гарәп белән грек мәдәниятләренең үзара йогынтысын, бәйләнешләрын өйрәнгән галимнәр тарафыннан расланган факт. Ләкин шуны да онытырга ярамый: борынгы Йунан җәмгыяте кризис кичереп, тарих сәхнәсеннән түбәнгә тәгәрәгән чакта грекларның антик чордан калган, таркалып яткан мирасын юкка чыгудан коткарып калучылар, аларны җыйнап, текстологик яктан эшкәртеп, шәрех-комментарийлар биреп, тәрҗемә итүчеләр, иҗади кабул итүчеләр баштарак несториан сириялеләр булсалар, соңрак ислам дөньясы вәкилләре булдылар.

Бу факт үзе генә дә Гареб галимнәренең мөселманнарда Ренессанс булмаган, чөнки алар борынгы грек мәдәнияте йогынтысын татымаганнар, дигән фикерне төбе-тамыры белән кире кага. Киресенчә, ислам дөньясының ауропалыларга караганда күп гасырлар элек йунан фәне, фәлсәфәсе казанышларын тирәннән

сөреп, иҗади эшкәртеп, Яңарыш хәрәкәтен әйдәп баручылар сафына басулары турында сөйли.

XX гасыр азагында кайбер рус галимнәре Ренессанс хәрәкәтенең асылын билгеләүче икенче шарттан да, ягъни аны бары тик буржуаз мөнәсәбәтләр җимеше итеп караудан да баш тарта башладылар. Мәсәлән, танылган галим Г.К.Косиков фикеренчә, Яңарыш әдәбияты феодаль җәмгыять алгарыш кичергән заманнарда ук зур уңышларга ирешкән. «Ренессанс гуманизмы, — ди ул, — урта гасыр хәрабәләреннән генә үсеп чыкмаган, киресенчә, ул урта гасырлар белән тыгыз чолганышта булып, катлаулы үсеш кичереп, урта гасыр цивилизациясе актив яшәеш кичергән бер чорда барлыкка килә» [2]. Аңлашыла ки, галим, рус фәнендә кабул ителгәнчә, урта гасырларны караңгылык һәм наданлык дәвере генә итеп карамый. Бу фикер ислам цивилизациясендәге Яңарыш хәрәкәтен күзаллау һәм аңлау өчен аеруча әһәмияткә ия. Чыннан да, шәркый мөселман дөньясының өч ареалын — гарәп, фарсы, төркиләрне шөһрәткә күмгән даһи философлар һәм бөек шагыйрьләр Әл-Кинди, Әл-Фараби, Ибн Сина, Бахманьяр, Имам Газзали, Ибн Гарәби, Ибн Рөшд, Бируни, Рудәкый, Фирдәүси, Йосыф Баласагунлы, Мөтәннәби, Мәгарри, Низами, Хакани, Хәйям, Кол Гали, Руми, Сәгъди, Хафиз, Нәсими, Котб, Сәйф Сараи, Нәвои, Җами, Мөхәммәдьяр һәм башка бик күпләр урта гасырлардагы Ренессанс дәверендә яшәгән һәм иҗат иткән.

Шәрекъ Ренессанс хәрәкәтен өйрәнү тарихы никадәр генә каршылыклы булмасын, XX гасырның соңгы чирегеннән башлап аның Кытай һәм Һиндстан халыкларында да, мөселман гарәп-фарсы-төрки халыклар мәдәниятләрендә дә булганын раслаган һәм һәртөрле тискәре бәяләрдән араларга тырышкан, реабилитацияләгән чыгышлар артты. Бу хакта рус, таҗик, үзбәк, азәрбайҗан, татар галимнәренең саллы гына хезмәтләре дөнья күрде, докторлык диссертацияләре якланды (Н.И.Конрад, В.М.Жирмунский, А.Ф.Лосев, Г.К.Косиков, Н.И.Балашов, А.Турсунов, А.Х.Хәйитмәтов, А.А.Гаджиев, Х.Г.Юсифов, Р.К.Ганиева һ.б.). XX гасырның бөек философы А.Ф.Лосев язганча, «Ренессанс бер ил белән генә чикләнмичә, барлык илләр аша үткән, әмма һәр ил үз Ренессансын һәм вакыт, һәм асыл сыйфатлары чагылышы ягыннан үзенчә үткән» [3].

***

Урта гасырлардагы Ренессанс күтәрелешенең беренче сәхифәләре бер үк вакытта ике урында — VII гасырда Шәрекъ дөньясының ике капма-каршы кыйтгасында, хәзерге Согуд Гарәбстанының мәдәни үзәген тәшкил иткән Хиҗаз өлкәсендәге Мәккә белән Мәдинә шәһәрләрендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең (570-632) могҗиз эшчәнлеге белән һәм дә Көнчыгыш төрки каханлыгы хәрабәләрендә үсеп чыккан Тан империясе дәверендәге (618-907) Кытай Яңарышы белән ачылып китә. Шунысы игътибарга лаек: Тан чоры Яңарыш хәрәкәтенең нигез ташларын салучылар төрки аристократия вәкилләре — кытайлыларның сарай гвардиясендә хезмәт итүче, ә соңрак хакимиятне үз кулларына төшерүче аталы-уллы Ли Юань белән Ли-Ши-Мин (Тай Цзун) булалар. Кытайлыларның Тан династиясе Яңарыш культурасы үсешенә төркиләрнең зур өлеш кертүе, аларның музыкасына, сәнгатенә, әдәбиятына, кием-салым йөртү, аш-су хәзерләү

өлкәсенә күп кенә яңалыклар алып килүе — галимнәр тарафыннан танылган факт. Тан чорындагы кытай әдәбияты чын мәгънәсендә яңарыш кичерә: анда 2200 шагыйрь яши һәм дә Чэн Цзы-ань, Ли Бо, Ду Фу, Бо Цзуй-и кебек даһи шагыйрьләр иҗат итә. Кешегә карата кешелекле булырга чакыру, һәркемне яратырга өндәү — Тан Ренессансының үзәк шигаренә әйләнә.

Якын һәм Урта Көнчыгышта исә Яңарыш балкышы мөселман мәдәниятенең олуг ядкәре — Изге Коръән тәгълиматы чәчкән илаһи нурлар йогынтысында пәйда була; тарих аренасына Алланың барлыгын һәм Берлеген расلаган, җир кешеләрен кешелеклелеккә чакырган, әхлакый яңаруга чакырган әт-Тәүхид фәлсәфәсе (монотеизм) мәйданга чыга. Ул кешеләрне Аллаһы Тәгаләнең яраткан коллары дип игълан итү һәм Аңа сәҗдә кылырга, мәдех укырга өндәү белән бергә, Кешене дә олылый, аңа җирдә яшәү һәм Галәм белән идарә итү өчен чикләнмәгән ихтыяр көче һәм рухи ирек бирә. Коръәннең 14:32-34; 16:10-19; 31:20; 45:12,13 сүрә һәм аятьләре шул хакта сөйли.

Исламга кадәрге гарәпләр арасында киң таралган фахишәлеккә, эчүчелеккә, яңа туган кыз балаларны тугач та, эссе комга йөзләре белән каплап үтерүгә һәм башка әхлакый бозыклыкларга каршы чыккан Коръән күрсәтмәләре мөселманнар өчен чын мәгънәсендә Яңарыш инкыйлабын тәэмин итүче бөек көч була. Аларның иҗтимагый-сәяси һәм көндәлек тормыштагы матди, рухи тәрәккыятләре өчен иксез-чиксез мөмкинлекләр ачыла.

Коръән тәгълиматы һәм ислам дине фәлсәфәсе алга сөргән гуманистик карашлар, югары әхлакый сыйфатлар (кешелеклелек, гаделлек, шәфкатьлелек, юмартлык, сабырлык, ата-ананы хөрмәт итү һ.б.) мөселман гарәп-фарсы-төрки халыкларның менталитетына, яшәү рәвешенә, гореф-гадәтләренә зур яңалыклар алып килә, гасырлар дәвамында аларның дөньяга карашларына йогынты ясый һәм әдәби-сәнгатьчә фикерләүләрен бихисап сюжет җепләре, образ-сурәтләр белән баетып тора. Татар әдәбияты тарихында да Коръән-Кәрим әдипләребез иҗатын иксез-чиксез әдәби эстетик ачышлар белән туендырып тора, яшәү фәлсәфәсенең һәр мәсьәләсенә җавап биргән әхлакый кыйммәтләр энциклопедиясенә әверелә.

Мөселман Яңарышын әзерләүгә зур өлеш керткән алшартларның иң әһәмиятлесе — әле ислам дине кабул ителгәнчегә кадәр үк «каһарманнар гасырында» иҗат ителгән йөзләгән бәдәви шагыйрьләр тарафыннан сәнгатьчә эшкәртелгән, иҗтимагый, сәяси, әхлакый, әдәби-эстетик фикер трибунасын үтәгән, безнең көннәргәчә антик үрнәк вазифасын башкарган гарәп әдәбиятының нигез ташлары салынган булу. Моның шулай икәнлеге хакында Аурופа, Россия һәм XX гасыр башы татар галимнәре дә язып калдырганнар (Х.А.Р.Гибб, Ф.Габриэли, Г.Э.Грюнебаум, И.Ю.Крачковский, И.М.Фильштинский, А.Б.Куделин, М.Бигиев, Р.Фәхретдинов, Г.М.әл-Гаффари, Г.Ибраһимов, З.Уразаи, «Г.Д.Р.Н» (имзалы автор) һ.б.). Аеруча шунысы гыйбрәтле: җаһилият дәвере (500-622) шагыйрьләре тудырган бай гарәп теле нәзым, мөсәҗҗәгъ нәсер өслүбенә корылган Коръән-Кәрим теле итеп кабул ителә һәм ул, Көнбатыш мәдәниятләрендәге латин теле кебек, ислам дине таралган һәр илдә, һәр халыкта, һәр мөселман кешесенә өйрәнү фарыз булган классик гарәп теленә әйләнә.

Борынгы гарәпләрнең исламга кадәрге чорында гомәриләр һәм гозрәиләр кабиләләре шагыйрьләре тарафыннан гамәлгә кертелгән газәлләр, касыйдәләр, сәҗгъләр (рифмалы проза) иҗат итү, нәзым әйтү традициясе, гасырлар кичә-кичә, нюанс-төсмерләрдә яңара-яңара, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Сәнгатьчә фикерләү осталыгы буенча шигъри талантларны сайлап алу максатыннан ярминкәләрдә, мәйданнарда әдәби бәйгеләр — «могалләкат» [4] ярышлары үткәрү, тиңе, мисалы юк дип бәяләнгән нәзымнарны иң югары дәрәҗәгә лаек дип, кыйммәтле тукымаларга алтын хәрефләр белән язып, гарәп кабиләләре исеменнән изге кәгъбәтуллага керү юлында диварларга элеп кую, җиңүчеләрне бүләкләү йоласы XX-XXI гасыр башындагы әдәби барышыбызда Г.Тукай исемендәге бүләкне бирү кебек күренешне хәтерләтә. Риваятьләр буенча, V-VII гасырлардагы исламга кадәрге гарәп әдәбиятында йөздән артык шагыйрь иҗат иткән. Шулар арасыннан бары тик җиде мәшһүр шагыйрьнең нәзымы гына «шигъри энҗе» рәвешендә «могалләкъкә» лаек дип табыла. Бу шигъри бәйгедә җиңеп чыгучы сүз сәнгате осталары түбәндәгеләр: Имрәэл-кайс, Тарафа бине әл-Габд, Харис бине Хиллиза, Гамру бине Көлсум, Гантара әл-Габбеси, Зөһәйр бине Әбү Сөлмә, Ләбид бине Рабига. «Шура» журналында «Г.Д.Р.Н.» криптонимы белән басылган мәкаләдә дә «Мөгалләкате сәбгә» авторларының исемнәре татар зыялыларына, укымышлыларына, мәдрәсә шәкертләренә яхшы мәгълүм булган [5]. XX гасыр башы татар әдәбиятындагы аерым шагыйрьләр «мөгалләкъ» авторлары белән дә чагыштырылган, мәсәлән, Р.Фәхретдинов М.Гафурины Имрәэл-кайс белән янәшә куйган.

Мөхәммәд пәйгамбәр вафатыннан соң (632), Госман хәлифә әмере белән 650-656 елларда Зәйд ибн Сабит тарафыннан Коръәннең канунлаштырылган тексты төзелә һәм гамәлгә керә. Изге Китаптагы Илаһият, Галәм, Кеше турындагы яңа дини-фәлсәфи, фәнни-дөньяви, рухи-әхлакый кыйммәтләргә таянып, ислам цивилизациясенең Яңарышка таба көчле һәм дәвамлы, эзлекле адымнары башлана. Гарәпләрнең алгарышка булган бу омтылышы милли дәүләтчелекне төзү, аның чикләрен киңәйтү яулары, гаҗәм халыкларының (гарәп булмаган) мәдәни казанышларын иҗади үзләштерү хәрәкәте белән янәшә алып барыла.

Күпчелек галимнәр фикеренчә, гарәп әдәбиятының чын мәгънәсендә классик камиллеккә, Яңарыш баскычына аяк басуы Өммәви (661-750) һәм Габбаси (750-1258) хәлифәләр хакимлек иткән чорларга туры килә. VIII-XII гасырларда Мәгърибтә (Төньяк Африка) һәм Испания Андалусиясендәге гарәп әдәбияты, сәнгате һәм архитектурасы чәчәк ату чорын кичерә. Гарәп мәдәниятенең югары үсеш алган бу чорларын сагынып, сагышланып искә алу XIX-XX йөз башы татар философлары, әдәбият галимнәре һәм язучылары хезмәтләрендә дә, әдәби әсәрләрендә дә (Ш.Мәрҗани, Г.Тукай, Г.Исхакый, Җ.Вәлиди һ.б.) еш очрый, хәтта бу хакта Исмәгыйль Гаспралы тарафыннан «Дарер-рәхәт мөселманнары» исемле утопик әсәр дә языла.

Гарәп теле һәм әдәбияты буенча зур белгеч, Коръән-Кәримне дә тәфсирләүче Б.Я.Шидфар гарәп әдәбиятының Ренессанс эчтәлекле классик дәвере VI-XII гасырларга туры килә дип исәпли. Танылган

шәрекъ галиме Х.А.Р.Гибб урта гасырлардагы классик гарәп әдәбияты тарихын биш чорга бүлеп өйрәнүне кулай күрә. Алар түбәндәгеләр: 1) Каһарманнар чоры (500-622); 2) Яулап алулар чоры (622-750); 3) Алтын гасыр (750-1055); 4) Көмеш гасыр (1055-1258); 5) Госманлы төрек империясе яулары вакытында мәйданга чыккан «Мәмлүкләр чоры» (1258-1800). Галим тәкъдим иткән атамаларга карап, ул замандагы гарәп Ренессанс әдәбиятының нindирәк иҗтимагый-сәяси, әдәби-эстетик, этик баскычлар һәм эволюция кичергәнен дә тоемларга мөмкин.

Мәҗүсилек дәверендәге бәдәви гарәпләрнең бернинди чит тәэсирләргә бирелмичә, сүз сәнгатенең тиңдәшсез югары үсеш баскычына күтәрелүе — дөнья әдәбияты тарихында сирәк очрый торган күренеш. Аларның шигърият өлкәсендәге зәвыклары бик тә нечкә һәм нәфис булуы, шигъри гүзәллекне бар нәрсәдән өстен куюлары, шагыйрьләрнең иҗтимагый-рухи тормышта тоткан урыннарын бик югары бәяләп, аларны әйдәп баручылар, хатыйблар —җитәкче трибуннар дип кабул итүләре гарәп әдәбиятын өйрәнүче галимнәрнең барысында да гаҗәпләнү һәм соклану хисләре уята. Шуны күздә тотып, XX гасыр башында Муса Бигиев: «Гарәби шигърият башка милләтләрнең әдәбиятына иярмичә дә югары камиллеккә иреште, «гарәп телле дәрья» исеменә лаек булыр дәрәҗәдә белем чыганагы булды. Мин гарәби шигъриятнең фикердә дә, фәлсәфәдә дә бу югары дәрәҗәдә торуын күрдем. Шуңа күрә сөйдем, аны өйрәнергә теләдем, гарәби фәннәрне ихтирам белән кабул иттем», — дигән [6].

Академик И.Ю.Крачковский да «чын гарәп шигърияте төшенчәсенә бары тик исламгача булган Җаһилият һәм Өммәвиләр дәвере әдәбиятын гына кертә. Габбасилар дәвере һәм аннан соңгы гарәп әдәбияты грек, һинд, фарсы, төрки традицияләр белән катнашып китә һәм ул башлангыч чордагыча «чын гарәп шигърияте» булу хосусиятләрен югалта [7].

Соңгы вакытларда галимнәр матурлыкның югары ноктасы булган, изге Коръән өслүбенең, беркадәр соңрак классик гарәп поэзиясенең нигез ташларын тәшкил иткән Җаһилият дәвере шигъриятенең дә югарырак үсеш баскычында торган күршеләренең йогынты катламнары булуы турында яза башладылар. Күренекле әдәбиятчы Фәридә Әхәд кызы Азизова бу чит тәэсирләрнең бикләнеп яшәгән сыман тоелган җаһили гарәпләргә диңгез көймәләре һәм чүл кораблары — дөяләргә утырып килгән күршеләре аша да килеп ирешү мөмкинлеге турында яза [8].

Әдәбият һәм искәрмәләр

1. Конрад Н.И. Запад и Восток. Изд. 2-ое, исправ. и допол. — М.: Наука, 1972. — С.495.
2. Косиков Г.К. Средние века и Ренессанс. Теоретические проблемы // Методологические проблемы филологических наук. — М., 1987. — С.230.
3. Лосев А.Ф. Эстетика Возрождения. — М.: Мысль, 1982. — С.51.
4. Могалләкат — асып, элеп кую.
5. Хәйдәров Л. XX гасыр башы татар әдәбият белемендә гарәп әдәбияты мәсьәләләре. Канд. дисс. 2004.
6. Бигиев М. Гарәп әдәбияты һәм Ислам фәннәре. — Казан: Иман, 2000. — Б.15-16.
7. Крачковский И.Ю. Арабская поэзия. Избранные сочинения: в 6-ти томах: Т.2. — М.Л.: Изд-во АН ССР, 1956. — С.246.
8. Азизова Ф.А. Литературное посредничество как система в арабском халифате. — Баку: Элм., 2009. — С.301.

Дәвамы киләсе саннарда.

БАТЫРША

ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА,
язучы

Татар халкының иң зур фаҗигасе 1552 елда — Казан урыслар тарафыннан яулап алынгач башлана…

Ничә гасырлар буе гөрләп яшәп яткан татар дәүләте, татар иле юкка чыгарыла…

Шәһәрләр талана, авыллар туздырыла, кешеләр юк ителә…

Татар ханнары үтерелә, гаскәр кырыла, казна туздырыла…

Дәүләт белән бергә, милли тормыш та чәлпәрәмә килә — мәчет-мәдрәсәләр җимертелә, изге китаплар утка ягыла, матди һәм рухи байлык талана, милләт мирассыз һәм тамырсыз калдырыла…

Меңәр еллар буе шанлы дәүләтләр тоткан, иксез-чиксез ил-җирләр биләгән, зур гыйлемгә һәм байлыкка ия булган, бөек мәдәнияте белән дөньяны таң калдырган татар халкы бер мизгелдә илсез һәм җирсез, өйсез-дәүләтсез, хокуксыз бер кол хәлендә торып кала…

Басып алучыларга татарның җәннәттәй җирләре генә кирәк була, ә аның теле һәм дине, үзе кирәк булмый…

Татарны түзә алмаслык коллык, кара эш белән изү, сугышларга куып кертеп, юк итү башлана, исән калганнарын исә тиз арада чукындырып һәм урыслаштырып бетерү максаты куела…

Урыс кылычыннан һәм коллыгыннан могҗиза белән исән калган татар халкы, кара урманнарга, төпсез сазлыкларга качып, дала-тауларга таралып, телне, динне, милләтне саклау өчен тиңсез көрәшкә күтәрелә…

Бу көрәш гасырлар буе дәвам итә һәм бүген дә бара…

Дәүләтсез калган татар халкының азатлыгы, теле һәм дине өчен көрәш белән милләтнең каһарман уллары, дин әһелләре, галим-зыялылар җитәкчелек итә…

Алар татар дәүләтенең юкка чыгуы, милләтнең бетүе белән беркайчан да килешмиләр, югалган дәүләтне кире кайтару өчен гасырлар буе басып алучылар белән көрәшәләр, телне һәм динне бирмәс өчен сугышларга керәләр…

Күпләр бу тигезсез көрәштә һәлак була, дин юлында шәһит китә, әмма

соңгы сулышынача мөселман-татар булып кала, милләтенә дә шуны васыять итеп үлә...

Әйе, татар халкы беркайчан да үзенең коллыгы белән килешмәгән...

Татар беркайчан да үзенең иреге, теле һәм дине өчен көрәшен туктатмаган...

Без бәян итәчәк XVIII гасыр тарихы да тоташы белән татар күтәрелешләреннән тора. Чөнки бу чорда патша хөкүмәтенең татарларга каршы көрәше, басымы, явызлыгы моңарчы күрелмәгән дәрәҗәгә җитә. Татарларны көчләп чукындыруларның, чукынмаган өчен тереләй утта яндыруларның, төрмә һәм каторгаларга җибәрүләрнең, адәм күтәрә алмаслык салымнарның, лашманлык, казна заводларында кол булып эшләүләрнең иге-чиге булмый...

Бу гасырда урыс патшалары татар халкын милләт буларак юк итү максаты куялар — Идел-Уралда татарларга карата чын мәгънәсендә геноцид башлана...

Моны аңлап алган татар халкы, соңгы көчен җыеп, үз-үзен якларга ташлана. Корал тота алган һәркем коралга ябыша, чөнки шулай гына исән калып буласын аңлый алар. Шул ук вакытта милләт улларында югалган дәүләтне кире кайтару өмете дә сүнми, алар аның төрле юлларын эзләп карыйлар. Әйтик, 1708 елда, Солтан Морат исемле татар каһарманының, Казан өчен хан сорап, Төркиягә юлга чыкканы билгеле. Ул бу эшне Идел-Урал татарлары белән киңәшеп, аларның фатихасын алып эшли. Солтан Морат шактый зур гаскәр туплап, юл өстендәге Самара, Камышлы, Сергиевск шәһәрләрен урыслардан азат итеп, сугыша-сугыша Төньяк Кавказга хәтле барып җитә, Терек шәһәрен камап ала. Урыс гаскәре белән каты бәрелешләрдә Солтан Морат әсирлеккә төшә, аны Казанга алып кайтып асып үтерәләр.

Бу вәхши хәл татар халкында патша хөкүмәтенә карата бернинди өмет калдырмый, алар яу артыннан яуга күтәреләләр. Гасыр башында татар яулары белән Сәгыйть Җәгъфәр һәм Теләкәй батырлар җитәкчелек итә. 1705-1711 елларда милли азатлык көрәше башына Теләкәй улы Күчем баса, 1735-1740 елларда татар явы белән Күчем улы Акай һәм Акай улы Габдулла җитәкчелек итәләр. Татар халкының азатлыгы өчен яуларда Күчем ханның нәселе — Себер татарларының да ахыргача сугышуын әйтеп үтәргә кирәк. Татарлар бөтен нәселләре, авыллары, гаиләләре белән басып алучыларга каршы сугышалар. Шулай итеп, Идел-Урал арасында татарларның бер гасырга сузылган Ватан сугышы башланып китә... Идел-Урал арасы тел, дин, ирек өчен көрәшкән татарларның каны белән сугарыла...

1755 елда Идел-Урал арасында яңа татар явы кабынып китә. Тарих мәйданына, бер кулына Коръән, икенче кулына кылыч тотып, татар мулласы Батырша хәзрәт чыга.

Батырша-Баһадиршаһ...

XVIII гасыр уртасында татар халкын урыс илбасарларына каршы җиһадка чакырган, мөселманнарны дин һәм ирек өчен изге көрәшкә күтәргән, үзе исә ахырда патша зинданында кяферләр белән тигезсез бәрелештә шәһит киткән татар каһарманы...

Язмышы һәм тормышы дастаннарга тиң Батырша мулла...

Үзенең хак сүзе белән патша тәхетен тетрәткән, Идел-Уралны чукындырудан саклап калган Баһадиршаһ...

Кем соң ул, кайда туган, нинди нәселдән, кайларда шундый зур гыйлем алган? Төп сүзгә — Батырша явына күчкәнче, шулар турында да

бераз мәгълүмат биреп үтик. Кызганычка каршы, бүгенге көнгә хәтле Батыршаның туган елы төгәл билгеле түгел, аны 1715 дип тә, 1710 дип тә язалар, 1717 елларга кадәр якынайтучылар да бар. Бу хәл Батыршаның туу турында метрикасы бүгенге көнгә кадәр табылмаганлыктан килә, ягъни Батыршаның метрикасы башка урында булырга яки махсус юк ителгән булырга мөмкин. Батыршаның ата-аналары, чукындырудан качып, Нижгар ягыннан Уралга күчеп килгән мишәрләр булуы билгеле. Бәлки Батырша анда ук туган булгандыр, бәлки, галимнәр язуынча, элеккеге Казан губернасы, Уфа өязе Карышбаш (Югары Карыш) авылында тугандыр. Бу авыл хәзер Башкортстан Республикасының Балтач районына керә.

Батырша (Габдулла Галиев) башлангыч дини белемне башта әтисе Туктаргали абзый мәдрәсәсендә ала, аннан укуын Казан ягындагы мәдрәсәләрдә — Тайсуганда һәм Ташкичүдә дәвам итә. Дөрес, моңа каршы төшүче галимнәр дә бар, бу мәсьәлә ачык килеш кала. Безнең фикеребезчә дә, Батырша Урал аръягы мәдрәсәләренең берсендә, әйтик, Әлмәндә белем алмадымы икән дигән уебыз бар, чөнки ул соңыннан өйләнүен дә, укытуын да шул якларда — хәзерге Чиләбе өлкәсенең Мөслим авылында дәвам итә (1746-1749 еллар). Соңыннан ул туган авылы Карышбашка кайта һәм 1755 елга кадәр, ягъни яуга күтәрелгәнче, шунда мәчет имамы һәм мәдрәсәдә укытучы булып эшли. Батырша хәзрәт тирә-юньдә үзенең зур гыйлем иясе булуы белән аерылып тора, тәкъва мөселман, гадел кеше булуы белән танылa. Шушы сыйфатларын искә алып, аны 1754 елда Себер юлы ахуны итеп тә сайлап куялар.

Бу еллар — татар халкын иң хокуксыз кол хәленә төшергән, көчләп чукындыруларның иң вәхши төс алган, буйсынмаганнарны иң рәхимсез рәвештә юк иткән кара еллар, канлы еллар... Һәм болар барысы да — чукынмаган өчен татарларны тереләй утта яндырулар да, мәчет-мәдрәсәләрне юк итүләр дә, халыкны кол хәлендә иң кара эшләрдә газаплаулар да — барысы да Батырша хәзрәтнең күз алдында бара... Эчендә җаны булган, милләтнең киләчәге турында уйлаган, ислам диненә, мөселманнарга нинди зур куркыныч килгәнен бөтен йөрәге белән аңлаган Батырша хәзрәт соңгы адымга бара — халыкны басып алучыларга каршы изге сугышка — җиһадка чакыра. Сүзебез тарихка «Батырша явы» булып кереп калган шушы тиңсез күтәрелеш турында, аның төп әйдәүчесе, идеологы, каһарманы Батырша хәзрәт турында булыр, иншаллаһ!

***

Татар халкы дин һәм милләт өчен шәһит киткән Батырша хәзрәт турында бик аз белә, бу хакта белүче галимнәрнең кайберләре исә аның батырлыгын шик астына куя, имеш, ул җитәкләгән күтәрелеш барып чыкмаган, халыкны канга батырып бастырганнар, үзен һәм гаиләсен юк иткәннәр... Бу тарихи фактларда хаклык бар кебек тоелса да, хакыйкать тирәндәрәк ята, тулы дөреслекне белү өчен, Батырша яшәгән чорга, аның эшчәнлегеннән соң булган үзгәрешләргә игътибар итәргә кирәк. Шунысын да онытмыйк, Батырша хәзрәт исеме урыс тарихчылары тарафыннан патша чорында да, совет заманында да, нигездә, бары тик тискәре яктан гына искә алынды, аңа Россия империясен җимерергә теләгән фанатик, фетнәче мулла, реакцион дин әһеле — итеп карадылар. Ә Батырша күтәрелешенең төп максаты Идел-Уралда яңадан бәйсез мөселман дәүләтен торгызу була.

Октябрь инкыйлабына кадәр яшәгән урыс тарихчылары Батырша явына азмы-күпме дини төсмер бирделәр, әмма шуннан артыгын күрмәскә тырыштылар. Әйтик, танылган урыс тарихчылары С.Соловьёв, П.Рычков, Н.Фирсов, Н.Дубровин Батырша явының дини ягына әһәмият бирәләр. Алар бу хезмәтләрен язганда, хөкүмәт архивларына, Ырынбур губернаторы И.Неплюев язмаларына, генерал-майор Тәфкилев белешмәләренә, һәм, әлбәттә, Батырша хәзрәтнең рус теленә тәрҗемә ителгән хат-аңлатмаларына, халыкка мөрәҗәгатенә таяналар, шулардан чыгып эш итәләр. Әмма бу хезмәтләрнең берсендә дә татарларның милли азатлык хәрәкәте, шул исәптән Батырша явы да гадел яктыртылмаган, алар барысы да шовинистик рух белән сугарылган, Батырша хәзрәт үзе түбәнәйтеп тасвирланган. Бу күренешкә филология фәннәре докторы Мәсгуд ага Гайнетдин дә игътибар иткән.

«Үткәне юкның киләчәктә дәвамы була алмый, — дип яза ул. — Шул дәвамы, алдагы елларда да үсентеләре булмасын өчен дип, царизм Батыршаны оныттырырга, һичьюгы, аның кешелек һәм асыл характер үзенчәлекләрен бозып, пычратып, әшәкеләндереп күрсәтергә бар көчен куйган. Нигездә, барысы да монархистлык сызыгында торган революциягә кадәрге атаклы урыс тарихчылары менә ни өчен Батыршаны күзгә чалынмаслык кечерәйтеп һәм царизм теләгән рәвешкә кертеп күрсәтүдә кимен куймыйлар. Галимлек намуслары алдында акланырга сылтау бар: алар бит татар тарихын язмыйлар, аларга ул татар турында төпченеп утыруның кирәге шундый гына... Татар укымышлылары исә дәүләт серләрен ачкан архив материалларына якын җибәрелмәгәннәр.

Аның исемен телгә алу кузгалыш елларында катгый тыелган. Ул тыюлар да үз көчен революциягә кадәр саклый». (Мәсгуд Гайнетдин. Язмышыңа Җиңү язылган булсамы? // Дин вә әдәп. Иман нуры. 2005, октябрь. — Б.3)

Урыс тарихчылары тарафыннан Батырша хәзрәткә карата тискәре фикер октябрь инкыйлабыннан соң да әллә ни үзгәрми, алар өчен ул һаман «фетнәче-реакцион мулла» булып кала. Ә XVIII гасырда бөтен Идел-Уралны тетрәткән милли-дини күтәрелешләргә совет тарихчылары бөтенләй икенче төрле төсмер бирә башлыйлар, аларны тарта-суза сыйнфый көрәш кырына куып кертергә тырышалар. Имеш, халык патша хөкүмәтенә каршы икътисади авырлыкларга түзә алмыйча гына күтәрелгән икән, бу милли һәм дини ирек өчен көрәш булмаган, ә крестьяннар сугышы булган, имеш, аларда бөтен милләтләр дә катнаш-

кан икән... Шулай итеп, татарның дәүләт бәйсезлеге, дин һәм милләт иреге өчен гасырлар буе кулга корал тотып басып алучыларга каршы көрәшүе тагын изрәтелә, йомшартыла һәм тамак өчен сәнәк сугышына әйләндереп калдырыла. Бу нисбәттән А.П.Чулошников, С.М.Васильев, Н.Калинин, Н.Устюгов хезмәтләрен, совет чорында иҗат иткән кайбер башкорт һәм татар галимнәренең язмаларын мисалга китерергә булыр иде. Батырша явын махсус өйрәнгән Чулошников күтәрелешнең җиңелүендә турыдан-туры дин әһелләрен, Батырша хәзрәтнең үзен гаепли, имеш, ул хәлиткеч мизгелдә урманга кереп качкан, халкын ташлаган икән...

«...Эта слабая сторона их политической деятельности, роковым образом отразившаяся на ходе самого восстания, наиболее ярко выявилась в действиях и поступках самого главного и крупного из этих вдохновителей движения мишарского муллы Батырши, вышедшего из среды местного духовенства, — дип яза ул. — В этом отношении особенно характерным было, например, поведение Батырши в критический для движения момент, когда он, вместо того чтобы решиться на смелый шаг, требовавший от него некоторго политического риска, предпочёл для себя лучшим выходом из положения удалиться поспешно из своего аула в соседний лес и, скрываясь там вместе со своими учениками, пассивно выжидать дальнейшего разрешения событий». (Чулошников А.П. Восстание 1755 г. в Башкирии. — М.-Л., 1940. — С.63.)

Бу «урманга кереп качты» ялазын соңыннан башкорт галимнәре И.Акманов һәм Г.Хөсәеновлар да күтәреп ала, моңа үзләреннән, «сукынырга теләде», дип тә өстәп җибәрәләр. Шулай итеп, Батырша күтәрелешенең бәясен төшерергә тырышу, Батырша хәзрәтне түбәнәйтү яңа әйләнеш ала, чөнки совет тарихчылары өчен дә татар халкының милли азатлык көрәше каһарманын күтәрү һич кирәк булмый. Югыйсә, патшага каршы көрәште, дип, Пугачёв яугире Салават Юлаевка совет заманында ук Уфа уртасында һәйкәлләр куйдылар, аны башкорт халкының милли каһарманына әйләндерделәр, ә империягә каршы изге сугыш игълан иткән, басып алучыларга каршы кулына корал тотып сугышкан һәм төрмәдә каһарманнарча үлгән Батырша хәзрәтнең батырлыгын күрмәмешкә салышалар, аңа җай чыккан саен тибеп үтәләр...

«Из-за колебаний и нерешительности Батырши время было упущено, — дип яза башкорт тарихчысы Акманов. — К тому же сам Батырша вместо того, чтобы открыто встать во главе движения и бросить клич к восстанию, забрав семью и учеников, бежал в лес, тем самым окончательно деморализовав взявшихся за оружие башкир Осинской дороги. Поэтому Батыршу нельзя считать предводителем восстания, тем более называть это движение его именем, как ошибочно писали дореволюционные историки». (И.Акманов. За правдивое освещение истории народов. — Уфа, 1995. — С.57.)

Үзенең совет чорында ук чыккан китабында да Акманов Батыршаны гаепләп яза, аны яубашы буларак танымый: «Батырша не был ни организатором, ни идейным вождём восстания», — дип яза ул. (Акманов И.Г. Башкирские восстания в XVIII в. — Уфа, 1989. — С.64.)

Гомеренең күп өлешен Батырша тарихын өйрәнүгә багышлаган икенче бер башкорт галиме Гайсә Хөсәенов та үз героена карата каршылыклы фикердә. Батырша хәзрәт аның өчен «башкорт восстаниеләре»

фонында бер шәүлә кебек кенә кирәк, ул аңа — ипи ашата торган фәнни тема... Ягъни сүзе кирәк, үзе — юк... Югыйсә, ул Батырша хәзрәтнең туган авылында аны түбәнәйтә торган мондый сүзләрне сөйләмәс иде:

«Төрле төбәктәрзә кабынган ихтилалга етәкселек итеү һәм уларзы берзәм хәрәкәткә әүелрелдереп ебәреү урынына ул (Батырша. — Ф.Б.) үзен көтеп торган кораллы якташлары — гайнәләрзе ташлап, урманга касыузы хәйерлерәк күрә. Батырның бахырга әйләнеүе бына ошоннан башлана ла инде... Батырша, «ахыр был мәглүндәрзән йәмәгәтемне коткара алмамдыр, бары үз башымды коткарайым», тип, катынын, ике балаһын ташлап, Яхъя тигән шәкерте менән касып китә. Гаиләһе яттар кулына эләгә». (Батырша — выдающийся идеолог и вдохновитель восстания башкир 1755-1756 гг. — Уфа, 2000. — С.32-35.)

Моның Батырша хәзрәткә карата нахак бәла ягу икәнлеген башкорт галиме ничек аңламый икән? Тарихтан билгеле булганча, Батырша хәзрәт гаиләсен урманда ташлап качмый, ә ышанычлы кешеләр белән каенаталарына — Урал аръягына озата, әмма аларны юлда тотып алалар. Батырша хәзрәт, башкорт галимнәре хор белән кычкырганча, урманга кереп качмый, ә өен кораллы сатлыклар сырып алгач, гаиләсен алып, урманга китәргә мәҗбүр була... Тарихтан билгеле булганча, ул әле аннан да халыкны яңадан яуга күтәрергә тырышып карый, төрле тарафка үзенең шәкертләрен юллый, әмма инде вакыт үткән була, Урал тауларын урыс гаскәрләре чорнап ала... Батырша хәзрәтнең «Гарызнамә»сенә таянып кына, башкорт галимнәре аның «сукынырга теләгәнен» куертырга яраталар. «Гарызнамә» — төрмә шартларында язылган аңлатма, анда төгәлсезлекләр дә, буталулар яки махсус бутарга тырышулар да булырга мөмкин, шуңа күрә «чукыну» темасын да, галим Мәсгуд ага Гайнетдин язганча, Батырша хәзрәтнең бер хәйләсе итеп кенә карарга кирәк. Әгәр ул чукынырга теләсә, бу яуга чыкмаган да булыр иде, әгәр Батырша хәзрәт төрмәдә христиан динен кабул иткән булса, хөкем ителүдән котылган булыр иде, гаиләсе белән яңадан кушылып, башка татарларны да чукынырга өндәп йөрер иде... Әмма ул бу адымга бармый, иманын сатмый, милләткә хыянәт итми, ислам дине, татар халкы өчен җанын бирә...

Кайберәүләр ни өчен һаман Батырша хәзрәтнең намуслы исемен пычратырга, ул эшләгән рухи батырлыкны кечерәйтеп, түбәнәйтеп күрсәтергә телиләр соң? Батырша хәзрәтнең батырлыгы нәрсәдә: халыкны басып алучыларга каршы яуга өндәүдәме, көрәшкә күтәрүдәме, төрмә шартларында да иманы, җаны өчен палачлар белән тиңсез көрәш алып баруындамы? Әллә инде шушы көрәшнең нәтиҗәләрендәме? Әлеге сорауларга җавап бирми торып, Батырша хәзрәтнең милләт һәм дин өчен эшләп калдырган гамәлләренә тулы бәя бирә алмабыз, мөгаен. Ул чордагы гаять катлаулы вазгыятьне белми торып та, бу фаҗигале хәлләрне тулысынча аңлый алмабыз. Ә Батырша хәзрәт — үз чорының баласы, милләт күргән бөтен авырлыкларны, динебез өчен бөтен михнәтләрне ул да күргән, шуның тере шаһиты булган. Зур дин галиме, Коръән буенча фәтвәләр чыгаручы казый, бөтен Себер юлы мөселманнарының җитәкче-ахуны Батырша хәзрәт, Идел-Уралда мәчетләр юк ителгәндә, халкы көчләп чукындырылганда, милләте һәм дине бетү алдында торганда, басып алучыларга каршы изге сугышка күтәрелә... ■

Дәвамы киләсе саннарда.

ХӘЙДӘР ГАЙНЕТДИННЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

ХӘЙДӘР

(Мин белгән Гайнетдин)

ФӘРИТ ЯХИН,
филология фәннәре докторы,
Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры

I. КЫЗЫЛ МУЕНСА

1982 елда Хәйдәрнең (Хәйдәр Гайнетдиннең) «Ут теле» исеме белән шигырьләр җыентыгы басылып чыкты. Ул вакыйга студент елларымда булды. Тулай торакта шунда ук сүз таралды. Җыентыкны күрәсе, сатып аласы, укыйсы килү теләге белән күпләр яна башлаганнардыр. Мин дә китап кибетенә йөгердем.

Сатып алдым, шул кичне үк укып та чыктым һәм күңелдә бу китапны «Кызыл муенса» дип атау теләге туды. Моның сәбәпләре дә бар иде. Беренчедән, аның һәр шигырендә куплетлары гүяки аерым-аерым яшиләрдер сыман тойгы калды. Икенчедән, аларны үзара ниндидер сизелмәслек җеп кенә бергә җыеп, бер шигырь ясап торадыр төсле. Ул җеп менә-менә өзелә дә шигырь-муенсалар куплетларга-төймәләргә таралалар да китәләр. Өченчедән, монысы инде «кызыл» булуларына хәйранлыктан, шигырьләре һәммәсе дә дөрес, тәртипле, ягъни коммунистик тәрбия идеологиясенә буйсынган. Ә югыйсә аларда «Яшә партия – яшик без!» ише лозунглар да, социалистик хезмәт батырлыгын данлау да юк, әмма коммунистик хис эченнән-тышыннан аңкып тора. Шуңа да «Кызыл муенса» инде ул.

Хәйдәр журналист һәм шагыйрь, язучы буларак, әлбәттә, тулысынча диярлек идеология вәкиле иде. Әмма ул үзен шул чакларда да коммунистик идеология хезмәтчесе дип санамаган. Безнең татар дөньясында демократия тойгысы хисләре чирләшкә, зәгыйфь, мескен бала сыйфатында дөньяга килде, баздагы бәрәңге сабагы кебек үрмәләп үскән булды. Аның һәр ягында коммунистик идеология һәм шул идеологиянең куәтле күләгәләре иде.

Сулдан уңга: М.Вәлиев, Х.Гайнетдин, Р.Ишморат, М.Әгъләмов, Р.Низамиев. 1982 ел

II

Минем хаталы уйлавымда Хәйдәр (мин аны Хәйдәр абый дип йөрттем югыйсә) телгә усал, төгәл, иң хәтәре — батыр иде сыман. Аның әйткәннәрен күпләр күтәрә алмаган кебек хәтердә. Катгый итеп әйтелгән төгәл сүз кешенең үзенә кайтарыла. Хәйдәрнең иң көчле шигырьләреннән берсе «Әйтер сүзем» дип атала. Аңа кереш буларак, эпиграф итеп Муса Җәлилнең «Соңгы җырым палач балтасына башым куйган килеш языла», шигъри юллары алынган.

Эчтәлеге дә гадидер сыман. Лирик геройның тел очында әйтер сүзе тора, әмма ул өзелмичә «сабагында калган җиләк кебек» кипкән. Сусыл чагында шуны замана авыз иткән булса, уйнап-көлеп алга омтылачак икәнлеге дә белдерелә. Әмма ул сүз әйтелми калган. Хикмәт шунда ки, әгәр дә ул сүз әйтелсә, шул әйтелгән сүзенә лирик герой кол булачагын белә, әйтми калдырса — ул әлегә аңа үзе хуҗа. Заман уза, ә сүзе лирик геройның тел очында кала.

Торгынлык чоры интеллигентының, тулы бер чор шәхесенең холкы да, сабырлыгы да, һәлакәте дә чагылдырылган шигырь бу. Хәйдәр дәвер һәм заманны күңеле аша уздыра, тоя, хәтта үзгәртергә мөмкин дип санаучы затлы әдипләребезнең берсе булды. Бу шигырендә аның лирик герое кызыклы күзәтү ясый: *«Ак күбеккә баткан заман чаба, бу болытлар, гүя, ап-ак күбек»*, — ди ул. Шигырьнең беренче аккордында белдерелгән шул сүзләр ахырда әсәрнең фәлсәфәсен төйнәп кую өчен хезмәт итә: *«Узып китте заман, карап калдым, баш очында һаман ап-ак күбек...»*

Шагыйрьләр хыялны, өметне, хиснең сурәтен тасвирлаганда болыт символына еш мөрәҗәгать итәләр. Бу шигыре белән Хәйдәр, замана-

лар узуга карамастан, хыялның, өметнең, хиснең яшәешен кешеләрнең күңелләреннән югалмавын тасвирлый. Аның лирик герое — идеалист, аңардан тәүфыйк, мәртәбә, акыл бөркелеп тора. Әмма ул үз сүзенә үзе кол булудан курка, аны әйтми калдырып, замананың «уйнап-көлеп чабуына» ярдәм итмәгән, ягъни шул кирәкле, тиешле сүзен күңелендә җыеп, сүзенә, шул рәвешле үзенә хуҗа булса да, тик ахырда барыбер шул әйтми калдырган сүзенә коллыкка төшкән түгелме?

Хакыйкатьтә шулай килеп чыга да: күңелендәге сүзен кеше әйтергә тели, әмма белдерми калдыра, кат-кат үлчи, нидәндер курка, ахырда шул әйтелмәгән сүзе аның үзен үк юк итә. Бары тик сүздән гамәлгә күчү генә кешене коткарып кала ала. Бу әле әйткән сүзеңдә тору, аңа тугры калу гына түгел, бәлки рухыңны сүз авырлыгыннан азат итү юлы да.

Хәйдәр сүз кешесе иде. Әмма сүздә талымсызлык күрсәтмәде. Гадел хөкем итәме, юкмы — аңа бу хакта искәртергә туры килә иде — алар аны борчымый, ул бөеккә әверелә барды. Ак болытлар биеклегенә ирешү юлында кирегә борылырга теләмәгән шәхес гаделлекне үз күз күреме белән үлчи.

III

Хәйдәр сиксәненче еллар буынының иң талантлы шагыйре иде. Алар берберсен иҗатта танымаучы, тормышта санга алмаучы, тәнкыйтьтән аек акыл, затлы бәя, дөрес үлчәү өметендә яшәүчеләр булып тарих сәхнәсенә шәхси драмаларын трагик герой сурәтендә уйнап кереп киттеләр. Бу иҗтимагый һәлакәтебезнең ачык тамашасы иде. Ә тамашачы хәлендә калганнарга бары тик тетрәнү, шуның белән бергә күңел юанычы халәте килми мөмкин түгел. Һәм шулай булды да.

Хәйдәр белән 1990 елның июнь ахырында таныштым. Аңа кадәр мин аны күреп-танып белмәдем. Ул вакытта завод эшчесе идем. Казан йортлар төзелеше комбинатында өченче цехта формаларга салучы, аңа өстәмәдә төзелештә хезмәт куючы, алар белән бергә журналистика һәм әдәбият белгечлекләре буенча филология фәннәре кандидаты, тагын да шигырьләре, хикәяләре матбугатта күренгәләп алгалаган кешеләрдән булсам да, күңелем тулы сагыш уты яшәгән чаклар бу. Очраклы рәвештә генә «Яшь ленинчы» газетасы редакциясенә кердем. Кичке вакыт. Журналистлар таралышырга өлгергән. Госман Садә һәм Хәйдәр Гайнетдинов бүлмәсенә уздым. Йомышым да юк иде сыман. Редакциягә менә-менә яшь каләмчеләр кунакка килергә тиешләр икән. Өметле талантлар! Андыйлар ниргәсендә йөрергә бер дә насыйп булмаганлыктан, тизрәк китү җаен уйладым. Радиодан Хәйдәр «Пәйгамбәрләр тарихы»н газеталарында бастырырга вәгъдә иткән. Ә аннары галимнәр арасыннан бу эшне башкарып чыгарлык кешене эзләгән, муллаларны йөреп чыккан. Ышандырып, җаваплылыкны җилкәсенә алырлык һичкемне табалмаган.

Беренче соравы да шул булды:

— Пәйгамбәрләрне беләсеңме?

Аның күзлеге калын, зур иде. Күзләре шарлар булып, бөтен бар йөзен каплап алгандай тоелды. Җавабым җиңел һәм гади чыкты:

— Беләм!

Ул шунда ук:

— Бер айдан язып китер! — диде.

— Ярар, — дидем.

— Вәгъдәме? — диде ул, ышаныргамы-ышанмаскамы кебек хис белән янган хәлендә. Инде күзләре дә кечерәеп, йөзенә дә елмаю чыкты.

— Ярар, — дидем.

— Булды, сөйләштек! — диде ул. «Күрербез», имеш.

Сүз беткәнне аңлап, әлегә кемнән әмер алганымны да төгәл генә белмичә, бүлмәдән чыгу ягына атладым. Хушлашасы идем.

— Тукта әле, болай гына китәсеңмени? — диделәр.

Тыелып калдым. Ни хакында сүз барачагын көттем. Әмма алар икесе дә чыгу ягына атладылар. Коридорның тәрәзәле очына килдек. Дөнья барышын сөйләшеп алу булды. Госман Садәдән:

— Ул абый кем? — дип, «хәзер киләм» диярәк киткән кешене сорадым. Гаҗәпләнде.

– Шушы бит инде гений Хәйдәр! — диде ул. — Аны да белмәскә!

Хәйдәр әйләнеп тә килде. Әмер дә итә башлады:

– Балалар күтәрелә. Алар белән очрашуга керәбез. Без очрашуны алып барырбыз, сөйләрбез. Сиңа да сүз булыр, пәйгамбәрләрнең берәрсе хакында кыскача гына хәбәр бирергә әзер тор! — диде ул миңа.

— Ярар, — дидем, гадәтемчә гади һәм җитди төстә.

Ул көнне очрашуда Йосыф пәйгамбәргә бәйле вакыйгалардан бераз сөйләдем. Балалар үз әсәрләрен укып сөендерделәр. Очрашу озакка сузылмады. Сәгать эчендә таралыштык та.

Бер айдан «Пәйгамбәрләр тарихы»ның газета вариантын редакциягә китердем. Хәйдәр, кулына язмамны алып, авырлыгын үлчәгәндәй итте дә, өстәл тартмасын ачып, аны шунда салды, япты. Аннары:

— Ярар, булган бу! — диде.

Мин үз эшемә киттем.

Вакытлар узгач, «Пәйгамбәрләр тарихы» китабым басылып чыккач, интервьюлар биргәндә һәм сүз ара сүзләр чыкканда Хәйдәргә бу эшкә юнәлтүе өчен рәхмәтләремне әйтүне гадәт иттем. «Пәйгамбәрләр тарихы»ның газета варианты «Яшь ленинчы»да басылып чыккан вакытта Хәйдәр анда эшләми иде инде. Аңа рәхмәтләрем язмаларым дөнья күрүдә төп рольне башкарган мөхәррирләрне бәлки кимсеткәндер, алар алдында соңарып булса да гафу үтенәм: кичерә күрегез!

IV. МАҖАРАЛАР КЕШЕСЕ

Хәйдәр авантюралар остасы кебек тә иде. Аны турыдан-туры «ул авантюрист» дип әйтеп булмый, хата чыга. Хәйдәрнең авантюралары бары тик мажаралык белән дөньяны ямьләндерергә омтылышыннан килә иде дисәм, ялгышмамын. Баштан ук тирәнтен уйлап, әмма импровизацияләргә урын калдырып, асылда акыллы шуклыкка корылган андый гамәлләрен ул ышаныч, мәртәбә белән оештырып алып бара белде. Әлбәттә, маҗара-авантюралардан могҗизалар да көтелә. Бу очракта шушы маҗарада катнашучылардан сабырлык, белми калучанлык тойгысы да сорала. Кеше юләргә калырга теләми, шунда ук саклану инстинкты уяна һәм мине ахмакка калдырырга итә бу дип уйлый. Шул сәбәпле күп вакытларда маҗараларның ахырына кадәр барып җитә алмыйча, әлеге маҗарадан могҗиза килеп чыкмый кала, уеннан уймак кына табыла. Хәйдәрнең могҗизалар коруы аның шуклыгыннан килгәнгә, дуслары аның нәрсә уйлаганын тиз төшенә иделәр. Үзләренең дә шул уенга катнашып китәргә осталыгы җитә.

Хәйдәр үзе белән сак булырга һәм үлчәп сөйләшергә өйрәтте. Асылда барлык фикер алышуларыбыз әдәбият тарихы, үз көнебез хәле тирәсендә әйләнде. Аның хәбәрдарлыгы киң. Югары белеменә өстәп ул әле әдәби

курсларда укыган, Мәскәүнең бөек галимнәренең лекцияләренә йөргән. Әдәбиятка бәйле иркен карашлы кешеләр сирәк була. Хәйдәр татар әдәбиятының киләчәген хакыйкатьне мификлаштырып тасвирлау белән бәйле әсәрләр иҗат итү юлында дип белә иде. Аның көчле әдәби әсәр миф тудырырга тиеш, дигәне халкыбызның борынгы дөньяга карашын яңартырга кирәклек мәсьәләсенә килеп төртелә торды. Әмма ул мифларны фәнебездә кем өйрәнгән, тәртипкә салган соң? Бу өлкәдә галим һәм язучы Галимҗан Гыйльманов шөгыльләнүен белгәч, зур кызыксынуын сиздереп, аның хезмәтләре дөнья күрүен зарыгып көтеп алды. Аерым томнар буларак алар басылып чыккач, өстәл китабына әверелделәр бугай. Шушы юлда эзләнүләре Хәйдәрне галим-фольклорчы Фатих Урманчиев белән дуслаштырды.

Телевидениегә дә Хәйдәр импровизация ысулын алып килде. Узган гасырның туксанынчы елларында татар телевидениесе шуның аркасында күтәрелде дә. Кайвакытларда болай да була иде: Хәйдәрнең тапшыруы әзерләнә, әмма туры эфирга чакырылган кунагы килә алмый. Алып баручы журналист буларак, ул аны алыштырырга кеше эзли. Таба алмый. Ике сәгатьтән тапшыруы башланачак. Миңа шалтырата: «Килмәсәң, башка чакыру юк, беттең», — ди. Мин, сәбәп эзләп, әле кичә генә аларда чыгыш ясавымны искәртәм. Ул кабул итми. Кисәтүен кабатлый. Тыңлаучан кеше йөгерә инде. Эш өчен кирәк бит! Хәтта нинди сорау бирәчәген дә алдан әйтеп тормыйча, камера каршысына утырта. Импровизация ысулы, әлбәттә, көтелмәгән сорауга нигезләнә. Тапкырлык та, белем дә кирәк булгандыр? Ә ул киң мәгълүмат иясе затлы зыялыларыбыздан иде.

Шулай бервакыт үзе килде дә:

— Иртәгә синең турыда материал әзерләү өчен, туган якларыңа китәбез. Машинаң белән алып барасың, — диде. — Мөдәррис Әгъләмовыңны да алабыз!

«Жигули» машинасына утырган гына, йөртү осталыгым да чамалы чаклар иде әле бу. Моңа кадәр алдарак минем хакта телетапшыру ясаячагы турында бер тапкыр тел төбемне тарткалап алуын да хәтеремнән җуймыйча, ризалаштым. Камерага төшерәчәк операторы Чаллыда икән. «Аны да үзебез белән алачакбыз!» — дип белдерде ул юлда.

Кайттык. Туган якларымны күрсәттем. Мәктәптә матур гына очрашу да уздырдылар, районда да яхшы кабул иттеләр. Туган йортымда кич кунып, икенче көнне Зәй тарафына юнәлдек. Инде белә идем: безнең бу кайтуыбыз, асылда, аның үз мәктәпләренең юбилеенда катнашу максаты белән дә икән. Анда Мөдәррис Әгъләмов та укыган, Роберт Батулла да, Наил Дунай да, тагын да күпме данхөрмәт ияләре, эшмәкәрләр, дөнья гамәлләрен җитәкләүчеләр...

Үз мәктәпләре директорына Хәйдәр, мул елмаеп:

— Үзем генә кайтмадым, менә бүләгем! Үзеннән сора! — дип миңа төртеп күрсәтте. Хәер, сүз без кайткан машина хакында бара түгелме дип тә уйларга мөмкин иде. Ул арада берничә күңелле мәзәк тә сөйләп алды Хәйдәр. Маҗарага маһирлыгы аны ал да, гөл дә итә иде шул.

Юбилей бәйрәмнәре бик матур узды. Батулланың шундый оста сөйләүләре, концертларының яхшылыгы — барысы да хәтеремдә.

Китәр алдыннан яныма мәктәп директорлары килеп басты. Юбилей бүләге хакында сүз катты. Мин инде нинди шаяртуга корбан булуымны тәмам аңлап җиткергән идем. Машинамда берничә китабым булып,

шуларны бүләк итеп бирим, дидем. Ярый да аңа гына риза булсалар?

V

Минем хакта аерым тапшыру оештырыласын инде белсәм дә, ул турыда сүзне башка кузгатмадым. Берәр ай вакыт узгандыр. Операторының тырыш хезмәтен дә исенә алып, сабырлыктан да файдаланып, Хәйдәр ул эшен җиңел генә ахырына кадәр җиткерде. Аңа шул телевизион тапшыруы өчен зур рәхмәттә булдым.

Хәйдәр җырга бик тә маһир, ул сәнгатьнең дә чын остасы иде. Илһам Шакиров белән туганнар. Хәйдәрнең әнисе Гыйльмисафа — Илһам Шакировның апасы. Мөдәррис Әгъләмовка да туганлыклары барлыгын үзләре сөйләгәннәрдән, ишетелгән хәбәрләрдән беләм. Әтисе Гайфетдин ягыннан Хәйдәрнең нәселе әдипләребез Разил Вәлиев, Зөлфәт Хәким, Рафис Сәлимҗановка барып тоташканын 2002 елда «Шәҗәрәләр» китабында шагыйрь һәм галим Дамир Гарифуллин тәфсилләп язып та чыкты, борынгы бабалары Йосыф исемле икәнлеген ачыклады.

Хәйдәр «Иске карурман»ны, «Уел»ны җырлый. Кайвакытларда Илһам абый Шакиров белән килеп чыгалар. Әдәбият, сәнгать турында иркенләп фикер алышабыз. Илһам абый Шакиров — гаять тә киң мәгълүматлы, титан шәхес. Бервакыт Хәйдәргә:

— Тавышың Илһам Шакировча матур, тетрәндергеч. Әмма аның ноталары шулкадәр түгәрәк, камил, матур чыгалар, ул хәтта ярымнарын да төгәл ала. Моңы — искиткеч. Андый җырчы башка юк. Аңа ияреп, аңа охшатып кына җырларга мөмкин. Тик андый иярчен җырчыны талантлы дип булмас. Ул кеше һөнәрче аталыр. Шулай түгелме? — дидем.

Сүзләремне, бигрәк тә «һөнәрче» дигәнемне авыр кабул итәрен башыма да китермәгәнмен. Аның йөзе үзгәрүеннән шунда ук артыгын сөйләп ташлавымны аңлап алдым һәм, гафу үтенеп:

– Дустым, зинһар, сине әйтүем түгел иде, — дидем. — Син бит җыр җырлап «тамак туйдыручы» түгел. Җырчылар исәбендә йөрмисең, язучы, журналист кешесең!

Әмма ул шушы «һөнәрче» сүзем өчен шактый ныклап үпкәләде, «аркам белән егып түбән салырга», моны башкалар алдында тел куәте белән башкара алу осталыгын күрсәтә белү ягыннан да ачылып китте.

VI

Дөрес аңларга кирәк: Хәйдәр фәрештә түгел иде. Хәер, адәм баласыннан фәрештә булуны таләп иткән дә юк. Ул мәктәп укытучылары гына укучыларының фәрештә булуларын телиләр һәм моны «баладан кеше ясау» дип атыйлар.

Бервакытны Хәйдәргә, бик талантлы шагыйрь булуын әйтеп, аңа «Ут теле» китабыннан бер шигырен укыдым. Ул, бәлки, шаяртамдыр дип уйлагандыр. Фикерләренең, сурәтләренең хакыйкатьне тирән ачып, тәэсирле итеп күңелләргә үтеп керерлек кимәлдә икәнлегенә басым ясадым. Ә никадәр гадилек, гадәтилек бу юлларда, табигыйлек!

ТОРМЫШ БИТ БУ!

Дөнья куа-куа
Беттем инде менә өтелеп.
Нурсызланды бугай күңелем дә
Караучысыз калган өй кебек.

Күпме яшерсәм дә, сорашалар:
әллә каян, читтән уратып.
Сорасалар:

– Хәлем бик әйбәт! — дим,
әнкәйләрне була юатып.

Юатырга була сөйгәннәрне,
ышандырып була дусларны.
Бәйләнчекләр очрый калса әгәр:
— Төпченмәче, — дим мин, —
юк-барны!

Тик йөрәкне булмый ышандырып, –
чыгар минутларын саный күк.
Елап туйган…
Хәзер ишек шакый
бикләп калдырылган сабый күк…

Гыйнвар, 1981 ел.

Әмма аның шулкадәр ачуы килде. Кулымнан китабын тартып алды да читкә томырды. Аңладым: ул үзенең шигырьләрен, алардагы күңел серләренең ачык сурәтләнүен сөйми икән.

VII. ДУСЛЫК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Хәйдәр үзенең кемлеген яхшы белүче кеше иде. Дәрәҗәсен түбән куймады. Кешене кеше илдә тоткан дәрәҗәсенә карап хөрмәтли. Хәйдәр бу кагыйдәне төгәл үтәп барды дип беләм. Бервакыт ул мөфти Тәлгать Таҗетдин белән килеп керде. Илдә дини сәясәтнең үзгәргән вакыты иде. Татарстан мөфтиятенең оешу җыелышы «Тукай» кинотеатрында узды. Әшне әйдәп йөрүчеләрдән Зөфәр хәзрәт (инде ул данлыклы архитекторлар исәбендә республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты булды) шул утырышның карарларын әзерләргә мине чакырды. Һәр төбәктә мөфти булуга шәригатьтә каршылык юк икәнлеген аңа гына түгел, бу юлы шул мәртәбәле җыелышка аңлатып, шунда ук эшләп биргән карарларым да булышлык иттеләр. Үзем белән алып килгән машинкада оештыру җыелышы барышында ук турыдан язып әзерләнгән шул карарларның кабул ителүендә өлешемне сөйләп, барлык җаваплылыкны үз өстемә алганымны сиздереп:

— Ялгышкан булсам, мөфти хәзрәт, мине ачуланыгыз! — дидем.

Тәлгать Таҗетдин миңа елмаеп карап торды да болай диде:

— Вакытлы, дөрес, кирәкле ул карарларның авторы сез идегезмени?

Шунда Хәйдәр, хәзрәтнең сүзләренә олы хөрмәт күрсәтеп:

— Динне мөфтиләрнең артуы үстереп җибәрә! — диде.

Инде сөйләшүебез тагын да җанланып китте. Кешеләрнең мәртәбәсен төгәл аеручы Хәйдәр оста дипломат шәхес буларак ачылды. Мөфти хәзрәтләренең акылы, белеме, дөньяга һәм дингә, милләткә карашлары күңелдәге икеләнүләрне юып ташлады. Бөек кеше икәнлеген төшендем. Мәҗлесебез иң четерекле мәсьәлә — дөньяви һәм дини кешеләр хакында фикерләшүләр белән уратылып алып барылды. Тәлгать Таҗетдин шунда Хәйдәргә һәм миңа дөньяви кешеләр булып калуыбызны теләп фәтвасын бирде.

Соңыннан да бу очрашуны искә алып сөйләшкәндә, Хәйдәрдән:

— Ни өчен мөфти безнең дин юлыннан китүебезне теләмәде икән? — дип сорагач, ул:

— Беренчедән, Тәлгать Таҗетдин бик акыллы кеше, икенчедән, синеңминем нинди камырдан ясалганыбыз күренеп тора, өченчедән, аларның анда үз дөньялары киштә-киштәлекләрендә мыскалына кадәр бүленгән! — диде.

Аңлаган кешегә шушылар да җиткән, күп вакыйгаларга аның бу билгеләмәләре ачык дәлил иделәр. Кабат ул темага әйләнеп кайтмадык.

VIII

— Сине Язучылар берлегенә алырга теләкләре бар! — диде бервакыт Хәйдәр.

— Белмим инде, — дидем мин аңа җавабымда. — Ул — «колхоз»га керү кебек нәрсә булмасмы соң?

Бу вакытта инде колхозлар таралып, бетеп маташа иделәр. Бер данлыклы һәм бөек журналист-язучыбыз да Язучылар берлеген колхозга тиңләп мәкалә язып чыгарган иде.

— Китапларың бар, исемеңнең танылуы да җиткән. Яңа төр, яңа фикерле кешесең, — диде Хәйдәр. — Аннары, дөрес аңла, кәҗәң килмәсен, хикмәте дә бар: сиңа ияртеп кенә тагын бер-ике кешене уздырырга кирәк!

Аның оста стратег, эшне оештыра һәм кора белүендә һичбер шигем юк иде, әмма кемнәр файдасынадыр мине «ширма», хәтта «көтү тәкәсе» итәргә теләвенә хәйран иттем. Артыма качырылып Берлеккә уздырылган кешеләр ахырдан барыбер дә рәхмәт әйтмәячәк, көнчелек күрсәтәчәкләр әле, җитмәсә.

Үз уйларымны сиздермәскә тырыштым. Икеләнгән булдым. Аннары, әгәр дә дустым икән, ни өчен миңа «ширма» язмышын юрый?

— Берлеккә кергәч, язган әсәрләреңне бастырып чыгару мәсьәләсен дә җиңел хәл итәрсең! — диде ул.

Бу сүзләре икеләнү-кирелекләремне юк иттеләр. Ничәмә китабым басылмыйча ятканын, китап нәшриятлары тарафыннан кабул ителми аптыратуларын исемдә тоттым.

Нәкъ Хәйдәр әйткәнчә булды. Аның кешеләр белән сөйләшә белү осталыгы, эшләрне стратегик яктан оста оештыруы үзен күрсәтте. Ә аннары ул, мәсьәлә чишелгәч:

— Амбразурага Газинурлар гына түгел, менә син дә капландың! — диде, вакыйгаларны көлә-көлә искә алып.

— «Колхоз»ны әйтәсеңме? — дип, мин дә шаярттым.

Язучылар берлегенә бишкуллап алсалар да, китапларымның, әсәрләремнең басылып чыгуына моның файдасы булмады. Әмма бәлаләре…

— Сине Язучылар берлегенең рәисе итеп күрергә телиләр! — диде ул беркөнне, мине тәмам хәйранга калдырып. — Монысының срогы чыга.

Бу юлы ике аяклап киреләнеп каршы чыктым. Минем ише сүз тыңламаучыларны чәнчә бармак белән генә җиңәргә өйрәнгән Хәйдәр бераздан килеште. Ишәген нуктасы белән бергә ташлап киткән Хуҗа Насретдинга әверелде. Сүзләре дә онытылды. Алар бервакыт кабат һәм кинәт калкып чыгарлар дип көтмәгән идем. Съезд якынлашкан саен, күңелгә утны аз-азлап сала-сала, ризалыгымны алуга иреште. Әмма мин аңа:

— Беркем белән дә сайлауларын үтенеп сөйләшмәячәкмен, беркемне дә үгетләмәячәкмен, дуслык хакына гына ул уенына катнашырмын, бу юлы да «ширма» булырмын, — дидем.

Язучыларның уенда мине рәисләре итеп сайларга теләге барлыгын күпләр телгә ала башладылар. Әлбәттә, ниятемне белү сәясәте генә иде бу, дидем үзалдыма елмаеп. Аларның да билгеле бер уен корбаннарыннан яки уенчыкларыннан булулары бик мөмкин иде. Рәислек һич тә кызыктырмады, нindидер ят, шикле җир кебек тоелды миңа. Инде Хәйдәрнең сүзен аяк астында калдырмаска тиеш идем. Ул вакыттагы рәис әфәнде, чакыртып, ресторан сыйлары белән кунак итеп, уемнан кире кайтуымны сорады. Аңа бу эшнең миннән тормавын кат-кат, ничә мәртәбәләр аңлатырга туры килде. Ә ул барыбер дә үз шигендә, үз

фикере коткысында калды. Мин инде күптән кемнәрнеңдер сәясәте барып чыксын өчен корылган «ширма» гына идем. Рәиснең үз дусларына да качып уйнарга яхшы җай иде бу. Әгәр дустым Хәйдәр шул көчле кешеләрнең берсе икән, мине ул уенга корбан итүенең асыл сәбәбе бар булыр, дидем, ролемне ахырына кадәр башкарасы гына калды.

Берлек съездының рәте булмады. Ул берни дә хәл итә алмыйча ябылды. Җәй урталарына җыелырга карар ителде. Аскы һәм өске агымнарга иярмичә калуыма сөенсәм дә, хәлемнең көенечле икәнлеген дә беләм, Хәйдәрнең, дус дип йөргән кешенең, нинди уенга мине корбан итүенә дә хәйранлыкта идем.

IX

Иң кыены шул — синнән уенчык ясауларын аңлап-белеп торасың, әмма бу тозактан чыга алмыйсың.

— Мине рәислеккә күрсәтсәгез, сикереп торам да, мин булырга теләмим дип, барысы каршында әйтәм!

Шушылай уемны-теләгемне Хәйдәргә белдергән идем, ул:

— Шул сәгатьтә-минутта ук сукыр бер тиенлеккә әвереләсең киләме әллә! — диде усалланып, ачуланып. — Андый кеше синнән башка да булыр. Күрербез!

Хәер, дөнья йөзендә һәр җан иясенең үз урыны бар, диләр бит, шулай булсын да, ди...

Хәйдәр миндә Язучылар берлеге рәисе булу теләген тудыру эшенә инде ныклап кереште. Әмма аңа фән белән шөгыльләнү уенда булуымны, институтка эшкә күчеп йөрүемне бөтенләй әйтмәдем. Аның — үз уе, минем — үземнеке.

Ә «ширма» ролен башкарырга барыбер туры килде. Язучы кеше тормышны, халыкны аңларга, төшенергә теләсә, үзе белән уйнауларын күреп, шул уенның ахырына кадәр бара да белергә тиеш. Шулай уйладым, шулай эшләдем. Хәйдәр артында кемнәрдер тора һәм ул да аларның теләген үти иде, ахрысы. Югыйсә бу тормышның һәммә яклары да аны үз дулкыннарында йөртмәскә, ул үзе дә күп мәсьәләләрдән чикләнергә тиеш иде. Ә яшәеш аны һәммә эресе-вагы белән үз куенына алды. Дөньяның гүяки төзүчесенә, төзәтүчесенә, иясенә әверелә барды Хәйдәр. Ул әйткән сүзләрне бүген башкалардан ишетсәм дә сәерсенмим, аның һәр сүзе, фикере, теләге аларның акылы-күңеле аша узган икәнлеге сизелеп тора.

X

Хәйдәр озын буйлы, күркәм кешеләрнең берсе булды. Сүзе — сүз иде, тавышы — моңлы, эше — гамәл!

Аның балта эшенә осталыгы күпләрне хәйран калдырды. Идел артындагы дачасына ул зур бураны берүзе бурады, йорт итеп, камил итеп салып та куйды. Өендә дә тәртип, пөхтәлекне яратуы беренче урында тора, гаиләсен даими кайгыртып яши белде. Кул эшләрен камил рәвештә башкаруы барча кылган гамәлләреннән күренеп торды. Һаман да һәммә нәрсәне үзе башкарырга өйрәнгәнлеге сәбәпле, кешегә ялыну, башкаларга салыну кебек гамәлләр уена да кермәде Хәйдәрнең.

Зур бер Казан шәһәрендә генә дә танышлары, дуслары арасында балта осталары күп иде. Аларның хәлләрен белешеп тору, яннарына барып чыгып, тормыш, сәясәт, аң-мәгърифәт мәсьәләләренә кадәр җитеп фикер алышулары эчкерсезлеген күрсәтеп тора. Сөеп, үз итеп сөйләгән кешеләренең берсе — Нургали абзый — урман хуҗалыгы белән бәйле кешеләрдән берсе иде. Ул аның

гадилегенә, хезмәттәшләренә карата гадел хөкемдә булуына исе китеп бәян иткәннәре хәтердә.

— Исерекләргә дә сүз әйттерми. Берәүләр кемнедер яманлап, гаеп итеп сүз катса, аны шунда ук туктата. Дөнья бу, тормыш бу, дия. Һәр кешенең үз урыны. Бүген болай булыр, ә иртәгә аннан да ышанычлы кешене табалмассыз, дия. Андый, Нургали абзый кебек изге җанлы адәмне сирәк очратабыз бу дөньяда!

Саба якларыннан булган урман хуҗалыгы хезмәткәре Нургали абзасына Хәйдәр баргалап йөрде. Аны идеал итеп күтәрүенә бераз аптырый да торган идем. Шул кеше белән таныштыруын үтенгәч:

— Ашыкма! «Кара урман» романымны язып бетерим, аннары… — ди торган иде.

Ул әсәренең язмышы миңа мәгълүм түгел. Әсәрләрен Хәйдәр хәтта басылып чыккач та күрсәтергә, фикеремне белергә атлыгып тормады. Үз иҗатына бәйле актан да, карадан да сүз әйттерәсе килми иде аның.

Дусларының берсе зур рәссам Фаил ага Зыязов иде. Аларны бергә еш очраттым. Югыйсә бездә танышсалар да, алга таба алар, Фаил агада очрашып, дөнья барышына бәйле әңгәмәләр корып, иҗат эше газапларын йөрәкләре аша уздырганнарында, күңел зарларына кушып, аптырашка да бирелми калмаганнар. Әдипләрдә һәм сәнгать кешеләрендә уртак уйлар белән яшәү тәртибе бар. Фаил ага Зыязовның Хәйдәр язган әсәрләр нигезендә берничә картина иҗат итүен сәнгатькәрләр генә түгел, музей-күргәзмә тамашачылары да яхшы белә. 1921 елгы ачлык турында Хәйдәр хикәя язгач, аның нигезендә ачлык темасына багышланган бүреләр турындагы Фаил ага Зыязовның картинасы күп кенә күргәзмәләрдә дә булды. Хәйдәр дә ул данлыклы рәссам турында телевизион фильм эшләде. Аны телевизордан кат-кат тапшырдылар. Ул шәхес аның зур ачышларыннан берсе иде, әлбәттә.

Кешеләрнең дәрәҗәләрен белү һәм аларны ихласлык, хакыйкать, намус призмалары аша күреп бәяләү Хәйдәргә хас сыйфатлардан берсе иде. Ул үзе өчен генә яшәгән, сүзендә берне сөйләп, гамәлендә икенче төрле булган, дан-дәрәҗәдән башканы сөймәгән, аңламаган әдипләргә карата каты бәгырьлелек күрсәтүне дөрес эшкә санады. Алар аны сөймәделәр. Җир шары ничек ике полюска бүленгән кебек тоелса, анда яшәүче кешеләр дә шундыйдыр инде: берләре — уңда, икенчеләре — сулда, дигәндәй.

XI. ЖУРНАЛИЗМ

Бернинди әдип тә, бернинди әдәбият та бу «авырудан» азат түгел. Бигрәк тә татар әдәбиятына ул каты йокты. Хикмәте шунда: безнең татар әдипләре көн күрү, яшәү хакына газета-журналларда кәсеп итәргә мәҗбүрләр. Мәкаләләр язу, газета чыгару, телерадио тапшырулар әзерләү, әлбәттә, журналистлар эше. Аларның үз хезмәт ритмы, үз яшәү тәртибе, язу, сөйләү, иҗат үзенчәлекләре дә бар. «Журнализм» гади сөйләм нормаларына нигезләнә, аңарда әдәби сөйләм принциплары юк дәрәҗәсендә. Ә безнең татар әдипләре, газета-журналларда хезмәт итеп, журналистлык кәсебендә шактый уңышларга ирешеп өлгерсәләр дә, әдәбияттан ераклаша баралар. Бу аларның язган әдәби әсәрләрендә ачык күренә башлый. Иң әүвәлдә әдәби стильне гадиләштерүгә омтылудан башлана, аннары әдәби формалардан публицистик калыплар өстен чыгарыла, инде образлы-сурәтле тасвирны фикер әйтү, хәбәр, вакыйга сөйләү алыштыра. Шушы өч адымнарыннан

әдипләрнең әсәрләренә «журнализм» чире йокканлыгын күреп була. Кайсы гына, хәтта әдәби дип аталган журналны яки газетаны ачып укып карамыйк, шигырьме ул, прозамы, башкасымы — алар барысы да «журнализм» авыруы тәэсирендә туган «гарип» әсәрләрдән торалар диярлек. Бу авыруның диагнозы күптән билгеле. Матбугат органнары тууга ук, газета-журналларны «литературчина», ягъни «әдәбилектән» коткару өчен оештырылган зур кампанияләр, чыннан да, ахырда журналистиканы әдәбияттан «котылдырганнар». Бигрәк тә XIX йөз Европа, Америка, рус матбугатлары «әдәбилектән» савыккан һәм моның өчен әдип кулы, әдип күңеле, әдип акылы белән язылган чын әдәби әсәрләргә (шигырь, хикәя, роман) газета-журналларда киң урын бирүдән дә оста файдаланганнар, югыйсә, һәм хәзер дә бу шулай булып кала бирә. Журналистик сәхифә белән әдәби полосалар бер-берсенә буталмыйча бирелү укучыда аларны дөрес аңларга ярдәм итә, үзләренчә яшәүләренә шартлар тудыра. Әмма татар матбугаты, бигрәк тә совет чорында, башкача эш итте. Әдәби әсәрләрне дә журналистик алымнарга буйсындыру редакторларның төп эшенә әверелде. Шул чорда әдәбиятка «журнализм» йокты, ә журналистикада «әдәбилек» авыруы бетә барды. Журналистиканың мәйданы шактый киң иде.

Хәйдәр, иң беренче чиратта, зур һәм бөек әдип булды. Әмма әдәби формаларда җиңел фикерли алудан шактый читләшергә өлгергәнлеге әдәби әсәрләрендә ачык күренә торды. Ул моны үзе дә сизә. Аларга «журнализм авыруы» дигән диагноз куймый мөмкин түгел иде. Шунда ук Хәйдәрне кисәтергә дә тиешмен дип таптым:

— Зинһар, «журнализм»ны рационализм һәм натурализм белән бутамагыз, — дидем.

Әлбәттә, рационализм дигәндә — табигыйлек, натурализм дигәндә — тышкы, болай да күренеп, аңлашылып торган чынбарлыкны сурәтләү күздә тотылуын белдердем. Минем аңлатмаларны ул бәхәссез кабул итә иде. Сүз «журнализм» мәсьәләсенә күчте. Татар әдипләренең күпчелеге, шагыйрьләре, язучылары газета-журналлардан алып өлгергән бу авыруларыннан савыкмаслык хәлгә калганнарын аңлаган Хәйдәр үзе дә ул аймактан чыгар юлны озак эзләде. Сурәтле фикерләүгә кайтуны ул мифлардан өлге алудан, үзе тоткан юлда — вакыйгаларны мифлаштырып бәян итүдә — табар сыман иде. Авыр иҗат газапларына бирелү аны изә башлады. Холкына да тәэсир итми калмады. Билгеле, язучы халкында тормышка хыял күзлеге аша карау гадәте бар. Моңардан аларны бары тик фән генә саклый ала. Юккамы алдынгы карашлы Европа әдипләре үзләрен гыйлем өлкәсе белән тыгыз бәйлиләр. Кайсын алсагыз да, яки ул физик, математик, яисә тарихчы, филолог. Электән Дантелар, Бокаччолар чорыннан ук шулай килә.

Боларны еш искә ала башлагач, Хәйдәр фән өлкәсе белән яхшылап кызыксына башлады. Галимнәр белән дуслыгын ныгытты.

Хыялдан азат булу дигәнне дә ул дөрес аңларга тиеш иде. Асылда, әдипләр юкны бар итеп күрү һәм сафсата бәласенә төшәләр. Һәр вакыйганы адәм башына килә алмаслык, тормышта булырлык түгел дәрәҗәдә катлауландыралар. Яшәеш чишмәгән, чишәргә теләмәгән мәсьәләне кеше акылы гына хәл итә алмый. Җәмгыятьнең үсешеннән башка гына, нинди генә талантлы булма, күп нәрсәләргә ирешеп булмый. Хәйдәр боларны акылы белән аңлый, күңеле белән тоя, әмма әдиплек максимализмы, «журнализм» коткысы аңардан

күпне таләп итә. Андый хисләр белән шаяру мөмкин түгел. Хисләрнең алдау, саташтыру көче бар.

Бервакыт ул графоманлык мәсьәләсен бәхәс мәйданына чыгара башлады. Бу гыйбарә артында нәрсә торганлыгын сорадым. Хәйдәр ул сүзне язуда талымсызлык дип аңлый икән. Мин көлеп куйдым. Андый вакытта ул икеләнеп кала торган иде.

— Дустым, — дидем аңа, — читтән кергән-кертелгән сүзләрдә, асылда, берничә мәгънә булучан. «Графоман» кәлимәсенең дә сүзгә-сүз эчтәлеге бар, шулай ук фикер үсеше тарихында аркасына алган йөге һәм, аннан килеп, телдә кулланылышы белән бергә, безнең үзебезнең ул гыйбарәне аңлау дәрәҗәбез.

Ул сөйләшүебездә графоманлыкның мәгънәсе идеологик яктан тотнаксызлык хәленә калу икәнлегендә тукталып калдык. Кичә кызыл таҗ киеп тә, бүген яшел чапан бөркәнүчеләр иде графоманнар.

Иҗат эше, әлбәттә, күңел хезмәте. Әмма акыл белән җан бергә береккәндә генә кешенең гамәлләре дөрес була башлый. Иҗатта күңелгә дә, акылга да бердәй таянырга кирәк. Иҗат ул, иң беренче чиратта, хакыйкатьне танып белүгә юнәлтелә. Хакыйкатьне төшенмичә, юкны бар итеп тасвирлау — иҗат түгел, саташу, графоманлык.

XII

Элекке эшемдә чагында Хәйдәр миңа еш килә иде. Институтта укыту эшенә күчүемә, бөтенләй башка тормыш башланды. Минем әле лекцияләрем, әле утырышларым, җыелышларым. Әүвәле ул айга бер килеп китсә, хәзер ярты елга бер минем ишеккә юлын төби. Әмма яңа дуслар, яңа хезмәттәшләр арасына кереп китә алмады. Безнең дуслык та суынды. Ул язу, иҗат эшенең авырлаша баруыннан зарланып, кайчакта шалтырата иде хәзер. Алар да бетте.

Теге вакытта, мәктәпләре юбилеена алып кайткач, аны туган авылына, Дүртмунчага, үзен генә алып барып килдем. Күпер асты ягында тыкрыклы урам булып, шундагы су буе юнәлешендә торган үзенең туып үскән йортына алып керде. Яз вакыты, яңгырлы, юеш, пычрак чаклар иде. Ишегалдына кергәч тә сул якта — таштан сарай, түрдә — терлек абзарлары, уңда — матур гына йорт. Янәшәсендә агачлар үсә.

— Өй каршындагы юкә агачы ауды бит, — дип, түрбакча уңаена алып килеп күрсәтте йортның ул вакыттагы хуҗабикәсе.

Ул адәм биеклеге урыннан шартлап сынган да шул килеш, киселмәгән хәлендә авып ята.

— Эче черек булган икән, — диде Хәйдәр. — Бала чагымда утырткан идем. Минем язмышка ишарә итә булыр!

Йөрәк жу итте.

— Агачтан да фал ачкач, нинди мөселман инде син! — дидем аңа, тәмам ачуланып.

Анысы дөрес инде: урман кисүдә күп иза чиккән кеше буларак беләм: агачны аударганда, бәласенең кайсы яктан сугарга мөмкинлеген даими аңлап, сизенеп эшләргә кирәк. Агач кисүнең җае бар. Мең исәптә бер ялгышу да харап итеп ташлый. Менә шуларны күздә тоткан акыллы кешеләр агач кисүдән сакланырга киңәш иткәннәр. Аларның ул сүзләре өзек чыбыклар аша тапшырылган, халыкта агач авуны-аударуны белә белгән юраугa кайтарып калдырганнар. Замана кешесе боларны гына белергә тиеш иде.

XIII

Дусларымны бик еш искә ала торган гадәтем бар. Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Наис Гамбәр, Фаил Зыязов, Гөлүс Хафизов... Саный китсәм — аз түгелләр. Хәер, артык күпкә дә җыелмыйлар. Барысын да атамадым. Догаларымда да «баргач кайтмый торган җиргә киткән» һәм монда калган дусларыма газап утларыннан саклавын һәм аларга яхшылыклар бирүен Аллаһы Тәгаләдән ялварып сорыйм.

Хәйдәрнең үлем түшәгенә ауганлыгын, телефоннан шалтыратып, Мөдәррис Әгъләм хәбәр итте. Телевидениедән күрсәткәннәр. Кабатлаячаклар икән. Нәкъ шулай булды. Сюжетлары хәтергә уелып калды. Уйланылмаган хәл булган, хатыны пычак тотып эшләгән вакытта, Хәйдәр ялгышлык белән аның кул астына килеп кергән. Искә алуы да авыр. Икесе дә калын пыялалы күзлекләр кия иделәр. Бәла аяк астында гына шул.

Бу вакыйга дөньяның котын алды. Язучы халкында бераздан имеш-мимеш куерды, төрле фаразлар белән урамнар тулды.

Хәйдәр белән хатыны үзара тату, берсен-берсе бик тә сөешеп, яратып, бәхетле яшәделәр. Ул аңа авыз күтәреп авыр сүз әйткәнен мин белмим. Хатыны да аның һәр адымын аңлап, һәр сүзен кабул итеп, алдында келәм, аркасында мамык япма булып, хезмәтендә камил зат иде.

Нигә, ни өчен, ничек шулай аралары бәла белән киселгәндер — аңлашылмады. Гомер буе матур яшәяшә дә әҗәл шуклыгыннан аякларың таеп китсен инде — алай бер дә дөрес түгел бит!

Көтелмәгән бәла аркасында Хәйдәрнең хатыны Наилә ханым берьюлы ничәмә ут эчендә калды. Ялгышлыгы аркасында ирен югалтуы аны акылыннан яздырыр хәлгә җиткерсә, кеше теле, кеше сүзе, имеш-мимеш уйдырмалар бәла чоңгылына җанын төртеп төшергәннәрдер? Мәхкәмә хөкеме бер хәл, ил хөкеме, халык хөкеме аңардан мең тапкырлар авыррак түгелме? Аллаһы Тәгалә мондый чакта кем ягында була? Сөйгән хатынын ялгышлыгы өчен каһәрләүче Хәйдәрнең дуслары, танышлары, ялгышмыйбызмы? Имеш-мимешләрдән арынырга вакыт түгелме?

Бу уйлар ничә еллар күңелемне борчып, вакыт-вакыт изеп тордылар. Ул чишелмәс төенгә әверелде. Һәм көннәрнең берендә хәл ителде.

Эшемнән кайтып килә идем. Хәйдәрнең хатыны очрады. Гаилә хәлләрен белештем. Улы өйләнгән, Хәйдәрнең кабер туфрагына, Дүртмунчага, ел саен барып, зыярәт кылалар икән. Сагыналар үзен.

Мин башка һич сүз сорашмадым. Авыр туфрагына җиңеллек үтенечендә үз юлларыбызга киттек. Шул минутларда Хәйдәргә Аллаһы Тәгалә җәннәт ишекләрен ачканлыгын күңел тойгандай булды. Борчылулар тулы уйларымнан аерылдым. Инде Хәйдәр хакында сүз чыгып, танышларымнан берәрсе имеш-мимешләргә бирелсә, юкны сөйләмәскә киңәш итүне гадәтемә керттем. Юкка әйтелмәгән бит, бәла аяк астында, дип. Ул хәтта бөекләргә дә кагыла. Ә Хәйдәр узган заманыбызның бөек әдипләреннән берсе иде. Табигате белән шулай яратылган, талантлы, чиста, пөхтә, булдыклы, ярдәмчел кеше, чын шагыйрь, чын язучы! Каләмдәшләре арасында мәртәбәсе даими югары иде. Бервакытта да икетөрлелек, икейөзлелек күрсәтмәде. Шуңа да аны юксынабыз, искә алабыз, әсәрләренең кабат томнар булып халыкка чыгуын көтәбез. ■

ЧИТТӘ

НУРИЯ ИЗМАЙЛОВА

Бигрәк татлы телле монда халык,
Бер дә юкка мактап маташа.
Их, әйтсәләр икән бер ихлас сүз,
Төчеләнми генә — татарча!

Егылмаганда да кул сузалар,
Егылсам да, бәлки, килерләр.
«Авырткандыр тәне баланың», — дип,
Булмас ләкин яше түгелгән...

Ятимгә дә ятлар йомшак телле,
Тик ул онытамыни әнкәсен?!
Безнең өчен көч һәм яшь коючы,
Төртеп екса, тартып торгызучы
Туган ил һәм әни яшәсен!

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНӘ

«Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле».

Габдулла Тукай,
«Уянгач беренче эшем»,
1913 ел, 14 март

БЕЗНЕ УРЫНСЫЗ ЯМАНЛЫЙЛАР (1907), шигырь. Әсәр — азәрбайҗан шагыйре Мөхәммәт Һадиның «Нәјимиз вар?» шигыренә назыйрә рәвешендә ияреп язылган, XX гасыр татар тормышының тискәре якларын, шәрекъ халыклары сатирасындагыча, мактый-мактый төп башына утырта, ягъни мыскыллы ирония белән тәнкыйтьли, фаш итә торган сатирик (һөҗүви) касыйдә. М.Һади сатирасының башламы түбәндәгечә: *«Нә исте, дади үлвиҗҗәт, нә дә урфанымыз вардыр, / Деҗәрсиз, хеҗрсиз җүз мин сүру наданымыз вардыр»;* Тукай нәзыйрәсенең беренче бәйте исә болай: *«Сәдакать бездә юкмыш; булмаса, ялганымыз бардыр; / Нифакъ выставкасында күп медаль алганымыз бардыр»*. Һәр ике автор гаруз гыйльменең 16шар иҗекле, 4 ритмик буынлы һәзәҗ төренә мөрәҗәгать иткән. Ике әсәр дә үзләренең тышкы һәм эчке төзелешләре белән газәлгә охшаган. Мондый синкретизмның сәбәбе тарихи әдәби барышта газәлнең борынгы гарәпләрнең касыйдә жанрыннан аерылып чыгуы белән аңлатыла. Һәр ике шагыйрьдә рифма һәм касыйдә, һәм газәл жанрына хас аа ба ва рәвешендә бирелә, һәр бәйтнең икенче юлында рәдиф-рефрен вазифасын үти торган «вардыр» (бардыр) сүзләре кабатлана. Шигырьләрдә баштан азакка кадәр логик эзлеклелек белән үстерелеп килгән фикри яки хисси сюжет бөтенлеге юк. Алардагы һәр бәйт мөстәкыйль тәнкыйди эчтәлеккә ия. Шул сәбәпле, М.Һади белән Г.Тукай шигырьләре касыйдәдән бигрәк, шәрекъ әдәбиятларындагы күп теманы берләштергән «сәчелмеш газәл» жанрын хәтерләтә. Азәрбайҗан һәм фарсы әдәбиятларында мондый шәкелдә Нәсими белән Хафиз газәлләре язылган. Тукай назыйрәсе дә шундый ук төзелештә: анда һәр бәйтнең үзенә генә хас эчтәлеге, темасы, проблемасы бар. М.Һади белән Г.Тукай шигырьләре тәнкыйди һәм сатирик эчтәлекне ниндирәк иҗат ысулы белән гәүдәләндерү ягыннан да бер-берсеннән аерыла. М.Һадиның һөҗүви касыйдәсе романтик рух белән өртелгән. Аның бөтен пафосы — азәрбайҗан, төрекләр яшәешендәге рухилыкның бик түбән дәрәҗәдә булуын эчке кичерешләр белән сугарып сурәтләү. Тукай назыйрәсе — тәнкыйди реализм әсәре. Аның бөтен эчтәлеге кадимче голямәләр эшчәнлегенең яңа тарихи шартларда татар халкының тәрәккыяте таләпләренә җавап бирмәвен күрсәтүгә юнәлтелгән. Г.Исхакыйның «Инкыйраз» антиутопиясендәге кебек, Тукай касыйдә-сатирасында да татар иҗтимагый-мәдәни тормышының торгынлык кичерүе тәнкыйть ителә; исламча яшәү рәвешен бары тик комганлы, тәһарәтле булуда күргән, әхлакка зарарлы хәрәм уен-гамәлләрне тыймаган, милли яшәешне яңартырга омтыл-

ган җәдидче яшьләрне сүгү белән генә шөгыльләнгән сәләфче, кадимче дин әһелләренә мыскыллы ирония белән җавап бирелә. Автор фикеренчә, урта гасырлардагыча җәһаләт сазлыгына батып яшәгәнгә күрә, татарлар арасында сәнәгатьчелек, һөнәрчелек үсеш алмаган (*«Санагать юк, һөнәр юк дип, яманлыйлар урынсызга; / Яһүдидән җиңел мал тапкучы ишаныбыз бардыр»*). Кая гына карама — һәркайда хәерчелек, фәкыйрьлек һәм наданлык хөкем сөрә: *«Татарда акча юк, байлык юк дип, юкны сөйлиләр; / Урам тулы, кулын җәеп, бурыч сораганымыз бардыр. // Тагын бездә гыйлем әһле — зыялылар да юк, диләр; / Утыз еллап Бохар, Каргалыда торганымыз бардыр»*. Мәдәни яшәешнең асылын тәшкил иткән табиблык фәне әле дә авыруларны әбибабайлар заманындагыча фанилыктан бакыйлыкка күчкәндә укыла торган «Ясин» берлән сугып егалар». «Закон белгән юристлар да юк, чөнки фикъһе гыйльме нигезләре әле һаман XII гасырдагыча Борһанетдин Гали Маргелани тарафыннан язылган «чуен калкан» — «Һидая шәрхе» (юл күрсәткече) буенча укытыла. Матур әдәбият үрнәкләре дә Әхмәт Уразаев-Кормашиның «Таһир илә Зөһрә», «Бүз егет» турындагы романтик мәхәббәт дастаннарыннан ерак китмәгән. Рәсем сәнгатебез аеруча кызганыч хәлдә: ул исә пәйгамбәребез биографиясе белән бәйле Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләре күренешләрен сурәтләгән, изге аятьләр язылган шәмаилләрдән генә гыйбарәт: *«Художниклар вә рәссамнар дә бардыр, юк диялмаслар, / Мәдинә, Мәккә дип, төрле буяу сатканымыз бардыр»*. Татар тормышының артталыгын чагылдырган бу гаепләүләр шигырьнең төп каһарманы — кадимчелек тарафдарының «Безне урынсыз яманлыйлар» дигән бәхәскә, мактануга, масаюга корылган монологы ярдәмендә алып ташлана; әсәр тукымасы эченә яшереп бирелгән автор образы исә аның «бездә барысы да бар», без сәләтле, без булдыклы («истигъдадлы») дип шапырынуларын усал, чәнечкеле, мыскыллы сардоник көлү белән тарих чүплегенә ыргыта.

Әсәр, 1907 елның май азагы — июнь башында язылып, «Бездә истигъдад бар» дигән беренче исеме астында җыентыгында бастыру нияте белән Казанга Шәрәфләргә җибәрелә. Ундүрт бәйттән торган бу шигырь, ике кисәккә бүленеп, «Әл-ислах» газетасының 1907 елгы 10 декабрь һәм 1908 елгы 8 гыйнвар саннарында «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга. Аның беренче өлеше 2 гыйнварда гает бәйрәме уңае белән Купеческое собрание залында үткәрелгән әдәбият кичәсендә укыла. Моннан соң ул «Безне урынсыз яманлыйлар» исеме белән «Габдулла Тукаев диваны»нда (1909) дөнья күрә. Кульъязмасы сакланмаган.

Чыганак
Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда. — I том. — Б.184-185.

Әдәбият
Тукай Г. Әсәрләр: 5 томда. — I том. — Б.363-365 (төзүче Р.Гайнанов искәрмәсе).

Резеда Ганиева,
филология фәннәре докторы

ЯҢА КИТАПЛАР



МИЛЛӘТ АНАЛАРЫ: ТАРИХИ-ДОКУМЕНТАЛЬ ҺӘМ БИОГРАФИК ҖЫЕНТЫК / төз.-авт. А.Х.Мәхмүтова. — Казан: Җыен, 2012. — 560 б. («Шәхесләребез сериясе»). — Тиражы 1500 данә.

«Шәхесләребез» сериясеннән моңарчы «Җыен» нәшриятында дөнья күргән китаплар халкыбызның горурлыгы саналган ир-ат шәхесләргә багышлана килде, ә бу җыентык исә — заманында мәгънәле гомер кичергән күренекле хатын-кызларыбызга багышланган беренче китап. (Бу материалларның күпчелеген А.Х.Мәхмүтова рус телендә 2006 елда бастырды.)

Әлеге басма тирән ихтирам хисе белән сугарылган һәм укучыда да шундый ук тойгы уята. Җәмгыятьне үзгәртергә хыялланган, хатын-кызларны тулы хокуклы итү өчен көчдәрманнарын кызганмаган, чын мәгънәсендә халыкка хезмәт иткән, авырлыклардан курыкмаган һәм аларны җиңү юлларын таба белгән туташ-ханымнарның тормыш юлы, кылган гамәлләре халкыбызда эчке энергия, лаеклы яшәү дәрте саекмавына бер мисал булып та тора.

Төзүче-автор — Альта Хаҗи кызы Мәхмүтова — төп идеяне укучыга китапның исеме аша ук җиткерергә омтыла. XIX гасыр ахыры — XX йөз башында милләтнең аңын уятырга, рухын сафландырырга, мәгърифәтле итәргә омтылучы фидакарь, олы ниятле туташ-ханымнарны ул милләт аналары буларак бәяли һәм сурәтләп бирә.

Кереш сүздә автор, үз хезмәтенең эчке асылын кыскача гына тасвирлап, китапның күптөрле чыганакларга нигезләнеп язылуын ифрат тыйнак шәрехләп китә. Дистәгә якын хатын-кызның тормыш юлын яктырту өчен күпме китапханә һәм архивларда эзләнүләр, күпме очрашу-сөйләшүләр, күпме вакыт, көч, күз нуры һәм зиһен сарыф ителүен дикъкатьле укучы, һичшиксез, тиешенчә бәяләр.

Кереш сүздән соң махсус бер тупланма итеп татар җәмгыятендә җәдитчелек идеологиясе этәргеч биргән хатын-кыз хәрәкәте формалашуы мәсьәләсенә караган мәкаләләр һәм документлар китерелгән. Бу тупланмада XIX гасыр ахыры — XX йөз башында татар җәмгыятендә хатын-кыз хәятенә яңа караш барлыкка килү, мәгърифәтчелек идеяләренең хатын-кызлар арасында тамыр җибәрүе, әлеге идеяләрнең ничек гамәлгә ашырылу ысулларын ачыклау максат итеп алынган фәнни эзләнү нәтиҗәләре чагылыш тапкан. Шул чорның сулышын, хатын-кызның социаль хәләтен күзаллап, татар ханымнарының яңарышка омтылуына фатиха булып яңгыраган тагын ике язма (аларның авторлары Г.Ибраһимов һәм Г.Исхакый) һәм Казанда 1917 елда булып узган Бөтенроссия мөслимәләренең беренче съезды белән бәйле, хатын-

кыз хәрәкәтенең пульсын тоемларга мөмкинлек биргән документлар да китапның шушы ук өлешендә урын ала.

Китапка кызыклы һәм гыйбрәтле язмышлар галереясе тупланган. Һәр очерктан соң документлар, истәлекләр, мәкаләләр бәйләме бирелгән. Төрле төбәкләрдә дөньяга килеп, төрле мәктәп-мәдрәсәләрдә белем алган, төрле шартларда гомер кичергән, әмма һәркайсы уртак бер максатка хезмәт иткән — милләте өчен янып-көеп яши белгән, хатын-кызга да нигезле белем, әхлакый тәрбия бирүне алга сөргән һәм боларны тормышка ашыруга бәяләп бетергесез өлеш керткән фидакарь ханымнар — милләт аналары — кемнәр соң?

Менә алар: беренче төрки-татар газетасы «Тәрҗеман»ның мәшһүр мөхәррире һәм нәшире Исмәгыйль Гаспралының (Гаспринский) хатыны, ярдәмчесе һәм фикердәше Зөһрә ханым Әсфәндияр кызы Акчурина, мөгаллимә һәм әдибә Мәхбүбҗамал Әхмәр кызы Акчурина, талантлы рәссам Хәдичә Мөбин кызы Акчурина, мөгәллимә һәм шагыйрә Маһруй Габделвәли кызы Мозаффария, танылган мәгърифәтче Бубилар нәселеннән чыккан мөгәллимә, дин белгече һәм ислам дөньясында бердәнбер хатын-кыз казыя Мөхлисә Габделгалләм кызы Нигъмәтуллина-Буби, Казанда кызлар өчен данлыклы җәдит мәктәбе тоткан сынмас рухлы, дипломатларга хас сыйфатларга ия Ләбибә Һадиулла кызы Хөсәения, Казанның Пыстау (Суконная) бистәсендә кызлар өчен кисү-тегүгә, ашсуга өйрәтү курслары һәм мәктәп ачкан, тәвәккәл-җитез ханым Фатиха Габделвәли Аитова, мөгәллимә һәм эшлекле журналист Фатыймаи-Фәридә Мортаза кызы Ваһапова, Франциядәге Сорбонна университетында югары белем алган, соңрак Мәскәү университетын тәмамлаган Сара Касыйм кызы Шакулова…

Бу ханымнарның зыялылыгы — пөхтә-затлы киемнәрендә, рухи сафлыгы — күз карашларында, горур бәйсезлеге гәүдә тотышында, йөзкыяфәтендә сизелеп тора — гасыр кичеп исән калган фотосурәтләр шул хакта искәртә, аңыбызны җәлеп итә, күзне иркәли. Даулы елларда уттан-судан, исраф ителүдән коткарып калган инсаннардан әлеге кадерле истәлек-фотоларны эзләп табып, еллар-юллар кичеп, бөртекләп җыеп-туплап бирүдә Альта ханым Мәхмүтова бик күп көч сарыф иткән.

Милләт аналарының язмышы — бүгенге яшь буын өчен дә гыйбрәтле мисал. Әгәр ерак гасырларга күз салсак, мондый да көчле рух чыганагы татар хатын-кызында борынгыдан ук «тояк уйнаткан». Ул яуда ияргә менеп җәя тарткан. Ул хан янәшәсендә киңәшче булган. Ул — илбашы егылса, аның урынына тәхеткә менгән. Ул — шагыйрә булып җыр-моң чыгарган. Ул остабикә булып Коръән мәкамнәре шифасын сабыйлар күңеленә иңдергән. Әйе, тирән тамырларың, тарихи нәсел чылбырың, таяныр җирең булмаса, буыннан-буынга килгән «китап җене», мәгърифәт нуры кагылмаса, кинәт кенә калкынып, «милләт аналары» дигән солтанатлы мәгънәгә ия исем алып, бер генә бирелгән кыска гомердә мондый биеклеккә чөелү насыйп булмас иде.

Бүгенге заманда хакими урыннарны күбрәк ирләр яуласа да, хатын-кызларыбыз да сынатмый: мәгърифәт өлкәсендә, сәясәттә, эшмәкәрлектә, фәндә, сәнгатьтә ныклы урыннарны биләп, илнең гадел, төпле терәге булып кала. Аларның чишмә башы, ерак үткәннәре — шушы китапта. Күренекле галим-педагог, публицист Альта Хаҗи кызы Мәхмүтовага шушы бибәһа китапны дөньяга бар итүе өчен мең рәхмәт җиткерәсе килә.

Динә Мостафина,
тарих фәннәре кандидаты

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

17 ҺӘМ 18 ОКТЯБРЬДӘ ТАТАР КИТАБЫ БАШКАЛАСЫ БУЛГАН КАЗАНДА БӨТЕН ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ӨЧЕН ДӘ МӨҺИМ ТАНТАНА – «ДӨНЬЯКҮЛӘМ РУХИ МӘДӘНИЯТ МӘЙДАНЫНДА ТӨРКИ ТЕЛЛЕ КИТАП» ДИП АТАЛГАН ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ БУЛЫП УЗДЫ.

ТӨРКСОЙ теләктәшлеге белән үткәрелгән әлеге чараның оештыручылары Татарстан Фәннәр академиясе, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе иде. Әйтергә кирәк, конференция төрки дөньяда гына түгел, Европа илләрендә дә кызыксыну уятты, мәркәзебезгә Төркия, Казахстан, Азәрбайҗан, Украина, Литва кебек җөмһүриятләрдән галимнәр килде, Россиянең әйдәп баручы фәнни үзәкләре дә үз вәкилләрен җибәрде.

Фәнни җыенда катнашучыларга котлау сүзләрен Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе М.Ш.Шәймиев, Татарстан Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы, Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Р.И.Вәлиев, Татарстан Фәннәр академиясе президенты Ә.М.Мазһаров, Төркия республикасының Казандагы консулы Сабри Тунч Ангылы, Иранның Казандагы генераль консулы Рәсүл Багернежад Шаян, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Э.Н.Фәттахов һ.б. юлладылар.

Конференциянең пленар утырышында К.М.Миңнуллин (Татарстан, Россия), Шүкрү Халүк Акалын (Төркия), Д.М.Насилов (Россия), И.А.Кәримов (Кырым, Украина) кебек атаклы галимнәрнең докладлары зур игътибар белән тыңланды. 18 октябрь көнне секция утырышларында китап белеменең төрле аспектлары турында сөйләнде, фикер алышулар булды.

Шунысы мөһим: Казанда ике көн кунак булган чит ил галимнәре һәм Россиянең башка өлкәләреннән килгән белгечләр башкалабызның бай китапханәләрендә һәм архивларында төрки-татар китабының тирән тарихы, аның тематикасы, төрләре, нюанс-үзенчәлекләре белән танышырга мөмкинлек тудырылган өчен җыенны оештыручыларга рәхмәт сүзләрен җиткерделәр. Шулай итеп, әлеге конференцияне гомумкешелек өчен әһәмияткә ия булган төрки китапны өйрәнүгә искиткеч зур өлеш кертән чара дип бәяләргә була.

Булат Хәйретдинов, *Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кече фәнни хезмәткәре*

Индекс 54132